КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

Мәдәни Җомга

№ 16
3 ноябрь
1995 ел

1995 елның июленнән
башлап чыга

Атналык әдәбият һәм сәнгать газетасы



Бүгенге санда:

2 *Марат* ӘМИРХАНОВ. Миллилектән без элеккечә үк өркеп яшибез. Әлегә кадәр дәүләтнең милли мәгариф системасы эшләмәве моңа ачык мисал.

6 *Мәсгудә* ШӘМСЕТДИНОВА. Гүзәл ил корган швед халкына сокландым һәм, безнең тырыш татар халкы белән дә шундый ил төзеп була, дигән фикер белән кайттым.

8 *Илдус* ЗИННУРОВ. Хәзер күпчелек театрларда, көн кадагына сугабыз дип, вакыйгаларны, образларны, сөйләм телен чиктән тыш вульгарлаштыралар, ә курчак театры мондый гамәлдән читтә тора.

9 *Раиф* МӘРДӘНОВ. Элеккеге татар матбугатының чалымнары һәм алымнары, формасы һәм эчтәлеге, рухы вә мәсләге татар эмигрантлары чит илләрдә чыгарган гәзит һәм журналларда сакланып калган.

15 *Солтан* ШӘМСИ. Мәдәниятебез һәм тарихыбыз каршында күрсәткән бөек хезмәте, шәхси фидакярлеге өчен Әхмәд ибне Фазлан хәзрәтләре истәлегенә болгар-татар җирендә һәйкәл куелыр, дигән өметтә яшим.

Оныкларга тонык тоелмасын,
Тарих, заман, нәсел, ата-баба...

МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

Дөньядагы барлык инеш һәм елгалар үзләренә генә хас үзән-юллары буйлап ага. Үлән арасыннан йөгерүче тартарларның да үз ихтыярлары белән салынган сукмаклары була. Ә нигә акыллыбашлар әллисактан агып ятучы гайрәтле елгаларның агымын борырга маташтылар соң? Үзләрен Алла итеп тойган аерым юлбашчылар табигый агымдагы җәмгыятьне ничә тапкыр юлдан яздырдылар. Моның аянычлы нәтиҗәсен ничә буын татый! Инде күктән төшеп йөрүче фәрештәләрне "рәхмәт юлы"ннан тайпылдырмасак иде, Ходаем...

Зиннур МАНСУРОВ

МИН ӘЙТТЕМ

Марат ӘМИРХАНОВ

Кем синең укытучың?

30 сентябрь. Иртәгә — Укытучылар көне. Радиодан концерт бара. Нигездә бәйрәм ияләренең үтенечләрен канәгатьләндерәләр. Ара-тирә укытучыларның шәкертләре дә кушылып китә. Әнә, кайсысыдыр беренче укытучысы хөрмәтенә җыр башкаруны үтенә.

Беренче укытучы! Зур дөньяга сукмак салырга өйрәтүче илаһи зат. Ә минем үземнең беренче укытучым кем иде соң? Ми сырларына юшкын булып яткан ерак хатирәләрне уятырга тырышып карыйм. Юк, уянырга теләмиләр. Ни кызганыч, уятырлык хәтер калмаган. Гафу ит, хөрмәтле апам, син минем тормышымда оя кора алмагансың. Шулай да, җиде ел белем алган туган авылым Көзкәй мәктәбендә мөгаллимлек иткән кемнәрне хәтерлим соң мин? Гөлсем апа исте икән. Ул безне укытмады, тик барыбер хәтергә уелып калган. Безне, бот буе малай-кызларны, дәрестән соң башак җыярга йөртәләр иде. Гөнаһ шомлыгына каршы димме, эскерт ышыгында шул Гөлсем апаның военрук белән үбешеп торганын күреп алдым бит, каһәр. Билгеле инде авыз тишек, бу мөһим вакыйга турындагы хәбәрне башкаларга да ирештердем. Үз чиратында ялагайлар моны Гөлсем апага сөйләгәннәр. Тегесе исә, мин ул малайның кирәген бирермен әле, дип әйткән, имеш. Шуннан куркуларымны белсәгез иде, төне буе йоклый алмый боргаланып чыктым. Калганы менә, нәтиҗәсе ягъни дә, исте юк.

Тагын? Тагын физика укытучысы күз алдымда тора. Ак йөзле яшь кенә чибәр апа иде. Ул вакытта физик законнар, формулалар дәреслектә кара рамка эченә алынып, симез хәрефләр белән бирелә иде. Апабызга алар әллә бар, әллә юк, сикереп кенә үтә.

Аның каравы җиденче классны бик күбебез Мактау грамотасы белән тәмамлады. Андыйларга кайда да юл ачык икән. Без исә өебез белән 60 чакрымдагы Минзәләгә юнәлдек, педучилищега. Ләкин анда безне колач җәеп көтеп алмадылар, «отличник»лар гына да бер урынга 8-10 кеше туры килә, диделәр. 1 сентябрьдә урыс теленнән диктант яздырып, иләктән дә сөзделәр. Без барыбыз да иләк өстендә калдык. Көзкәй «бишле»сенең егәре Минзәләдә сукыр тиенгә дә тартмады.

Алай да әнкәй, җаен табып, мине Актаныш урта мәктәбенә кертте. Ни әйтсәң дә, мулла нәселеннән бит, әткәй дә сугышка киткәнче мөгаллимлек иткән, укысын дигәндер инде.

Урта мәктәптә уку авыр иде, «икеле»ләрне дә тизәләр генә, вакытында төзәтмәсәң, куып җибәрергә дә күп сорамыйлар. Ул вакытта ялынып укытмыйлар иде. «Икеле»ләргә иң маһиры математика укытучы Сәйдәш абый булды, дисәм, һич тә ялгышмам. Юан гәүдәле, салмак хәрәкәтле, әтенебрәк сөйләшә торган буйдак кеше иде. «Хотя бы, җә такта янына чыксын әле», — дип журналдагы исемлектән чираттагы «корбан»ын эзләгәндә җан аяк табанына җитә иде мәгәр. Аның өчен укучылар ике генә төркемгә бүленә. Беренчесе — математика җене кагылучылар, икенчесе — күчерүчеләр. Беренчеләре аның, гадәттә, класста өч-дүрт бөртектән артмый. Сәйдәш абый аларны чын математик итеп коеп куя иде. Аларның шактые фән юлыннан китте, араларында профессорлар күп. Кызганыч, мин аның яраткан шәкерте була алмадым. Әмма ул сәер укытучымны әлегәчә ихтирам итеп искә алам.

Урта мәктәптә укыганда, әгәр шундый мөмкинлек тудырылган булса, радио аша җыр сәламен беренче чиратта Миргалим абый Дәүләтбаевка җиткерер идем, мөгаен. Талканы коры иде. Шуңа күрә тәннәр буе физиканы ятлый идек. Әмма ул безне башка сыйфаты белән шаккатырды.

Хәл болай булды. Актаныш авылының нәкъ үзәгендә мәчет бар иде. Электән ничектер манарасын аудармаганнар. Инде шул хатаны төзәтергә ниятләгәннәр. Безгә дә өлеш чыкты. Комсомол җыелышы җыеп, өлкән класс малайларын «осталар»га ярдәм итәргә барырга мәҗбүр иттеләр.

Март ае иде. Аяз, салкынча көн. Ярмалы кар аяк астында керт тә керт итеп изелә. Без вакыйга буласы урынга элдертәбез. Соңга калырга ярыймы соң — килмәсәгез оешма белән хушлашачаксыз, дип кисәттеләр ич.

Капкадан чыгуга Миргалим абыйга тап булдык. Шырпыдай төп-төз булып басып тора бу. Кулында кәкре башлы таягы. Йөзе кырыс.

— Кая барасыз? — дип туктатты бу безне.

Бер-беребезне бүлешә-бүлешә, максатыбызны аңлаттык.

— Бирермен мин сезгә малай актыклары, — диде Миргалим абый күзләреннән ут уйнатып, — хәзер үк торакка кайтыгыз, дәресләрегезне яхшылап әзерләгез, ничу трай тибеп йөрергә.

Миргалим абый туры сүзле, принципиаль, гадел кеше иде. Кияве дә үзенә охшаган. Танылган артистыбыз Равил Шәрәфи турында әйтүем. Кызларын ул ярәште.

Әлегә сүзем гел физиклар, математиклар турында. Бу — табигый. Чөнки тормышта гуманитар юнәлеш буенча китсәм дә, үз юлымда чын күңелемнән татар әдәбиятына, милли тарихыбызга, сәнгатебезгә бирелгән әдәбият укытучысына тап була алмадым. Минем иҗатка соңлап керешүемнең сәбәбе дә шундадыр дип уйлыйм. Хикмәт миндә генә булса, бер хәл иде. Юк шул. Күпме талантлы татар баласы шытым бирә алмыйча вакытсыз көярга мәҗбүр ителә. Җиде миллионлы татарның өчтән-дүрттән бере генә тарихи ватанында яшәвен исәпкә алсак, бу милли фаҗигагә әверелә түгелме? Бәләбез ләбаса, чит өлкәләрдә яшәүче татарлардан әдәбият-сәнгатькә агым тукталып бара. Анда талантлы балалар юкмы әллә?

Без укыган чор татар теленең иң кимсетелгән вакытына туры килде. Чак-чак терәге сынмыйча калды телебезнең. Ходай саклады. Татар теле укытучылары арасында башка фәннәргә борын тыга алмаганга гына әлеге белгечлекне сайлаучылары да шактый күп иде. Мескеннәр, чарасызлар, басынкылар. Аларны рәнҗетү дә берниге тормый. Чөнки үз шәүләләреннән үзләре куркып-өркеп яшиләр иде. Хәтта югары уку йортларында да бәгъзе галимнәр ана телен, әдәбиятны тамак өчен, корсак өчен генә укытып йөрделәр. Монысына да үзебез шаһит. Аспирантура хакында сүз кузгаткач, берсе турыдан-туры: «Син, Әмирханов, рәтең булса, башка өлкәне сайла, татар теленең киләчәге юк», — диде.

Университетта исә хәл бөтенләй башка иде. Олы максатлар, иҗади омтылышлар белән яши иде студентлар. Чөнки бу фән сараенда шуңа рухландыручы галимнәр эшли иде. Кайберәүләр, ихтимал, педагогия институтының бурычы — укытучы әзерләү, дияр. Әйе. Ләкин, алайга калса, университет тәмамлаганнарны да укытучы итеп җибәрәләр иде. Бу — бер. Икенчедән, иҗади эзләнү, тынгысызлык, рухи омтылыш кебек сыйфатлар укытучылар өчен зарурракътыр да әле ул. Алар кулында милләт язмышы ләбаса!

Институтны мин башлыча урыс теле укытучысы Иван Иванович Назаров образы аша хәтеремдә тотам. Мин — саф татар районында туып-үскән кеше. Мәктәптә исә телләр өйрәнүдә схоластика хөкем сөргәнлектән, дәресләр кагыйдә ятлауга гына кайтып кала иде. Сочинениеләрне күчерә идек, билгеле. Әле дә исемдә, институтта инша яздык. Не тот парень, дигән фразадан мин «Нетопорин» дигән әр-яңа фамилия ясап куйган идем.

Рәхмәт аңа: Иван Иванович мине урыс теленең эчке аһәңен, моңын тоярга өйрәтте. Телне кагыйдә аша түгел, мәгънә аша үзләштерергә кирәк, дия иде. Аның үз методикасы бар иде. Ләкин аны формалист профессорлар хупламады, Иван Иванович киң мәйданга чыга алмады.

Институтны тәмамлагач, мин Питрәч районының Күн сигезьеллык мәктәбенә юллама алдым. Укытучымның бөеклеген дә шунда аңладым.

Мәктәпкә килеп керүгә директор: «Менә яхшы, менә шәп, нинди яшь укытучы — урыс теле укытучыбыз бар безнең хәзер», — дип кулларын угалады.

— Мин татар теле укытучысы, — дидем директорга.

— Бездә татар теле сәгатьләре юк! — дип кырт кисте бу.

Тәвәккәлләдем. Армиягә алганчы, ике ай Күн авылы балаларына урыс теле һәм әдәбиятыннан дәресләр бирдем. Хәер, бу минем башка төшкән бәла генә түгел иде. Татар теле укытучылары сәгать җитмәгәнлектән, тарих, география дәресләре алып бардылар, рәсем, сызым серләренә өйрәттеләр. Хәзер, әнә, Аллага шөкер, сәгатьләр буа буарлык, белгечләр җитешми. Ана телен хәтта химиклар, инженерлар, агрономнар да укыта. Шул рәвешле телебезнең дә, чын белгечләрнең дә абруе төшә.

Абруй дигәннән, Ленин бабай да халык укытучысын буржуаз җәмгыятьтә мөмкин булмаган бөеклеккә күтәрү турында хыялланган. Тормышка гына ашмады. Дөрес, мөгаллимнәрнең дәрәҗәсе патша вакытында да зур булмаган. Чиновниклар иерархиясенең иң соңгы рәтендә, почтмейстерлар тирәсендәрәк йөргән укытучы. Тик шунысы да хак: ул берүзе эшләп тә гаиләсен матди яктан тәэмин итә алган.

Укытучының хәзерге хәле исә хәерчә хәлендәрәк: хәерчелекнең кеше шәхесенә тискәре йогынтысы турында сөйләп тә торасы юк. Беренче чиратта, укытучы өчен һава кебек зарури булган интеллектуальлеккә зыян килә, ул иҗади шәхес булудан туктый. Бу куркыныч бигрәк тә авыл укытучысына яный. Чөнки авыл укытучысы очны-очка ялгар өчен мал-туар асрарга мәҗбүр. Ә мал-туар асраган кешенең иҗади эзләнергә, белемен арттырырга вакыты калмый.

Мин һич тә укытучыларга мал асрамагыз, дигән өндәмә ташларга җыенмыйм. Интеллект, зыялылык канына сеңгән укытучы барысына да вакыт таба. Бер генә мисал. Мин эшләгән Карабаш урта мәктәбенә (Бөгелмә районы) Иркен исемле кечкенә авылдан укучылар килә иде. Үзләрендә аз комплектлы мәктәп. 1-2-3-4 нче класс балалары бер бүлмәдә укыйлар. Аларны Гали Рамазанов дигән зәгыйфь кенә мөгаллим укыта иде. Мәгәр укучылары шартлап торыр иде. Белемнәре тәпле, үзләре тәрбияле, итагатьле. Чын мәгънәсендә талантлы педагог иде мәрхүм Гали әфәнде. Урыны оҗмахта булсын. Кызганыч, андыйлар сирәк шул.

Инде менә милли гимназияләр, төрле колледжлар ачылуга да хәтсез вакыт үтеп бара. Ләкин мәдәни тормышыбызга алар керткән өлеш үзен әллә ни сиздерми әле дияр идем мин.

Милли җанлы, үз халкына җаны-тәне белән бирелгән укытучы-белгечләрне әзерләү, тәрбияләү, үстерү өчен, әлбәттә, ныклы нигез зарур. Татарстанның дәүләт суверенитеты турындагы Декларациясен, 1992 елның 6 ноябрендә кабул ителгән Конституцияне мин шәхсән, башка мөһим мәсьәләләр белән беррәттән, шушы изге рольне дә үтәр дип уйлаган идем. Тик бу өмет өлешчә генә акланды. Миллилектән без элеккечә үк өркеп яшибез. Әлегә кадәр дәүләтнең милли мәгариф системасы эшләнмәве моңа ачык мисал.

Татарстан — татар иле. Татар халкы фәкать шушында гына үз милли дәүләтчелеген кора ала. Өстенлек тә, шуңа күрә, татар халкы ягында. Шуның белән бергә, бу һич тә башкаларны кысу исәбенә башкарылырга тиеш түгел. Әмма шул «башкалар» Татарстан Республикасында яшәүләрен сизеп-белеп торырга, җирле халыкның телен, гореф-гадәтләрен, динен ихтирам итәргә бурычлылар. Мәгариф системасы дөрес уйланылган очракта бу бурычларны мәктәп, укытучылар рәхәтләнеп тормышка ашыра алырлар иде.

Бөек немец шагыйре Гетеның шундый сүзләре бар. «Гыйлем өйрәтүчеләрне без укытучылар дип йөртәбез. Тик аларның бер ишесе бу исемне йөртергә лаек түгел», — дигән ул. Шушы «лаек түгелләр» мөмкин кадәр азрак булсын иде, һәр укытучы бала күңеленә якты маяктай кереп калсын иде.

ҖИДЕГӘН ВАКЫЙГАЛАР ХӘБӘРЛӘР ЯҢАЛЫКЛАР
5 6 7 1 2 3 4

Рәссамнар дәрәҗә дәгъвалый

Русия сәнгать академиясе хакыйкый әгъза һәм әгъза-мөхбир булырга дәгъва кылучыларның исемлеген бастырып чыгарды. Нәкыш бүлегенә хакыйкый әгъзалыкка Татарстаннан күренекле рәссам Харис Якупов та тәкъдим ителгән. Мәскәүдә яшәүче мәшһүр милләттәшебез Әхмәт Китаев исә әгъза-мөхбир дәрәҗәсен алырга ниятли.

Дөньядагы һәртәрле академияләрнең әгъзасы булу гайрә табигый күренеш түгел, әлбәттә. Ә менә Русиядә сан ягыннан икенче урында торган татар халкы вәкилләренең әлеге исемлектә берән-сәрән генә күренүе күңелне хаклы рәвештә борчый. Югыйсә, нәкыш, графика, скульптура, архитектура, сәнгать белеме, гамәли сәнгать, сәхнә бизәү, дизайн һ.б. бүлекләргә күрше милли республикалардан чагыштырмача күбрәк исемнәр кертелгән. Бәлки мондый хәл рәссамнарыбызның таркаулыгыннан киләдер?!

ӨСТӘЛДӘ АК КӘГАЗЬ

Мөслимдә яшәп иҗат итүче танылган язучыбыз Фоат Садриевка телефоннан эндәштек:

— Хөрмәтле Фоат әфәнде, соңгы вакытларда сезнең каләмегездән ниләр тамып төшәргә әзерләнә?

— Әлләни майтара алган юк бит әле, егетләр.

— Шулай да?..

— Шулай да Минзәлә театрында пьесам буенча «Җәмиләнең җенләнүе» дигән комедия куелырга әзерләнә. 4 ноябрьдә премьерасы була.

Аннары өстәлемдә «Бәхетсезләр бәхете» исемле роман язылып ята. Бик авыр бара. Алай да «Аргамак» журналының ике санында өзекләре басылды.

Ике мәшһүр җырчыга — бер китап

Туймазы төбәкара «Илһам» җат берләшмәсе һәм республикаара җат» компаниясе «Татарның ике былы: Фәридә Кудашева һәм Илһам акиров» дигән китап-альбом бастып чыгарырга җыена. Әлеге китап мәүр Моң иярләре, Җыр падишаһлары, нгать илә президентлары, атаклы ырчыларыбызның олуг юбилеена башлана (Илһам Шакировка быел 15 евральдә 60 яшь тулды, ә Фәридә Кудашевага исә 15 декабрьдә 75 яшь тучак) Шул уңайдан без һәркемгә (нин милләттән булуына карамастан) ярәм сорап мөрәҗәгать итәбез: кемнәрдә шушы ике күренекле җырчы турында мәкаләләр, кульязмалар, шигырьләр, җырлар, чәчмә әсәрләр, истәлекләр, багышлаулар, хатирәләр, аларга җибәрелгән котлаулар, аларның хатлары һәм фотосурәтләре, рәссамнар ясаган портрет-сурәтләре яисә аларның күчермәләре булса, зинһар, рәхим итеп хат юллагыз:

452600, Башкортстан,
Туймазы шәһәре,
Комаров ур. 47/1 — 52
Замир Низаметдиновка
(тел. 6-50-39)

АСЫЛЫБЫЗГА КАЙТЫП БАРЫШЛЫЙ

«Мөхәммәдия»гә мәдхия

Авыл урамы буйлап тәз гәүдәле, зифа буй чибәр егет атлый Башында түбәтәе Күзрендә җылы нур йөзе тәвәккәл Мәчеткә ыга егет Авыл өстендә моң, аһәң. Азан ңы һәрбер кеше эшен ташлап карашын чет манарасына юнәлткән Яшь тавыш көе тавыш Авыл имамының халык ишетеп нгән аһәңе түгел бу Яшь шәкерт тавышы Туң йөрәкләрне эретерлек, карт-корыны атырлык, мөселманны шатландырырлык ңлы азан өчен рәхмәт сиңа шәкерт!

Җәйге җылы кичләрдә башка яшьтәшлә төрлечә күңел ачканда балаларны мәче җыеп гарәпчә укырга-язарга өйрәттең. чә сабый күңелә сафлык чисталык мәрәтлелек доньясына беренче адымнарын ды Иншалла алар шушы юлдан тайпылйча син кабызган учактан алган утны сүнмичә башкаларга да өләшерләр диген т уятуың өчен рәхмәт сиңа шәкерт!

Әти-әниләрегезгә белем бирүче «Мөхәммә» шәкертләре зур рәхмәт сезгә!

Моңарчы намаз. дога белмәгән әби-бабалар сезнең яшьлегегез, тырышлыгыгыз, белемегезне, теләгегезне күреп, хәзер намаз укыйлар икән, моңарчы зиратның кайда икәнен белмәгән ирләр гает турында ишетеп кенә белгән егетләр мәчетләргә йөри икән — боларның барысында да синең өлеш бар, шәкерт!

Илебезнең төрле почмакларында яшәүче күпмә ата-ана ышанычлы, тәпле тормыш алып бара икән, белегез аларның балалары — «Мөхәммәдия» шәкертләре Улым кайчан исереп кайтып тавыш чыгарыр икән дип яшәмәүче ата-аналар алар Шундый балалар тәрбияләвегез өчен чын күңелдән рәхмәт сезгә!

Казан урамнарында ак яулык бәйләгән кызлар, ханымнар күбәя, мәчетләргә йөреп укучылар саны арта бара икән, белегез — бу «Мөхәммәдия» кылган игелекле гамәл нәтиҗәсе.

Мең рәхмәт сезгә, мәчетләр, мең рәхмәт сиңа, «Мөхәммәдия», мең рәхмәт сиңа, шәкерт!

Мәдинә ШӘЙХИЕВА.
Казан шәһәре.

Котлыйбыз

Арча районы, Култәс авылында яшәүче ебез Шәйхелислам Нурмөхәммәт улы МӘДУЛЛИНГА 10 ноябрьдә 80 яшь а. Без аны юбилее белән чын күңелдән лыйбыз. Сиңа, кадерле әтиебез, алдаконеңдә тазалык-саулык, көннәреңнең акты, матур булуын телибез. Сиңа доньяның ачысын-төчесен күп тага туры килгән. Безгә — тугыз балага белем-тәрбия бирүе җиңел булмагандыр. Без барыбыз да бүгенге көндә сиңа рәхмәтлебез, әтиебез. Әниебез урынына калып, менә 13 ел инде синең белән чүкердәшеп яшәүче Саҗидә әнигә дә рәхмәтебез зур. Синең шушы көнгә кадәр таза-сау, бәхетле яшәвеңдә аның да өлеше бик зур. Сезнең алдагы көндә дә шулай шат, матур, таза-сау булуыгызны телибез!

Кызың Алидә, киявең Наил, оныкларың Ләйсән һәм Руслан.

Кремль ярдәменнән ташламас

Татарстан Республикасы Президенты аппараты җитәкчесе Хәләф Мирзамөхәммәт улы Низамов «Мәдәни җомга» атналык гәзите редакциясендә булып китте. Шушы елның 21 июлендә беренче санын чыгарып, әле аякка басып кына килүче яңа басма, табигый ки, бүгенге катлаулы икътисади шартларда финанс һәм матди яктан кыенлыклар кичерә. Югары дәүләт даирәсеннән редакциябезгә беренче булып килгән хөрмәтле кунакка, әлбәттә, гәзит җитәкчеләре үзенең моң-зарларын сөйләргә мәҗбүр булды. Әдәбият һәм сәнгать әһелләре белән һәрвакыт дустанә мөнәсәбәттә булган Хәләф Низамов, безнең хәлне аңлап, «Мәдәни җомга»га мөмкин булганча булышлык күрсәтергә, шул исәптән редакция билегән зал һәм бүлмәләрне төзекләндерү җәһәтеннән ярдәм итәргә ышандырды.

Рәсемнәрдән чәчәк исе килә

Казан милли мәдәният үзәгендә Николай Индюхов күргәзмәсе ачылды.

Бу рәссамны лирик пейзаж остасы дип атарга була. Елның кайсы фасылын гына сурәтләмәсен — анда йомшак, җылы лиризм. «Мәгаен, ул минем холкымдадыр инде. Елның һәр фасылын яратам, шулай да иң яратканым — апрель...», — ди ул үзе.

Тамашачылар Н.Индюхов картиналарын ишетеп тә була, диләр — алардан җил дә, яфрак шавы да ишетелә, җиләкләр, чәчәкләр исе дә килә.

Эльмира МОСТАФИНА.

ҖОМГАДАН — ҖОМГАГА

Җөмһүрият елъязмасына җөмләләр

Кино сәнгатенең 100 еллыгы уңаеннан Свердловски киностудиясендә төшерелгән «Сильва» нәфис фильмының 50 еллыгына багышланган очрашу белән Казанның Актерлар йортында чираттагы сезон ачылды.

Республикада чувашча нәшер ителүче «Суар» гәзитенең 100 нче саны дөнья күрде.

Чүпрәле районында яшьләр һәм яшүсмерләр тормышы мәсьәләләрен хәл итү белән шөгыльләнәчәк авыл яшьләре шурасы эшли башлады.

Тиздән Казандагы «Вертолеты-МИ» фәнни-җитештерү берләшмәсендә Әзәрбайҗанның «Азелавия» авиакомпаниясе соравы буенча «МИ-14» нигезендә эшләнгән тәүге вертолет-амфибия җыелып бетәчәк.

Санкт-Петербургта 1996 елның 6 гыйнварыннан 13 гыйнварына кадәр Русиянең танылган опера җырчысы Николай Константинович Печковскийның тууына 100 ел тулуга багышлап үткәрелә торган II халыкара конкурста Татарстанның яшь опера җырчыларының катнашуларын да сорап, Мәдәният министрлыгына чакыру җибәрелгән.

Казанның «Батыр» (элеккеге «Синтез») физкультура йортында 3-6 ноябрьдә Олимпия уеннары, дөнья, Аурупа чемпионы Александр Курынов истәлегенә штангачыларның халыкара ярышлары үтәчәк.

Төркиянең Истанбул шәһәрендә үткәрелгән «Мисс Аурупа-95» чибәрләр конкурсында 1991 елгы «Мисс СССР», Сарытауда яшәүче татар кызы Ильмира Шәмсетдинова Албанил вәкиле белән 4-5 урыннарны бүлеште.

Сәхифәләрдә редакциябез журналистлары, авторларыбыз, «Татар-Информ» һәм башка чыганаклар хәбәрләре файдаланылды.

Ниһаять, Туфанның да бенефисын күрербез

1 ноябрьдә Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында күренекле драматург Туфан Миңнуллин спектакльләреункөнлеге башланды. Ул драматургның тууына 60 яшь тулуга багышлана.

Ункөнлектә, Камал театрыннан тыш, К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры, Казан һәм Түбән Кама яшьләр театрлары, М.Гафури исемендәге Башкорт дәүләт академия драма театры, Уфадагы «Нур» татар драма театры, Туймазы татар драма театры коллективлары катнаша. 11 ноябрьдә Туфан Миңнуллинның бенефисы булачак.

Опера сөючеләр клубы юбилее

5 ноярьдә М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрында опера сөючеләр клубының 10 еллыгына багышлап юбилей кичәсе үткәрелә.

Шушы вакыт эчендә клуб опера сәнгатен популярлаштыру буенча зур эш башкарды: яшь опера җырчылары, танылган татар композиторлары белән очрашулар, премьералар буенча фикер алышулар, танылган музыка әһелләренең юбилейларын үткәрде.

Юбилей тамашаларында Мәскәү кунаклары — классик музыка яратучылар лигасының Русиядәге рәисе В.Каслин, Бөтенрусия музыка җәмгыятьләре вице-президенты И.Большаков, Зур театр солисткасы Т.Ерастова, шулай ук Санкт-Петербургтан В.Черноморцев, Чувашстаннан В.Ивановның да килүләре көтелә. Әлбәттә инде, М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театрының танылган опера җырчылары чыгыш ясаячак.

Мәгърифәтче-галим күргәзмәсе

Казан дәүләт педагогия университетының гыйльми китапханәсендә мәгърифәтче-галим, Русиянең һәм Татарстанның атказанган укытучысы, халык мәгарифе отличнигы, республиканың Муса Җәлил исемендәге бүләге иясе Әнвәр Нуриәхмәт улы Хуҗиәхмәтовның күргәзмәсе ачылды. Әлеге күргәзмәдә галимнең соңгы елларда иҗат иткән әсәрләре — дәреслекләр, укыту-методик әсбаплар, публицистик язмалар җыентыклары урын алган. Алар арасында Русия Мәгариф министрлыгы уздырган конкурста беренче урынны алган, академиклар Габделхан Габдуллин, Җәмил Нигъмәтов белән берлектә иҗат ителгән «Мәктәп педагогикасы» дәреслеге дә бар.

Мәгълүм булганча, Әнвәр Хуҗиәхмәтовның исеме педагогларга да, халык мәгарифе органнары җитәкчеләренә дә, ата-аналарга да яхшы таныш. Казан дәүләт университетын тәмамлаганнан соң, ул шактый еллар Спас районының Яңа Рәҗәп урта мәктәбе директоры булып эшләде. Шул чорда әлеге мәктәп коллективы өч тапкыр Бөтенрусия, дүрт тапкыр республика буенча конкурсларда җиңеп чыкты, өч автомобиль, берничә йөк автомобиле, тракторлар белән бүләкләнде.

Соңрак тәҗрибәле педагогны, тынгысыз мәгърифәтчене Татарстан Халык мәгарифе министрлыгына бүлек белән җитәкчелек итәргә чакырдылар. Шул ук вакытта ул күпкырлы җәмәгать эшчәнлеге алып бару белән бергә, фәнни-тикшеренү эшенә дә зур игътибар бирде, аспирантура тәмамлап, фәнни дәрәҗәләргә иреште. Соңгы елларда аның берничә дистә китабы дөнья күрде, ул шулай ук урыс мәктәпләре өчен татар әдәбияты дәреслекләренең авторы да. Педагогия институтлары һәм училищелары өчен махсус эшләнгән дәреслекләр һәм методик кулланмалар, халык мәгарифен оештыручылар өчен эшкәртмәләр, тәрбия теориясе буенча лекцияләр курсы — боларның барысы да мәгърифәтче-галим Әнвәр Хуҗиәхмәтовның гаҗәеп тырыш хезмәте нәтиҗәсе.

Казан яңадан Галимовларны каршыларга әзерләнә

Башкортстанда туып үскән талантлы милләттәшләребез соңгы вакытта республикабызда еш кунак була. Алар мәркәзебезгә, милләттәшләре янына дулкынланып, сагынып киләләр. 4 декабрьдә К.Тинчурин исемендәге Татар драма һәм комедия театрында Башкортстан композиторы Васил Галимовның иҗат кичәсе уздырыла. Анда Башкортстанның мәшһүр шагыйре Наҗар Нәҗми дә катнашыр дип көтелә. Кичәдә җырчылар Айдар Галимов, Зөфәр Билалов, Зөйнәп Фәрхетдинова, Зөһрә Сәхабиева, Наил Шәймәрданов, Роза Хәбибуллина, Гали Хәмзин композитор иҗат иткән җырларны башкарачак.

Очып кайткандай булыр

...Яшьлегемә кайтыр идем
атларда чабып кына...

Бу җырны Сөләйман Йосыпов аеруча яратып башкара. Шушы көннәрдә Сөләйман ага яшьлегенә, чабып кына түгел, очып кайткандай булыр әле. 10 ноябрьдә «Казан» милли мәдәният үзәгендә җырчыга 70 яшь тулу уңаеннан кичә уздырыла. Бу көнне биредә Сөләйман аганың туганнары, хезмәттәшләре, чордашлары, якташлары, яшь җырчылар җыела. Кичәгә Теләче районының Алан авылыннан кунаклар, «Карамай», «Тасма» акционерлык җәмгыятьләре җитәкчеләре, Зөйнәп Хәйруллина, Җәүдәт Айдаров, Габделхак Шаһиев, Җәваһирә Сәлахова кебек ветераннар килер дип көтелә.

Китапчылар тәҗрибә уртаклаша

— Дуслыкны сакларга, үзара киңәшеп эшләүне алга таба да дәвам итәргә!

Республика китап палатасына хезмәттәшләре янына тәҗрибә уртаклашырга килгән Башкортстан кунакларының уртак теләге әнә шундый булды.

Татар белән башкорт гомер-гомергә тугандаш халыклар, ут-күршеләр булып яшәгән. Ике милләт тә бер-берсенә юлны өзмәгән.

— Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев Башкортстанның дәүләт мөстәкыйльлеге турында Декларация кабул ителүгә 5 ел тулу уңаеннан уздырылган бәйрәмгә килгәч әйткәнчә, телләребез аша аңлашабыз, бер җырны җырлыйбыз бит без, — диде Башкортстан китап палатасы директоры Ләлә Кәлим кызы Иксанова. — Без Татарстан китап палатасы директоры Роза ханым Хананова белән Мәскәүдә уздырылган директорлар киңәшмәсендә очрашкан идек, шуннан бирле элемтәне югалтмадык.

Ике республиканың китап палатасы җитәкчеләре, хезмәткәрләре бу көнне үзара тәҗрибә уртаклашу максатыннан конференция уздырды, эшнең оештырылышы, уңышлары турында фикер алышты, бер-берсенең хезмәтләре белән танышты. Үрнәк итәрдәй, түргә менгереп күрсәтердәй уңышлары күп булып чыкты аларның. Башкортстан кунакларына хезмәттәшләренең эшне үтә дә җыйнак, пөхтә, җентекле, әзлекле алып барулары аеруча ошады. Алар эшнең оештырылуында да, методик формаларда да отышлы эш алымнарын күрделәр. Үзләрендә дә бу уңай алымнарны кулланачакларын әйттеләр, хезмәттәшләренең өлгерлегенә сокландылар. Кунаклар китапларны саклау шартларының тиешле таләпләргә җавап бирмәвенә борчылу да белдерделәр. Башкортстанда архивның тиздән яңа бинага күчәчәге, заманча җиһазлар алулары турында сөенеп сөйләделәр.

● (Сулдан уңга) Татарстан китап палатасы мөхәррире Миләүшә Шакирова, Татарстан китап палатасы директоры Роза Хананова, Башкортстаннан китап палатасы директоры Ләлә Иксанова, архив-белешмә бүлеге мөдире Зилә Едих, библиография бүлеге мөдире Айгөл Хәкимова.

Акыртып алдыйлар — шым гына таланабыз

Сәүдә, товарларның сыйфаты һәм кулланучыларның хокукларын яклау буенча дәүләт инспекциясе идарәсе хезмәткәрләре кибетләргә һәм җәмәгать туклануы предприятиеләренә чираттагы рейд үткәрделәр.

Соңгы вакытларда Казанда үзбәк аш-сулары белән мавыга башладылар. Мавыгуын-мавыгалар, әмма... Мәсәлән, «Руслан» кафесында (ул Киров исемендәге мәдәният сараенда урнашкан) бер порция манты 7088 сум тора-торуын, әмма аның 81 проценты бары суганнан гына гыйбарәт. Касса аппаратыннан башка сәүдә иткәннәре өчен әлеге кафе хезмәткәрләрен салым инспекциясе берничә тапкыр штрафка тарткан иде инде, әмма биредә һаман да кисәтүләргә колак салмыйлар. Гомумән, тикшерелгән 28 кибет һәм киоскның 20сендә касса аппараты юк.

«Татарстан» кунакханәсе кафесында исә ризыкны әзерләү технологиясе бозыла. Мәсәлән, бер порциясе 2587 сум торган ит ассортиена татлы борыч, сельдерей җитешми, ә кыяр исә чистартылмыйча салына. Нәтиҗәдә ризыкның порциясе 890 сумга арзанрак булырга тиеш. «Табигать бүләкләре» ресторанында да шундый ук хәл күзәтелде.

Сертификат кәнфит, печеньега гына түгел, ә тавык йомыркасына да булырга тиеш. 553 нче кибеттә Лаеш кошчылык фабрикасыннан китерелгән йомыркага сертификат та, ветеринар белешмәсе дә булмавы ачыкланды. Әлеге кибеттә һәм шулай ук ит комбинатының 4 нче кибетендә колбаса, ит әйберләрен саклау технологиясе бозыла. Кибет җитәкчеләре бу хәлнең күңелсез тәмамланырга мөмкин булуы хакында уйлап та карамыйлар, ахрысы.

Тукаев дигән рәссам да бар...

Күптән түгел башкалабызның М. Горький исемендәге музеенда запастагы майор, үзешчән рәссам Камил Тукаевның шәхси күргәзмәсе булды. Күргәзмәгә авторның төрле елларда ясалган әсәрләре куелган иде.

Камил абый рәссам булырмын дип һич тә уйламаган. Заводта эшләгән, авиация институтында, марксизм-ленинизм университетында укыган, 26 ел гомерен хәрби хезмәткә багышлаган.

Буш вакытларында ул кулына кәгазь-каләм, буяу алып, рәсем ясаган. Солдатларның ялга туктап гармун сузуларын да, шахмат уйнап анекдот сөйләүләрен дә...

Инде менә хәзер аның картиналары шәһәребезнең төрле мәдәният сарайларында, Рәссамнар берлегенең зур күргәзмәләр залында бүтән талантлы рәссамнарның хезмәтләре арасында урын алды, белгечләр тарафыннан да, тамашачы тарафыннан да югары бәяләнә башлады. Ә «Фронттан хат», «Монда каты сугышлар булган» дигән ике картинасы Мәскәүдәге «1941-1945 еллардагы Бөек Ватан сугышы» дигән музей каталогына кертелеп, шунда саклауга куелды.

Ак булып, саф булып истә калсын Казанның кадерле кичләре...

1 ноябрьдә бу сүзләрне, бу көйне хәтерләгән бик күпләр, Сара ханым Садыйкованың кабере алдында баш ияр өчен, татар зиратына барды. Ләкин әле аңынчы, инде без хәбәр иткәнчә, 27 октябрьдә, «Мәдәни җомга» гәзите һәм Сара Садыйкованың хәйрия фонды редакциядә аның быелгы беренче табынын оештырды. Әлеге мәҗлес-табынның хуҗабикәсе, белгәнебезчә, танылган шагыйрә — Гөлшат Зәйнашева, фонд идарәсе рәисе — Әзһәр Хөсәенов.

Быелгы, алтынчы табынның нәкъ менә «Мәдәни җомга» гәзите редакциясендә узуы да гаҗәп түгел. Сәнгать әһелләре, язучылар-шагыйрьләр, композиторлар-музыкантлар, җырчылар-биючеләр монда җыела...

Мәшһүр композиторыбыз Сара Садыйкованың бу табынында Татарстан Президенты аппараты җитәкчесе Хәләф Низамов, Татарстанның халык артисткасы, опера солисты Рәйсә Билалова, язучы Әхсән Баян, нәфис сүз остасы, Татарстанның халык артисты Айрат Арсланов, шагыйрә Лена Шагыйрьҗан, Сара ханым хакында бик җылы истәлекләр белүче ветеран Рифкать Исмәгыйлев, әле күптән түгел генә мәрхүм булган күренекле шагыйрь Шәриф Бикколның хатыны Рәйсә Бикколова, галим Нурмөхәммәт Хисамов, «Мәдәни җомга» гәзитенең баш мөхәррире, шагыйрь Зиннур Мансуров һәм башкалар катнашты.

Алдагы саннарның берсендә без мәҗлес-табында яңгыраган чыгышлар белән киңрәк таныштырырбыз.

Шамил АБДЮШЕВ фотосы.

Мөхәммәт МӘҺДИЕВ

Мин сине көтәм, көтәм, көтәм...

(«Бәхилләшү» исемле моңсу повестьтан өзек)

... Танго кичәсе үткәндә, н уртасында нииндидер бер ызы район үзәгендәге курныч бер оешманың ишеген ккан һәм, имеш, уч төбе дәрле бер кәгазь калдырн: «Тел турындагы шундый әмиятле бер сөйләшүдән ң район клубында яшьләршул җыелышның әһәмиян аңлатасы урында пленй Әхәт Яһүдин намуссыз вештә бию оештырды, ханы белән икесе парлап ырлый-җырлый биеделәр, тен көннең авторитетына керделәр. Чын коммунист». Хәтерлим: бик озак хәбәрз торганнан соң, Өммеһани а елый-елый ябыгып, тарлып, йомылып беткәннән ң, ике ел үткәч кенә Әхәтн бер хат килде. Төгәлрәге, яндыр, каядыр узучы бер зый, Исламгали агайның нә кереп тә тормыйча, чонан гына бер хат биреп гә. Әйбер төрә торган сары газьгә карандаш белән ылган, конверты кулдан ясалган, пешкән бәрәңге белән ябыштырылган. Өммеһанига...

«Сөеклем Майя!

Син миңа рәнҗемә инде. Син минем бәхетем идең. Мин бик еракта. Безгә хат язышу тыелган. Әйттеләр: бу урын — сезгә мәңгелек, диделәр. Монда хатын-кызлар да бар. Теләгәнегез гаилә корыгыз, диделәр. Кайту, кавышу беркайчан да булмаячак, диделәр. Син акыллы, чибәр, яшь әле. Үзеңә тиңнәрне табарсың. Мин сиңа моны рөхсәт итәм. Син дә миңа рәнҗемә, мин дә шулай — сиңа тиңен таба алмасам да, картаеп түшәккә егылгач җан биргәндә авызыма су тидерергә тиешле берәр хатынга өйләнермен инде. Безнең безнең дә гаеп юк бит! Без ник бу хәлгә калдык? Башым җитми. Әти сөйли торган иде: күгәрчен күченә козгын җитәкче булса, бөтен күгәрчен дә үләксә ашый башлар, дип.

Син мине гафу ит, мин сиңа бәхет китерә алмадым. Хуш, бәхил бул, җаныкаем. Бу җырларны, әгәр яңа иреңнән бала тапсаң, аны бишектә тирбәткәндә җырларсың:

Еракларда күренеп тора
Эсвирлау дигән кала.
Иленнән сөреләмени
Бәхетле булган бала?
Кулларыма алдым яулык,
Җилгә чыгып болгадым;
Тыныч торган дөньяларны
Кайгым белән чолгадым.

Хәтерлисеңме? Соңгы кичне без тангога биегән идек. «Син кайларда йөрисең икән?» Ул бит безнең татар халкының беренче тангосы. Аны җырчы Сара Садыйкова иҗат иткән. Ул тангода бит гел сагыш тавышы. Ләкин мин андагы сүзләрне кабатлый алмыйм инде: «Кавышырбыз дип мин өмет итәм...» Юк, без кавышмыйбыз инде. Хуш, бәхил бул, бәхетем, бердәнберем минем».

Исламгали агай бу хатны үзендә саклый. Майя шулай рөхсәт иткән...

Әхмәт ЕРИКӘЙ

Көтәм сине

Син кайларда йөрисең икән,
Алтыным, көләч йөзле иркәм.
Кайтырсың дип мин өмет итәм,
Мин синә һаман көтәм, көтәм.
Сагыналар сине матур кошлар,
Сагыналар сине якын дуслар.
Күңелем эзли сине кич-иртән,
Мин сине һаман сагынып көтәм
Китмисең минем йөрәгемнән,
Төшмисең минем телләремнән.
Көн саен, сәгать саен, иркәм,
Мин сине һаман көтәм, көтәм.
Кайт, иркәм, тизрәк-тизрәк миңа,
Синнән башка юк тормыш миңа.
«Көт, иркәм, кайтам», — дигән сүзең
Музыка төсле тоела миңа.



Итальяннар татар моңын аягүрә алкышлады

Халыкара баянчылар нкурсы ел саен Италияе Костельфидердо шәһәрендә уздырыла. Аны штыручылар — моннан еллар элек ачылган кордеон фабрикасы, шәһәр департаменты һәм бай рмалар. Италиягә юлны ннан ике ел Казан консерваториясе профессоры укәт Әмиров салып, ан-при алып кайткан . Узган ел андый бүләкбаянчы Әбүзәр Фәйзулһәм балалайкачы Рак Таҗетдинов лаек булБыел халыкара конска өч коллектив — консерваториядән милли уен аллары оркестры (җинесе Ринат Халитов), рприз-квинтет» һәм е сәнгать академиясе «Алтын өтөч» (Людми-Әмирова) балалар коллтивы барды. алыкара конкурс ике егориядә — җиңел һәм классик музыка буенча егермеләп төрдә соло, дуэт, ансамбль, оркестрлар чыгышлары, катнаш уен коралларында уйнаучылар һ.б. буенча үткәрелә.

Греция, Бразилия, Испания, Югославия, Польша, Чехословакия, Украина, Беларусь, Русиянең бик күп төбәкләреннән иң яхшы музыкантлар арасыннан Италия тамашачылары бу юлы да өстенлекне Казан музыкантларына бирде. Милли уен кораллары оркестры Гран-при, «Сюрприз-квинтет» 3 нче урынга лаек булды. Татарстанның халык артисты Владимир Федотов һәм консерватория студенты Шамил Авдеевлар диплом алып кайтты. Шунысы кызык, «Самбо», «Румба» кебек халык көйләрен татарлар бразилиялеләрнең үзләреннән дә шәбрәк итеп уйнап күрсәттеләр. «Ай былбылым», «Әпипә», «Бишле бию»ләрне поляклар татардан әйбәтрәк уйнаса, оят булыр иде, әлбәттә.

Шулай да конкурста шау-шу, гаҗәпләнү һәм соклану тудырган коллектив — «Алтын өтөч» балалар ансамбле була.

— Без ике категориядә — җиңел һәм классик музыка буенча чыгыш ясадык, — ди ансамбль җитәкчесе Людмила Әмирова. — Җиңел музыка буенча тугыз балалар коллективы арасында без беренче булдык. Ә менә икенче категориядә безне ни өчендер профессиональ музыкантлар белән ярыштырдылар. «Скиф»та, мәсәлән, Әстерхан консерваториясе профессорлары һәм доцентлары чыгыш ясады, ә минем балалар — музыка мәктәбенең 3-4 нче сыйныф укучылары. Кубыз тавышларын беренче тапкыр ишеткән жюри әгъзалары үрелеп-үрелеп карадылар, ә зал аягүрә алкышлады. Бу конкурста без алтынчы урынга лаек булдык. Уникe профессиональ коллектив арасында музыка мәктәбе укучыларының алтынчы урынга чыгуына мин Казанга кайтканчы ышанмадым. Безнең чыгышны шулкадәр яраттылар, милли көйләребезне итальяннар чүлдә сусаган мосафир шикелле кабул иттеләр, — дип куана-куана сөйләде Людмила Александровна.

Әмма... халыкара конкурста шундый зур уңышка ирешкән сигез кешелек коллективны Казанда чүп урынына да күрмиләр шикелле. Кече сәнгать академиясе Вахитов район мәгариф бүлегенә карый. Алар шөгыльләнгән бинаны Финанс министрлыгы тартып ала, ә Людмила Александровна балаларны үз өенә чакырып... халыкара конкурска әзерли. Хәзер дә шөгыльләнер урыннары юк, кече сәнгать академиясенә тәгаенләнгән бина ремонтта, ә аның очы-кырые күренми әле. Балалар шөгыльләнгән бинаны тартып алырга кулыннан килгән Финанс министрлыгының кече сәнгать академиясенә бирелергә тиешле бинаны алдан ук ремонтлап куярга да хәленнән килгән булыр иде бит, югыйсә. Нихәл итәсең, көчленеке замана! Искечә яшәргә теләмибез, капиталист булырга хәлдән килми.

Рәсимә СИБГАТУЛЛИНА.

Мәсгудә ШӘМСЕТДИНОВА:

«Швециядә бер генә проблема бар — проблемасызлык»

— **Татар композиторлары арасыннан Швециягә бару сөенечә ни өчен бер Мәсгудә ханымга гына тәтеде икән?**

— 1989 елда мин Варшавада Швеция дәүләт радио компаниясенең музыка бүлеге мөхәррире Фолке Рабе белән танышкан идем һәм ул минем «Изге Болгар дастаны» исемле әсәрем нигезен-

дә 1990 елда Швеция радиосында бер тапшыру эшләде. Шуннан соң Швеция радиосы татар музыкасы белән ныклап кызыксына башлады. Фолке әфәнде Татарстанга килеп, Тәтеш, Балык Бистәсе төбәкләрендә татар халкының борынгы көйләрен җыеп йөрде.

һәм, ниһаять, быел Фолке Рабенең шәкерте. ярдәмчесе Матс Эйнарссон Чаллы, Зәй. Мамадыш, Алабуга ягындагы керәшен авылларында йөреп. бик күп җырлар язып алды Тәтеш экспедициясеннән соң Швеция радиосы бөтен дөньяга биш сәгатьлек тапшыру эшләгән иде Соңгы экспедиция, алар әйтүенчә. җиде-сигез сәгатьлек тапшыруга нигез булачак Ул тапшыруларны янә сорап егерме-ләп илдән Швеция радиосына заказлар килгән Мин һәр экспедициядә дә аларга кадәри хәл ярдәм иттем һәм Швециягә чакыру алдым.

— **Татарлар турында Швеция кешеләренең мәгълүматы ни дәрәҗәдә?**

— Алар бит татарларны чи ит ашый торган кыргый халык дип белә, менә үзләре берничә тапкыр килеп карагач. көнкүрешебезне, мәдәниятебезне өйрәнә башлагач, фикерләре үзгәрде.

— **Син Швециягә ни белән бардың — нинди уй, нинди бүләк белән дигәндәй?..**

— Шөбһә белән бардым. Аурупа Мәсгудә Шәмсетдинова атлы бер татар композиторының иҗатын аңлармы. кабул итәрме? «И Адәм балалары» исемле кантата-риваять үзем дә көтмәгәнчә зур уңыш казанды. Ул өч тапкыр башкарылды.

— **Швециядә тормышлар ничек соң?**

— Сорашма! Сөйләсәм — көенең китәр. Аларда бер генә чишелмәгән проблема бар — проблемасызлык Безнең кайгылар аларда күптән юк.

— **Шундый мул вә бәхетле илдә калырга теләгең булмадымы?**

— Мин шундый гүзәл ил корган швед халкына сокландым һәм, безнең тырыш татар халкы белән дә шундый ил төзеп була, дигән фикер белән кайттым. Аларда байлыкны күрсәтә беләләр. Бездә алтын тирес астында ята.

— **Анда барып кайтуың иҗатыңа нинди тәэсир ясар икән?**

— Моңа кадәр мин шикләнеп, икеләнеп иҗат иттем, чөнки иҗатымны һөнәрдәшләрем, иптәшләрем арасында шик астына куючылар да аз түгел. Хәзер мин беләм: минем үз юлым дөрес икән. мин икеләнүләремне читкә куеп иҗат итәчәкмен.

— **Татарлар белән очрашулар булдымы?**

— Татарлар арасында йөри торгач, мин Ана Телемне шома[рып] кайттым, чонки минем я[нга] килүче татарлар саф татар тел[ендә] дә сөйләшә. Финляндиядән к[үч]кән татарлар бар, үзебезнең [як] татары Мөхәммәд абый белән д[ә] күрештем, ул Добъяз ягын[нан]

— Чыршы авылыннан Аңа бер [у]туган як туфрагы алып бард[ым] Иң зур бүләгем шул булды Музы[ка], җыр белән тулы кассетала[рны] да алган идем. Аларны тыңлага[ч] да кардәшләрнең күзендә кайна[р] яшь иде Түркәр Суыккан исемл[е] бер мәһабәт татар яши Стокгол[ь]мда, аның әнисе Әминә ханы[м] кызы Ләйлә ханым белән күре[ш]тем. Алардан Галимҗан Идриси[]нең җырларын язып алдым. Ә[нә] шул Идрисинең улы Илдар исе[м]ле Муса Җәлил янына барып йөрүч[е] егет шул булган, диләр.

— **Швециядә татарлар ниче[к] яши?**

— Иркен яши. Алар бишәр-а[лты]шар тел белә. Баягы Мөхәммәд абыйның улы Наил АКШта эшл[и] икән, ике йөз кешегә эш бирә, үзе дә әүкатле.

— **Алга табаниләр майтарырга уйлыйсың, Мәсгудә ханым?**

— Тукайга кагылышлы бик к[үп] музыкаль фольклор бар минд[ә]. Аларга тотынасым бар. Аннар[ы] үзеңә сер итеп кенә әйтәм: Те[л], әдәбият һәм тарих институтын[ың] аспирантурасына имтихан тотарга исәпләп торам

— **Кайсы бүлеккә?**

— Философия бүлегенә.

— **Музыка һәм философия — кызык берләшмә!**

— Алай гына да түгел, динне д[ә] тирәнтен өйрәнәчәкмен, иншалла[һ]. Татар халкының дини бәйрәмн[ә]рендәге музыкасы мине нык кызыксындыра.

Әңгәмәне **АЛТАТАР** әзерләд[е]

БЕЗГӘ КУНАК КИЛДЕ

Мәскәүдә калыккан «Изге Ай»

Соңгы елларда милли эстрада күгендә бик күп йолдызлар кабынды. Мәркәзебез Казанда, аннан читтә эшләп килүче дистәләгән ансамбльләр зәвык белән җыелган чәчәкләр бәйләмен хәтерләтә. Аңа әледән-әле яңалары өстәлеп тора. Һәр чәчкә үзенчә матур, үзенчә кабатланмас, һәркайсының үз моңы, үз аһәңе. Татар теле чәчәкле тел булса, татар җыр-музыка дөньясы чәчәкле болын ул. Моннан биш ел элек бу болында тагын бер чәчкә пәйда булды. Ул — Мәскәүдәге «Изге Ай» татар ансамбле. Кыска гына вакыт эчендә ансамбль Русия татарлары арасында гына түгел, Казан тамашачылары арасында да танылып өлгерде. Ансамбльне һәвәскәр шагыйрь һәм композитор Р.Кузнецов җитәкли. Ул репертуардагы барча җырларны да үзе иҗат итә. Шуның өстенә, Равил бер дигән музыкант та. Җырчы Халидә Бигичева исә ансамбльнең җаны. Чөнки ул тамашачы алдына һәр җырны йөрәге аша үткәреп чыга, шул җырлардагы хисне, моңны түкми-чәчми аның күңеленә ирештерә. Һәм менә Равил белән Халидә тагын Казанда. 6-7 ноябрьдә алар «Уникс» мәдәният-спорт комплексының тамаша залында чыгыш ясаячак.

— **Равил, синең «Үпкәләмә, бәгърем, үпкәләмә». «Сагыш», «Авылым кызы» дигән җырларыңны тыңлагач. чыннан да, татар эстрадасы күгендә «Изге Ай» калыкканына төгаен ышанасың. Бу ансамбль ничек туды?**

Алабуга мәдәни-агарту училищесын тәмамлагач мин Мәскәүдә төрле урыс ансамбльләрендә уйнап йөрдем Шулай бервакыт мин уйга калдым Туктале мәйтәм нигә дип урыс ансамблендә уйнарга тиеш әле мин? Татар ансамбле оештырсаң, милләткә дә файда булыр үземнең дә йөрәк мүкләнмәс иде Шуның өстенә күңел һаман туган телгә милли моңга тарта Мин инде кечкенәдән шигырьләр җырлар язарга хыяллана идем һәм көннәрдән бер көнне бөтен эшемне ташлап татлы иҗат дөньясына чумдым Әлбәттә. тәүге җырлар бик җиңел генә тумады Ләкин сабыр төбе — сары алтын дигәндәй тора-бара барысы да җайланды, эчке сиземләү дигән нәрсә барлыкка килде Мин тамашачымны иң зур хөкемдарым дип саныйм Әгәр җырым тамашачыга ошамаса. аны кат-кат эшкәртәм бизим үстерәм Халидә белән танышып киткәч эшләр тагын да алга китте Ул — чын эрудит Көйдә яисә шигырьдә берәр кимчелек булса шундук тәнкыйть уты яудыра башлый Мондый вакытларда мин үземне бәхетле кеше итеп саныйм Тормышта гына түгел иҗатта да бергә без

— **Халидә, сиңа Равил язган җырлар ошыймы?**

— Әлбәттә Ошамаса мин аларны җырлар идем мени? Без бер-беребезне ярты сүздән аңлыйбыз Ничек шулай туры килгәндер. тормышка гына түгел дөньяга музыкага һәм шигърияткә булган карашларыбыз да уртак Шулай да кайбер вакытларда бәхәсләшеп алабыз Мондый бәхәсләрне тамашачы хәл итә чөнки читтән барысы да яхшырак күренә бит

— **Равил, сез Русиянең бик күп шәһәрләрендә чыгыш ясадыгыз. Төбәк төбәктән, халык халыктан аерыла дигәндәй, тамашачы да бөтен җирдә бертөсле түгел бит. Сез аеруча кайсы төбәк тамашачысын якын күрәсез?**

— Тамашачыларның барысы да якын инде Шулай да үзең әйтмешли. тамашачы белән тамашачы арасында аерма зур Мәсәлән. Түбән Новгород, Төмән шәһәрләрендә яшәүче татарлар тамаша барганда искиткеч җылы сүзләр язып җибәрәләр Аларда туган җирне. туган телне сагыну күренеп тора. Һәм бу аңлашыла да Чит җирдә ана телендә яңгыраган җыр аеруча кадерле, якын була икән ул Ә менә Казан тамашачысы бөтенләй башка. Ул инде синең җырыңны бүтән җырлар белән чагыштыра, нәтиҗә ясый. Казан тамашачысы татар мәдәниятенең казанында кайный бит Аны аннан-моннан гына язылган җырлар белән алдап булмый.

— **Ә син ничек уйлыйсың, Халидә?**

— Равилнең фикере белән килешәм Казан тамашачысы гади тамашачы түгел Карый, уйлана, фикерли Ни дисәң дә, читтәге татарлар кебек, елына бер генә концерт карамый бит ул Тәҗрибәсе дә зәвыгы да бар Шуңа күрә без аны аеруча якын итәбез аңа ышанабыз

— **Халидә, синең яраткан җырчыларың бармы?**

— Беләсеңме мин кечкенәдән Илһам Шакиров моңына гашыйк Әлфия Афзалованы да иң якты йолдызларыбызның берсе дип саныйм Бу ике шәхестән башка татар җыр сәнгатен күз алдына да китерү мөмкин түгел Хәер, бу минем генә фикер түгел күпләр шулай уйлый.

— **Сезнең иҗат юлында нинди дә булса киртәләр, авырлыклар булдымы?**

— Булды, әлбәттә Бу турыда Равил сөйләс[ен] инде

— Безне, гадәттә, мишәрчә җырлауда гаепли[ләр] иде Шунлыктан Казанда ансамблебезгә юл бире[рге] гә теләмәүчеләр дә булды Мишәр булып туга[ч] мишәрчә җырламыйча нишлисең инде. Татарда м[и]шәрләр дә шактый бит. Мәсәлән, Пинҗә, Түб[ән] Новгород, Сергач, Әлки, Чистай мишәрләре ... Ни[гә] дип әле без үз шивәбездән куркырга, баш тартырга тиеш? Аннары мин мишәр сөйләмен ямьсез ди[ми]дем. Аның да үзенә генә хас сурәтләү чаралары, нәфислеге бар Әнә, Финляндиядәге бер ми[шәр] ансамбле тәлинкә дә чыгарды инде. Яратып, с[о]кланып тыңлыйлар үзләрен. Җыеп кына әйткәндә татарны сортларга бүлүчеләрне өнәмим мин. Без барыбыз да бер халыкка, бер мәдәниятке хе[змәт] итәбез Әгәр нинди дә булса авазларны һәм сүзләр[]не икенче төрлерәк әйтәбез икән, монда бер [дә] хафаланырлык нәрсә юк.

— **Урамда көз. Син, Халидә, елның кайсы фа[]сылын күбрәк яратасың?**

— Елның барча фасыллары да матур Шулай да көзне күбрәк яратам Чөнки агачлар яфрак кой[ган]чорда фәлсәфи уйлар, матур көйләр күбрәк ту[а]. Синең ал, кызыл, сары яфраклардан букет яса[га]ның бармы?

— **Балачакта гына булса инде... Ә син, Рави[л], кайсы фасылны яратасың?**

— Эшләр тауга барганда хәтта иң сазлы-пычра[к] көз дә яраттыра Ә менә күңел төшенкелегенә б[ир]елсәм, гел язны сагынам Туган якка кайта тор[ган] кошлар белән үз-үзеңә булган ышаныч, өметләр [дә] кайтыр сыман

— **Ансамбльнең исеме ничек туды?**

— Безнең ансамбльнең барлыкка килү вакы[ты] Сөембикә манарасына ай куйган чорга туры ки[лде]. Шул хөрмәткә ансамбльгә «Изге Ай» дигән ис[ем] бирдек Бу исем үзебезгә дә, тамашачыга да [бик] ошый.

— **Халидә, бу сорау инде сиңа булыр. Яңа җыр[]ларың язылган өченче тасмаң Казан киосклар[ы]на кайчан чыгар икән?**

— Берничә айдан алар тамашачыга барып ир[е]шер, дип уйлыйм Әгәр безнең яңа җырларны и[шет]терге теләсәгез, «Уникс»ка килегез

— **«Мәдәни җомга» газетә укучыларына ни[нди] теләкләр теләр идең?**

— Әлеге яңа басманы Мәскәүдә яшәүче ка[йбер] татарлар да алдыра Быел аңа без дә язылыр[га] уйлыйбыз Ник дигәндә мәркәзебез Казан тор[мы]шын, андагы сәяси, икътисади һәм мәдәни ва[кый]галарны бик тәфсилләп яктыртып бара ул

— **Ә син, Равил, нинди теләкләр теләр идең?**

— «Мәдәни җомга» газетен бер тапкыр кул[ыңа] алып караган кеше, аны алга таба да укымый [] түзә алмас дип уйлыйм мин Татарстанның үз[ендә] генә түгел, аннан читтә яшәүче милләттәшләребез арасында да укучыларыгыз күп булсын!

Әңгәмәне Зәһид МӘХМҮДИ алып бар[ды]

ШАГЫЙРЬ НЕЧКӘЛЕК БИЛГЕСЕ БЕЛӘН ЯЗЫЛА

Гөлшат ЗӘЙНАШЕВА

Ник яна соң бу йөрәгем...

«Әгәр җырым аңлашылмас булса,
Минә балаң итеп санама...»
Язып куям ак кәгазь битенә,
Әйтер сүзем шул Җир-Анама.

* * *

Кәкрәне төзәтергә тырыштым —
Сынды кәкрем.
Үзем кәкрәеп калдым,
Чыкты бөкрем.

* * *

«Ни хәл? — дисең, — ничек яшәү?..»
Шулай яшим хәзергә:
Дулкын ярга бәреп атҗан
Ярык коймә хәлендә...

* * *

Ач кешегә май кунмас,
Ашап гамагы туймас.
Социаль рәнҗетмә —
Социаль яклыйсы булмас.

* * *

Тәрәз төбемдә гөлем бар,
Күчереп утыртсам — сула.
Йөрәгем шул гөл яфрагы —
Ерак калса ил туфрагы —
Өзелеп төшәрдәй була.

* * *

Чит илләрдә чит тау-ташлар,
Адаша язды башлар.
Каберең ташы булыйм, дип,
Дәшә кебек шул ташлар.

* * *

Вәгъдә бирсәм, вәгъдәм үтим,
Әйткән сүздән кайтмыймын.
Дошманнарымнан үч алмыйм,
Дусларымны сатмыймын.

* * *

Гомере аның кинәт бетте,
Өзелгән чылбыр сыман.
Иң матур җирендә кинәт
Өзелгән бер җыр сыман.

* * *

Совет чорын сүгеп, эч бушаттык,
Бушап калды ашказаннар.
Кайсы чорга алып бара илне
Сәясәттә юлдан язганнар?..

* * *

Агымнарга каршы йөз син,
Агып барма үз җаеңа.
Үлгән балыклар гына бит
Йөзә агым уңаена.

* * *

Балыксыз бер күл кебек мин,
Чәчәксез болын кебек.
Карурманда адаштырып,
Калдырган колын кебек.

* * *

Җиңел түгел, авыр иде үткән заман,
Матур әкият кебек иде коткән заман.
Котырган эт кебек үсә бүген бәя,
Бер кап шырпы мең тәңкәгә җиткән заман.

* * *

Упкын аръягында икән бәхетем,
Үзе килер диеп ник йөрим?..
Төшсәм, төшим упкын уртасына,
Бәхетемә таба сикерим!..

* * *

Сандугачлар тынгач, әрәмәне
Баса икән кара каргалар.
Кара карга кебек кайгылар да
Кешеләргә шулай каныгалар.

* * *

Тәнең, җаның бергә сыкрап сызланганда,
Ак халатлы табибларга барасыңдыр.
Ак халатлы табибларга бару кирәк,
Ак каенга хәлең сөйләп кара син бер...

* * *

Җылы өйдә ялгыз гына утырганчы,
Бураннарда синең белән йөрсәм идә.
Кайгы килсә, ялгызым да күтәрермен,
Шатлыгымны синең белән бүлсәм идә.

* * *

Шатлыгымны сиңа бирәм,
Кайгыңны син миңа бир.
Алдашсам, мине кичермә,
Ә ялгышсам, аңлый күр.

* * *

Әллә юрган, әллә кәфен —
Уралганмын ап-акка.
Әллә йоклыйм, әллә үләм,
Үлсәм бүген, шаккатма.

* * *

Сүзсез генә аңла мине,
Нигә син ялгыз,димә.
Мәңге төзәлмәс ярама,
Җәрәхәтемә тимә.

* * *

Әнкәм тапкан, ләкин бакмаган,
Ана назы күрми үскәнмен.
Ятимлекнең салкын кочагына
Бишегемнән егылып төшкәнмен.

* * *

Тиң түгелгә кул бирдерттең,
Сөймәслекне сөйдерттең.
И яшьлегем, юләрлегем,
Нигә шулай тилерттең?..

* * *

Бәхет белән бәхетсезлек миңа
Бергә килә һаман нигәдер.
Бәхет кенә бирсә, күпсенәдер,
Язмыш миннән шулай көләдер.

* * *

Мәхәббәт күкләргә күтәрә,
Кешене канатлы итә.
Сүнсә, канатны сындырып,
Кайчак типкәләп йөртә.

* * *

Авырыйм тәннәр буена,
Ютәлләп, хырлап ятам.
Бәлки әле тазарырмын —
Хырылдап җырлап ятам.

* * *

Чибәрлеккә чамалы бит,
Ник аны сөйдең, диләр.
Сезгә чибәр күренмидер,
Минем өчен бик чибәр.

* * *

Ник яна соң бу йөрәгем,
Сүрелер микән, юк микән?
Йөрәгем урынында әллә
Бер йомарлам ут микән?..

* * *

Таш ята коеның төбендә,
Яшь ята күзнең түрендә.
Коә төбенә ташлар ташламыйк,
Кайгы килү белән җылый башламыйк.

* * *

Уза гомерем, шатлыгымны
Кайгылардан аралап.
Шатлык килдә, дип куансам,
Кайгы тора сагалап.

* * *

Бик яшь идек, ярлы идек,
Икебезгә идә бер мендәр.
Икебезгә иде бер юрган,
Иң бәхетле чагым шул булган.

* * *

Яшь бер хатын ирен ташлап китте,
Төенчеккә тойнәп язмышын.
Ник китәсең, дигәч, җавап бирде:
«Явызлыктан качып бармышым...»

* * *

Минем күңелем — тальян гармун,
Таң алдыннан моңая...
И яшьлегем, тальяныңны
Ташлап киттең син кая?..

* * *

Попугайның урыны биек залларда,
Былбылларның урыны бәдрә талларда.
Биек залда бер попугай булганчы,
Былбыл булып бер әремгә кунсамчы!..

* * *

Табигать бик гаҗәп көньякта,
Йөзем үсә ташлы туфракта.
Ташны ярып үсә, пешә йөзем,
Булсаң иде шундый чыдам, түзем!..

* * *

Сәүдә ит, булырсың, диләр
Алыпсатар, бизнесмен.
Сату түгел, сатып ала
Белмим хәзер мин мескен.

* * *

Шкаф хәтле ул үстердем,
Мактанырлык эшем юк —
Шкаф сатып алган идем,
Алып кайтыр кешем юк!

* * *

Бер җиңгидән сорыйм:
«Киленнән, — дим, — уңдыңмы, җиңги?»
«Уңдым, — ди, — егылып уңдым,
Теле — пычак, иреннәре — лизви!..»

* * *

Чәчә гайбәт, чәчә гайбәт,
Гомере уза чүбек чәйнәп.
Көн-төн мырлый, кеше хурлый,
Теле аның безразмерный!

* * *

Каш ясыйм дип, бер модный кыз,
Күзен чыгарган.
Икенчесе чәч ясыйм дип,
Мәгез чыгарган.

* * *

Матур җырларны гына
Отып ала минем халкым.
Начарларын тиз оныта,
Эчкерле түгел — белем холкым.

Әкиятне чынга әверелдерүчеләр

Казан дәүләт курчак театрының баш режиссеры **Илдус ЗИННУРОВ** белән әңгәмә.

— Казан дәүләт курчак театры үзенең 62 нче сезонын ачып җибәрде. Ә без, әйдәгез, сүзне узган сезоннан башлыйк әле. Ул ничек узды?

— Һәр юбилей — үткән эшләргә йомгак ясау, булган казанышларны барлау. алдагы елларга ниятләр кору ул Узган сезон чыннан да безнең өчен шундый ел булды Без тагын бер мәртәбә үткән тарихыбызга борылып карадык. хатирәләрне яңарттык Мәгълүм ки. Казан дәүләт курчак театры үзенең туүы белән Сергей Мерзляковка бурычлы Бу шәхес хакында әлегә аз беләбез Ул — Идел буе республикаларында курчак театры хәрәкәтенә нигез салган кеше С.Мерзляков Казанда I Интернациональ курчак театры төзегәннән соң, Чабаксар, Киров шәһәрләрендә шундый ук театрлар оештыра. соңрак Белоруссия башкаласында эшли Ул — күпкырлы оста. Артист. режиссер буларак, курчак театры сәнгатенең алтын фондына кереп калырдай әсәрләр, образлар иҗат иткән шәхес Киләсе елда Мерзляковның туүына 100 ел тулачак Казан театр җәмәгатьчелеге дә бу бәйрәмне зурлап билгеләп үтәргә җыена

— I Интернациональ театр дигәнне ничек аңларга?

— Эш шунда ки, театр оешканда ук аның составында урыс һәм татар телләрендә спектакльләр куючы труппалар була. Әйтергә кирәк. безнең театр бүген дә бу исемгә тугры булып яши. Хәзер дә сәхнәдә спектакльләр ике телдә бара Хәтта ки, Казан дәүләт курчак театрында ике мөстәкыйль театр бар, дип әйтергә мөмкин. Әмма бу театрларның биналары, җитәкчеләре генә түгел, мәнфәгатьләре, хыял-ниятләре, проблемалары да бер үк. 60 ел — күп гомер түгел Ә шушы бер кеше гомеренә тиң вакытка күпме талантлы шәхесләрнең тормышы, иҗаты, бөеклеге сыйган Мәрьям Хисамова, Фуат Таһиров, Сәлах Хәсни, Вәли Гаффаров, Галия Таһирова, Сара Вәлиуллина — бу исемлекне озак дәвам итәргә булыр иде Миңа аларның күбесе белән бергә эшләргә насыйп итте Үземнең иҗат кыйбламны да шушы шәхесләр нигез салган традицияләргә карап билгеләдем

— Узган ел чит илләрдә дә булгалагансыз икән...

— Әйе. узган сезонда без Германиянең Брауншвейг шәһәрендә үткән XIII курчак театрлары фестивалендә катнаштык Бу гаять тә абруйлы фестивальгә БДБ илләре арасында беренче сукмакны без салдык, беренче чакыруны без алдык Быелның 22-27 октябрендә исә Төркиянең Адана шәһәрендә Бөтендөнья театр эшлеклеләре берләшмәсе (УНИМА) оештырган II халыкара традицион курчак театрлары фестивалендә катнаштык. Гомумән, УНИМА белән дус яшибез Дүрт елга бер мәртәбә була торган фестивальләрдән кала, Казан дәүләт курчак театры бу абруйлы оешма эшендә, аның конгресс-симпозиумнарында даими катнашып килә.

— Илдус әфәнде, быелгы сезонда тамашачыларны нинди спектакльләр белән сөендерәчәксез?

— Миннән бик еш сорыйлар. «Сез куйган әсәрләрнең күбесен шагыйрьләр язган Моның сере нидә?» — диләр Сере бар инде аның. Курчак театры сәнгате шигъриятькә бик якын тора, Эш спектакльләрнең шигъри текстларга, җыр-моңга бай булуында гына түгел, әлбәттә. Рухлары. асыл хасиятләре белән тугандаш алар Тирән образлылык. тәсмерлелек. романтика һәм үтә дә нечкә эмоциональ накал. Шуңа күрә дә бездә Зөлфәтнең әсәрләре бара Нәби Дәүли. Равил Бохараев, Гәрәй Рәхим. Ренат Харис, Рафис Корбан пьесалары куела. Быелгы репертуарда 27 әсәр бар.

Сезонны 19 октябрьдә С.Прокофьевның «Абау, крокодил!» әсәре белән башлап җибәрдек Аны урысчадан Зөлфәт тәрҗемә итте 21 октябрьдә икенче премьера — Д.Биссетның «Юлбарыс белән әңгәмә» дигән уен-тамашасы булды. Бу спектакльне сәхнәгә Л.Дьяченко куйды (рәссамы А.Губский) Ноябрьдә тагын бер премьера — Туфан Миңнуллинның «Укытты бүре сабак» исемле әсәре сәхнәгә менәчәк Язын тагын берничә әсәр сәхнәләштерәбез: татар халык авыз иҗаты мотивлары буенча тамаша, Лев Кожевниковның «Барабашка» әсәре һәм ГАИ заказы буенча эшләнгән «Яшел дулкын» спектакле.

— Узган елгы репертуардан нинди спектакльләр калды?

— В.Гауф әсәре буенча эшләнгән «Кечкенә Мук» спектаклен былтыр тамашачылар бик яраткан иде. Ул быелгы репертуарга төп әсәрләрнең берсе булып керә. Яңа сезонда нәни тамашачыларыбыз шулай ук «Морозко» (Л.Кожевников), «Кардагы мәче баласы» (К.Мешков, П.Катаев), «Кечкенә Убырлы карчык» (О.Пройслер), «Патша килене» (М.Гыйләҗев), «Ана күзләре» (И.Зиннуров), «Мөгезборын һәм Жираф» (Х.Гюнтер), «Тисту — нурлы бармаклы малай» (М.Дрюон), «Сикерүче принцесса» (Л.Дворский) һ.б. спектакльләрне карый алачак.

Татар телендә сәхнәләштерелгән һәм узган елда тамашачыларыбыз яратып калган спектакльләрнең дә берничәсен атап үтмәкче булам: «Җен кызы» (Зөлфәт), «Җырлап узган җәй» (Н.Дәүли), «Әтәчләрдән хәбәр килгән» (Г Остер), «Салават күпере» (Батулла), «Ат әреккән шомлы төн..» (Зөлфәт), «Гасырдан озын бу көн..» (Ч.Айтматов), «Куркуын җиңгән куян» (Р Корбан).

— Спектакльләр нигездә әкият мотивларына корылган һәм, әйтергә кирәк, аларның күбесе авылга йөз тотып куелган кебек...

— Репертуар төзегәндә без шәһәр тамашачысын да, авыл тамашачысын да бердәй искә алабыз Аннары, югары сәнгатьтә авыл һәм шәһәр төшенчәләре юк, ә Казан курчак театры бүгенге көндә югары сәнгатькә хезмәт итә, дип уйлыйм мин.

— Курчак театрларының төп тамашачысы — балалар. Бу репертуарның үзеннән үк күренеп тора. Әмма узган елларда театр өлкәннәр өчен дә спектакльләр куйгалый иде...

— Сез, әлбәттә, бу очракта Т Миңнуллинның «Диләфрүзгә дүрт кияү», Юныс Сафиуллинның «Кыямәт көне», Кәрим Тинчуринның «Хан кызы» кебек спектакльләрен күз уңында тотасыздыр Без киләчәктә дә бу юнәлешне саклап калырга уйлыйбыз Өлкәннәрнең ширма артындагы курчакларның ничек уйнап йөрүләрен карап утыруларын күрсәгез иде сез! Чын сәнгатьнең яше дә, милләте дә, чиге дә булмаганына шул вакытта янә бер ышанасың!

— Инде гастрольләр хакында да берничә сүз әйтсәгез иде. Бу авыр заманда гастрольләр дә сирәгәйгәндер, маршрутлар да кыскаргандыр...

— Әйе, шаулап-гөрләп ил гизеп йөргән чаклары бар иде театрның Чиләбе, Ырынбур, Махачкала, Уфа, Киров, Мәскәү. Рязань һәм башка бик күп шәһәрләрдә гастрольләрдә булырга туры килде Хәзер алмаш гастрольләр хакында хыялланырга гына кала Шулай да республика авылларында мөмкин кадәр күбрәк булырга тырышабыз. Һәрхәлдә, бер труппа даими рәвештә авылларда йөри Казанда да тик ятмыйбыз: төп бинабызда барган спектакльләрдән, репетицияләрдән бушаган араларда шәһәр мәктәп-гимназияләрендә, балалар бакчаларында еш булабыз.

— Илдус әфәнде, иң зур хыялыгыз нинди?

— Курчак театры музеен булдыру. «Дисней-ланд» кебегрәк музей-тамаша хакында хыялланам мин. Татар курчакларының үз музее, күргәзмә заллы, хәтта аттракционы булырга тиеш. Боларның барысын да балалар үзәге берләштерсен иде...

— Хыял хыял белән, ә...

— ...Ни сорарга теләгәнегезне аңладым. Бина мәсьәләсе — иң авырткан җиребез. Элекке чиркәү бинасы берничек тә театр сәнгате таләпләренә җавап бирә алмый. Әмма бүгенге көнгә кадәр яңа бина төзү хәл ителмәгән... Икенче зур мәсьәлә — драматургия. Тәкъдимнәр күп. Әмма безнең таләпләргә җавап бирердәй әсәрләр аз. Яхшы пьесаларны бик авырлык белән табабыз. Күп вакыт якын дустыбыз Зөлфәт коткара: йә үзе иҗат итә, йә урысчадан тәрҗемә кыла.

Әмма без яуланган биеклектән түбән төшә алмыйбыз. Курчак театры өчен пьесалар аз дип кенә очраган бер әсәрне сәхнәләштерергә җыенмыйбыз. Хәзер күпчелек театрларда бер чир бар: бүгенге көн кадагына сугабыз дип, сәхнәдә барган вакыйгаларны, образларны, сөйләм телен чиктән тыш вульгарлаштыралар.

Курчак театры мондый гамәлдән һәрвакыт читтә торырга тырышты. Һәм ялгышмады дип уйлыйм. Башта кызык, гадәттән тыш тоелган вульгар пьесалардан тамашачы суына башлады, ә сәнгатьнең классик дәрәҗәсен сакларга тырышып яшәгән театрыбызның тамаша заллары һаман шыгрым тулы Бу хәл тоткан юлыбызның дөреслеге хакында сөйли.

— Мәгълүм ки, бүген Казан курчак театры республика театрлары арасында иң тотрыклылардан исәпләнә. Коллектив тату, репертуар бай, зал тулы тамашачы... Һәркем аңлыйдыр, мондый абруйга ирешүдә хәлиткеч рольне баш режиссер уйнаган булырга тиеш...

— Чыннан да, баш режиссер һәрьяклап та театрның күрке, җаны, идеологы булырга тиеш Минем эшем хакында артистлар ни әйтерләр, үземә калса, театр коллективы белән уртак тел таптым кебек. Ялгызыма кыен булыр иде Минем монда ышанычлы ярдәмчеләрем бар. Шуларның берсе — Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Людмила Дьяченко. Түбән Новгородта театр училищесын тәмамлап, соңрак ГИТИС каршындагы югары режиссерлар курсында Образцовның үзеннән белем алган. Казан курчак театрына 1965 елда ук килгән. Театрның баш рәссамы, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Валентина Губская курчакларга бөтен гомерен багышлаган. Директорыбыз Роза ханым Яппарова белән дә аңлашып эшлибез. Театрдагы җылы, үзара дустанә мөнәсәбәт иң элек аңардан тора бит.

— Сезгә чит ил театрларында да эшләргә туры килгән икән...

— Әйе, 80 нче еллар ахырында Ломжа курчак театрында бераз эшләп алдым. Ул вакытта поляклар белән иҗади дуслык мөнәсәбәтләрендә идек. Польшада мин үземнең «Ана күзләре» дигән пьесамны куйдым Ә Казанда Хенрих Галаның «Роза Ветров» әсәрен (Мансур Гыйләҗев эшкәртүендә) сәхнәләштердем.

— Курчак театрының төп авырлыгын үз җилкәләрендә алып баручы кешеләр — артистлар. Алар хакында да берничә сүз ишетәсе килә. Кемнәр алар — җансыз курчакларга җан өрүче, тавыш иңдерүче, аларны хәрәкәткә китерүче, терелтүче тылсым ияләре?

— Курчак театрында универсаль артистлар эшли. Курчак театры артисты һәркайда, һәртөрле театрда менә дигән итеп уйный ала, ә теләсә кайсы драма артисты курчак театрында эшли алмый. Чөнки ул, әйткәнегезчә, җансыз курчакларга «җан өрә» белергә тиеш. Ә моның өчен эчке бер тоем, табигать тарафыннан салынган үтә дә нечкә тоем булуы зарур. Әлбәттә, болардан кала, курчак театры артисты талантлы һәм хезмәт сөючән дә булырга тиеш әле. Театрга артистлар алганда без шушы таләпләрдән чыгып эш итәбез.

— Бездә курчак театры артистлары әзерләүче уку йорты бармы?

— Казан театр училищесында 1966 елдан бирле курчак театрлары өчен артистлар әзерләнә. Училище белән без иҗади дуслыкта яшибез, үзебезнең матди база белән аларга даими ярдәм итәбез. Чөнки училищены тәмамлаган студентлар кайчан да булса безгә киләчәкләр бит. Чынлап та, театрның төп составын нигездә шушы уку йортын тәмамлаучылар тәшкил итә. Казан дәүләт курчак театрының йөзен, асылын билгеләүче артистлардан Миңнехан Әпсәләмов, Ришат Гиздатуллин, Вероника Маякова, Александр Корнеев, Геннадий Вишняков исемнәрен атап үтәсем килә. Яшьләрдән Сиринә Вәлиева, Петр Дементьев, Наталья Баймяшкина яхшы гына уйнап киттеләр.

Курчак театрын матур әкият белән тыңлап караучылар ялгыша, минемчә. Әкиятне чынга әверелдерүче серле дөнья ул безнең курчак театры

Әңгәмәне **Галим ӘСӘН** оештырды

● **Илдус Зиннуров.**
● **Спектакльдән күренеш.**

КЫТАЙДА — ТАТАР ГӘЗИТЕ

Безнең халык... банкрот милләт түгел

Бу елның сентябрь аенда татар телендә басма рәвештә беренче татар гәзитә «Нур»ның чыга башлавына 95 ел тулды «Идел» журналының бу көнне. ягъни 15 сентябрьне. татар матбугаты көне бупарак рәсмиләштерергә диган тәкъдиме булды 1905 елдан татар халкының тарихында яңа бер дәвер башлана ягъни татар дөньясы көндәлек басма — матбугат ташкынына күмелә Дистәләгән сәяси фиркаләр. төрле агымнар һәм сыйныфлар. җәмгыятьләр үзләренең гәзит яки журналларын булдыралар Көндәлек татар матбугатының мәсләк-юнәлешләр төрлелеге һәм сан-ягыннан зур үсеш алуы 1917 1918 елларга туры килә Әмма 1905 елдан соң гына чыга башлаган күп төрле гәзит һәм журналлар барысы да диярлек. советлар карары буенча, «контрреволюцион һәм искелек тарафдарлары» дип. 1918 елда туктатыла

Татар көндәлек матбугат галәме шулкадәр бай ки. хәтта бүгенге көндә аның төгәл генә санын атау да кыен Соңгы күзәтүләр тикшеренүләр нәтиҗәсендә, 1905-1924 елларда гына да якынча 310 исемдә татар гәзитләре һәм 98 исемдә татар журналы чыкканлыгы мәгълүм

Югарыда әйтелгәнчә еллар дәвамында формалашкан татар көндәлек матбугатының үзенчәлекле традициясе 20 нче еллардан тамырыннан үзгәреш кичерә. гарипләндерелә. миллилеген югалта. кырыс һәм коры большевистик төс ала Халыкның рухи ихтыяҗлары арткы планга тибәрелеп, аның урынына индустриаль-техник. тимер-бетон фәлсәфәсе. тирес-ашламалар һәм бәрәңгечелек чыга Ә инде элеккеге татар матбугатының чалымнары һәм алымнары. формасы һәм эчтәлеге, рухы вә мәсләге татар эмигрантлары тарафыннан чит илләрдә чыгарылган гәзит һәм журналларда берникадәр сакланып кала алган

Билгеле булганча, татар мөһаҗирләре Алмания Кытай, Япония Төркия Финляндия кебек илләрдә татар телендә дистәдән артык газета һәм журналлар нәшер иткәннәр Аларда, нигездә, Йосыф Акчура, Гаяз Исхакый, Габделбарый Баттал кебек патша Русиясе дәверендә үк көндәлек татар матбугатында җиң сызганып эшләгән тәҗрибәле зыялылар эш башында торганлыктан әүвәлге традицияләр сүнеп бетмәгәннәр һәм яңача калыпта үстерелгәннәр Дөрес безнең илдә дистә еллар дәвамында, татар мөһаҗирәтенең матбугатына карата кырын караш тыелганлык хөкем сөреп килде Аларның сәбәпләре һәркемгә ачык мәгълүм Шунлыктан, чит илләрдәге татар матбугаты галимнәребез тарафыннан аз тикшерелгән өлкәләрнең берсе булып кала Хәер, үз җирләребездә кайчандыр нәшер ителгән гәзит-журналларның әтрафлы өйрәнелгәннәре дә иксез-чиксез дәрья-диңгезнең аерым утраулары нисбәтендә генә

Татар мөһаҗирәте матбугаты тарихында иң якты эз калдырганнарның берсе — «Милли байрак» гәзите чыга башлауга быел 60 ел тула. Милләт каһарманы күренекле әдип һәм җәмәгать эшлеклесе Гаяз Исхакый тарафыннан оештырылган «Милли байрак» гәзитенең беренче саны 1935 нче елның ноябрь аенда Кытайның Мукден шәһәрендә дөнья күрә Нашире Сөләйман Аити, мөхәррире Ибраһим Дәүләткилде булган атналык бу гәзит 1945 елга хәтле чыккан Гәзит материаллары. беренче чиратта, чит илләрдәге татар мөһаҗирләренең гомуми хәлләренә багышланган «Милли байрак»ның тулаем эчтәлеге һич тә ярлы түгел төрле илләрдәге татар җәмгыятьләре төрки халыкларының тормышы дөнья сәясәте, совет чынбарлыгы тарих, әдәбият Арадан мөһаҗирлектә Тукай бәйрәмнәре уздыру ел саен 15 октябрь көннәрендә Хәтер матәмен билгеләп үтү турындагы язмалар бигрәк тә тәэсирле

«Милли байрак» гәзитенең 60 еллыгы уңае белән укучылар игътибарына «Милли байрак»ның 1936 елда дөнья күргән мәкаләсен тәкъдим итәбез

Раиф МӘРДӘНОВ,
Татарстан Милли китапханәсенең
Кулъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге мөдире



«Милли байрак»ның бер еллыгы

Бүген «Милли байрак» гәзитебезнең чыга башлавына бер ел туладыр Адәм баласының тормышында бер ел бик кыска бер мөддәт (вакыт) булган кебек бер газитнең гомерендә дә бер ел бер дә озын түгелдер Күршеләребездә яшьләре йөзәр ел беләә үлчәнеп килгән гәзитләр бар вакытта. бер ел гәзит чыгара алуыбыз, аны мөнтәзам (тәртипле) рәвештә алып бара белүебез бәлки, безгә гәзитебезнең бер яшьлек бәйрәмен итәргә хак та бирми торгандыр Ләкин безнең милли тормышыбызда «Милли байрак»ның уйнаган роле Кытайның меңеллык гәзитәсенең безнең эшебездә уйнаган роленнән меңләр мәртәбә артык булганга, без шул бер ел эчендә үзебезнең «Милли байрак» янындагы уңышларыбызны, җитешсезлекләребезне карап. аларның сәбәпләрен эзләргә шуларны киң халык катлауыбыз алдында ачык итеп күрсәтмәенчә үтәргә хакыбыз да юктыр Чөнки «Милли байрак» безнең мөһаҗир халкыбызның үзенең эченнән туган. үзенең матди, мәгънәви көче белә генә яшәп килә торган үзенең мәдәни барлыгын күрсәтә торган, Ерак Шәрыктә бердәнбер милли гәзитебездер бердәнбер киң катлау халкыбызның милли дини хакларын саклый торган мәдәни коралыбыздыр. «Милли байрак» милли барлыгыбызны милли ганганәбезне (традиция) дини бәрлегебезне саклар өчен бик авыр хәлләр эчендә Ерак Шәрыктә өч ел бер буйдан алып барылган милли тартышыбызның тудырган иң кадерле баласы шул авыр милли хезмәтебезең иң татлы җимешедер һич шөбһәсез «Милли байрак» гәзите бүгенге көнне безгә генә укучыларыбызга гына юлыбызны яктыртучы милли фонарь булып кына калачак түгелдер «Милли байрак» безнең киләчәктәге фикер тартышыбызда безнең халкыбызның үзлегене саклауда да тарихи ролен уйнаячактыр Безнең Идел Урал истикълал хәрәкәтебезнең тарихында зур бер урын тотачактыр Без үзебез саннарыбыз берничә меңнәр белә генә чикләнә торган Идел Урал төрк татар мөһаҗирләре генә булсак та безнең эшләребез үзебезнең бүгенге ихтыяҗларыбыз белә генә чикләнмидер Безнең максатыбыз да бүгенге авыр хәлләребезне аз маз чикләтү генә үзебезнең ертык тишекләребезгә аннан моннан ертык портык табып ямаулар салу гына түгелдер Безнең максатыбыз, большевикларның золымыннан качып илне ташлап чыгарга мәҗбүр булган милләттәшләребезнең илебездән алып чыккан милли дини барлыкларны югалттырмаенча яшәүче халыкларның мәдәниятләреннән яңа-яңа байлыклар кушып, рухан сау сәламәт көенчә газиз туган илебезгә алып кайту вә большевикларның егерме еллык, мәдәниятебезне җимерүдә ватуда яшьлегебезне безгә дошман булган рухта сугаруларыннан килеп чыккан бушлыкны тутырырга хәзерлек күрүдер Милли тарихыбызда шул егерме еллык фәтрәт (төшенкелек, хәрәкәтсезлек) дәверен аңлатып тарихи борылышыбызның милли тәсбихен өздермәүдер Туган илебезнең гөрләп ага торган матур сулары гөлләчәкләре, болыннары аланнары ашлык белән капланган кырлары бай суларының очы кырые күренми торган караңгы карурманнарына мөһаҗирәтебез кайтканда анда калган мескен халкыбыз авыр саташулы йокыдан албасты басканнан котылган кебек булып уянган вакытында күзләре алдында элекке миллэтчелек, элекке динчелек үрнәкләре ялтырап торсын вә безнең милли юлыбыз аларнын күзләрен чагылдырырлык булып ярылып ятсын Менә шул милли вазифаны үтәр өчен шуны белер өчен мөһаҗирәтебезнең яше-карты бае ярлысы үзенең эше бу көнне үткәрү алай-болай гаиләсенең тормышын тәэмин итү белә генә тәмам була дип уйламаенча ул үзенең туган иленнән алып чыккан бөтен барлыкны милли гореф-гадәтне дин-әхлакыны бөтен ганганәсене чит илдә туган үсә торган баласына чагасына бирергә тиеш вә аларны аңлы милләтче итеп җитештереп иленә тапшыру да иң зур милли бурычы икәнлекне аңларга тиештер вә шул юлда кулдан килгән матди-мәгънәви ярдәмне аямаска тиештер

«Милли байрак» гәзите менә шул милли хәзерләүнең мәктәбе милли вазифаны көн дә искә төшереп торучы милли азанчысы дөньяның киң чит илләренә таралган мөһаҗирләребезнең милли рухының тәрҗеманы әфкяредер (фикерләрен җиткерүче Ул безнең киң төрк илләренең мөһаҗиренең сөеп укый торган чын мәгънәсендә бер төрк гәзите

Шайтанның Коръән тавышыннан качкан кебек кача торган милли догалы гы безнең арабыздагы төрле төрле ике йөзле монафикълар эчке зыянчыларны куркыта торган һәр саны аларны суык җилдәге көзге яфрак кебек бетәм-бетәм дип калтырата торган милли коралыбыздыр «Милли байрак» Ерак Шәрыктәге милләтләр арасыннан безне Идел-Урал хәрәкәтенең үсеп җитеп гәүдәләнеп өлгереп үзенең теле чыкканын үскәнен күрсәтә торган башка милләтләр алдында аның хөрмәтен үстерә торган җанлы бер дәлилдер Ничек соң бу «Милли байрак» мәйданга килде нинди әхвәль эчендә туды үсте? Ник берничә ел элек йә соң тумады? Боларны язып торунын әле вакыты түгелдер Ләкин моның һәрбер адымы һәрбер авырлыгы онытылмаска тиештер Монда сарыф ителгән бер тиен көмеш акчабыз яшеренеп калмаган кебек моның туывына дәвам итүенә-үсүенә сарыф ителгән иксез-чиксез мәгънәви көчләр санап бетерә алмаслык фидакярлекләр дә һичберсе онытылмаска тиештер Һәммәсе дә милләтебезнең мәгънәви барлыгы дәфтәрендә кадерле урында язылып куярга киләчәк буыныбызга тарихи хатирә итеп калдырылырга тиештер Авырлыкның эчендәге милли эшчеләребезнең боларны язарга-сызарга вакытлары да юктыр милли вазифаны эшлибез дип эшне алып барганга кичергән кичерә торган авырлыкларны сөйләп торырга теләкләре дә юктыр Ләкин милләт халкыбызның киң катлавы шул авыр йөкне алып баруның никадәр мәшәкать зәхмәт икәнен белергә-аңларга һәммәбезнең уртак бурычларын үтәүче милли эшчеләребезгә кадер-хөрмәтен үзенең күңелендә сакларга тиештер Ләкин шул бер ел эчендә үзебезнең иксез-чиксез җитешсезлекләребезнең бер өлешен генә күздән кичердек вә бик аз гына авыруларыбызга дарулар эзләштек вә бик аз гына каты хәстәрлекләребезгә ярдәмгә килеп аларга пластырь-фәлән генә ябыштырдык Икенче елыбызга тагын эш бик күп калды Икенче елыбызга әле милли вазифаның бик күп авырлыклары тагын килеп басты Мәктәбебез мәдрәсәбез мәсҗитебез җәмәгатебез матбугатымыз кәтебханәләребез әдәбиятыбыз мәркәзебез җирле җәмгыятьләребез яшьләр түгәрәгебез хатыннар оешмаларыбыз балалар бакчаларыбыз — боларның барысы да алда никадәр эш көтә Боларның барысы да җитәкчелек көтә Боларның барысы да үзенең уңышларын таркау милләттәшләренә белдереп аларны да сөендерер өчен үзенең милли кайгы-хәсрәтләрен бөтен милләттәшләре белә уртаклашып бергә кайгырып бергә елашып бергә шуларның чараларын эзләү өчен «Милли байрак»ның битләре бу елгы кебек үк ачык булуын тели

«Милли байрак»ның милли тормышыбызның көзгесе булып бөтен милли тормышыбызны күрсәтеп баруын таләп итә «Милли байрак»ны үстерергә зурайтырга баетырга омтыла Аны зур матур гәзитләр арасында күреп үзенең милли горурын сыйпамакчы охшамакчы буга Менә без кемнәр? Безнең халык элекке гасырларда гына зур халык булып хәзер банкрот булган милләт түгел Без һаман шул ук Чыңгызлар шул ук Тимерләр шул ук Олуг Мөхәммәдләрнең угыллары шул ук Сөембикәләрнең кызлары Нинди авырлык эчендә нилләр кылдык дип дус-дошман арасында күкрәген киермәкче була Бу теләк хәзерге көндә һәмме милләтчеләребезнең гомуми теләгедер Ләкин теләкнең гәүдәләнеп җитеп бер милли барлык булып чыгуы гына каладыр Аны вөҗүдкә чыгарыр өчен бөтен яшебез-картыбыз «Милли байрак»ның яшәвенә догада гына булып тору җитмидер Аның матди ягын куәтләндерер өчен аның абунәчеләрен күбәйтергә аның акчалы игъаннарын зурайтырга аның өчен кирәкле булган хәзинәне коргаксымый торган итәргә кирәктер «Милли байрак»ның тагы күркәм тагы матур тагы байрак тагы зурырагырак тагы ешрак чыгуы өчен аны үз матбагасы белә тәэмин итәргә тырышырга тиештер Бу милли эшне дә фәлән эшләсен фәлән кылсын дип тормаенча һәркем үзенең милли вазифасы дип аңлап үзе эшкә керешергә тиештер Беренче милли бурычны үтәү шәрәфе миңа булсын дип милли вазифаны эшләргә үзе ашыгырга тиештер Ерак Шәрык мөһаҗирәте өч ел бер буйдан киң рәвештә милли күләмдә зур милли тартыш алып килде Ерак Шәрык төрк татар мөһаҗирәте үзенең милли теләкләрен кануни рәвешкә куяр өчен ике мәртәбә киң күләмдә корылтайлар ясады үзенең милли дини теләген гәүдәләндереп аны эшләргә мәркәз тудырды аның сүзен сөйләргә теләген ишеттерергә «Милли байрак»ны вөҗүдкә китерде Индеге бурычы шул милли мәсьәләләребезне аксатмаенча алып бару шул милли коралларыбызны көчләндерү куәтләндерү генәдер Ерак Шәрык төрк татар мөһаҗирәте бер сәлкенүе белә бу милли вазифаны үти алачактыр «әйдәгез агай-энә тагы бер ярдәмгә» дию белә бу тагы бер еллык милли планыбызны яшәрлек хәлгә куя беләчәктер Бу хәрәкәтнең туктаганы юктыр бу хәрәкәт дәвам итеп киләдер Ерак Шәрыкнең батыр бер милләтчесе Хөсәен әфәнде Беглицый милли матбага тудырамыз дип билен бәгълап «Бисмилласын» әйтеп шул милли вазифага тотынгандыр Ерак Шәрыкнең иске милләтчесе Хаҗи әфәнде Әгерҗи милли хәзинәне тудырабыз милли эшләребезне коргаксытмыйбыз дип бар иманы белә мәйданга чыккандыр Ерак Шәрыкнең бик күп милләтчеләре боларның яннарына тезелгәндер Боларның мөкаддәс милли эшләренә кул сузарга сүз биргәндер Вә бу корылтайларны тудырган һәрбер төрле җирле җәмгыятьләребезне яшәткән милли куәтебез әлбәттә «Милли байрагыбыз»ны да яшәтәчәктер матбагасын да корачактыр матбугатын да тудырачактыр Монда минем һичбер шөбһәм булмаган кебек чит илләргә таралып үз авыр милли йөкләрен өстерәүче милләттәшләребезнең дә шик-шөбһәләре юктыр Фәкать Ерак Шәрыкта корылган милли эшебез бөтен Идел Урал төрк татарының уртак эше булган да Ерак Шәрыктә алынып барыла торган милли дәгъвабызның уңышлы чыгуы һәммәбез өчен уртак сөенеч булганга бу изге эшкә Ерак Шәрыкнең бөтен мөһаҗиренең киң катлавы катышырга тиештер Киң катлавы «Милли байрак»ның еллык бәйрәмендә аны үз матбагасы белән тәэмин итүне гәүдәләндерген аның киләчәк елга дәвамын тәэмин итәргә тиештер Шул эш эшләнсә «Милли байрак»ның бер еллыгы бәйрәм ителгән буладыр Шул эш үтәлсә «Милли байрак»та армый талмый эшләүче милли хезмәтчеләребезнең хезмәтләре тәкъдир ителгән буладыр вә безнең киләчәктә милли аңышыбызның тагы зур бер адымы атланган буладыр

Милләттәш һайди милли вазифа башына

Гаяз ИСХАКЫЙ.

Рабит БАТУЛЛА

Хәвефле өч көн

Язылмаган сәяси-фантастик әсәр

Бөек Октябрь революциясенең җитмеш еллык бәйрәме алдыннан булды бу хәл.

Мавзолей ишеге янында каравыл торучы солдатларның берсе, төнге уникеләр җитеп килгәндә, пышылдап кына хезмәттәшенә эндәште:

— Тыңлале!

Күзен тасрайтып, тораташ булып торучы солдат күзләрен челт-мелт йомгалап алды: сакта торганда сөйләшү түгел, тамак кырырга да ярамый дигәндәй, ул иптәшенә карады.

— Тыңлале, — дип кабатлады беренче солдат.

— Нәстә? — диде икенчесе.

— Эчтә кемдер йөри! — диде беренче. — Мавзолей эчендә.

— Саташасыңмы әллә, — диде икенчесе.

— Әнә, кемдер йөри бит...

— Кем булсын ан...

Икенче солдат сүзен әйтеп бетерә алмады, сагаеп калды: чыннан да мавзолей эчендә кемдер, нәрсәдер кыштырдый иде. Икенче солдат мавзолей ишегенә колагын куйды.

— Дөрестән дә, анда кемдер бар бугай!

— Бар шул, бар, — диде беренчесе.

— Берәрсе яшеренеп калган!

— Әй, кем бар анда? — диде беренче солдат.

Эчтән:

— Мин! — дигән тавыш ишетелде. — Мин бу, ачыгыз!

— Кем ул син?

— Мин — Ульянов-Ленин!

— Нинди Ленин! — диде икенче солдат. — Шпион бу, диверсант! Нәчәльниккә хәбәр итәргә кирәк!

Ул арада каравыл алмашыныр вакыт җиткән иде инде. Ике солдат алдан, командирлары арттан дөп-дөп атлап килеп тә җиттеләр. Алыштырганнарын да көтмичә, ишек янындагы беренче солдат командирга мөрәҗәгать итте:

— Иптәш капитан, мавзолей эчендә кемдер йөри. Үзе, мин — Ульянов-Ленин, дип кабатлый.

Командир:

— Ты что! Уставны белмисеңме? — дип кычкырмакчы иде, шул чак эчтән тавыш ишетелде:

— Чыгарыгыз мине, җегетләр! — Эчтәгенең «Р» хәрефе бик саңгырау яңгырый иде.

Капитан тораташ булды. Алмашчы солдатлар да, аяклары күтәрелгән килеш, бер урында катып калды.

— Ачыгыз, минем бәдрәфтә йомышым бар! — дигән тавышка капитан айнып китте дә ишек янына килде.

— Кем син? Ничек кердең анда? — диде ул.

Эчтәге кеше:

— Мин — Ульянов-Ленин! — диде.

— Ленин икәнсең, бар, үз урыныңа ят, — диде капитан.

— Зинһар, мине чыгарыгыз, минем печ итәсем килә!

— Хәзер мин шундый итеп чыгарырмын, печ итеп кенә калмассың!

— Әгәр дә сез мине чыгармасагыз, мин шушында үз эшемне башкарачакмын. Аннан соң үзегез җавап бирерсез Үзәк Комитет каршында! — дигәч, капитан каушап калды. Чыннан да бу мавзолей идәненә тәрәт итеп куйса, эшләр хәтәр булачак. Колымага, Чукоткага тәгәри китте йомгагым...

— Ач, — диде капитан беренче солдатка, үзе пистолетын чыгарды.

Ачылган ишек яктылыгында чыннан да Ленин кыяфәтендәге бер кеше басып тора иде. Капитан үзе дә сизмәстән үрә катты,башка солдатлар да үкчәләрен шапылдатып алдылар да тораташ булдылар.

— Безобразие! — диде әлеге адәм. — Политические пгоститутки сез!

— Виноват, Владимир Ильич! — диде капитан

— Бүген каисы көн? — диде кеше.

— Җомга көн башланды, Владимир Ильич! — диде капитан — Өченче ноябрь, 1987 ел! Бәйрәмгә әзерләнәбез, Владимир Ильич. Бөек Октябрь революциясенең җитмеш еллыгын каршылыйбыз.

Ленин кыяфәтле бу кеше:

— 1987 дидегезме? — дип сорады.

— Доп-дөрес, Владимир Ильич, 87! — диде капитан.

— Алайса, коммунизмга җиткәнсездер инде, шәт?

— Коммунизм бар, Владимир Ильич, бар. Кремльдә сез үлгән көннән алып коммунизм, кому...

— Кызык, кызык, иптәшләр, бу бик кызык. Коммунизмны күрергә Кгемльгә керер чыгармын, әмма башта минем йомышны башкарырга иде. Кайда монда патшалар җәяү йөри торган урын?

— Сержант! — диде капитан. — Владимир Ильичны өбрәкәйгә озата бар!

— Тыңлыйм! — диде дә сержант, йомышлыны алгарак үткәреп, үзе арттанрак атлап китте.

Узып барганда капитан сержант колагына:

— Әбрәкәйгә керү белән бу бәндәне кулга ал да карцерга яп! Мин хәзер КГБ белән МУРга хәбәр итәм бу мур кыргыры хакында, — диде.

Тегеләр китүгә, капитан атылып мавзолей эченә керде: пыяла капкач эче буш иде.

— Тревога-а! — дип акырды капитан. — Теге мужик Ленинны урлаган! Каравы-ыл!

Аның тавышына солдатлар йөгереп керде.

— Эш харап, — диде капитан. — Икегез ишектә сакта кала.

Ул тышка атылды, каравылдан бушаган солдат аңа иярде.

Кремль янындагы өбрәкәйгә килеп кергәч, алар мондый күренешкә тап булдылар: Ленин кыяфәтле әдәмне озата килгән солдат мылтыгын кочаклап, ишек төбендә йокымсырап утыра, бәдрәфтән чыдап булмаслык одеколон исе аңкый иде.

— Кайда теге җен с... суккан бәндә? — дип акырды капитан.

Солдат сискәнеп торды да үрә катты.

— Кайда-а? — дип кабатлады нәчәльник.

Солдат шунда гына телгә килде.

— Б-бәдрәфтә! — диде ул. — Чыкмый да чыкмый, иптәш капитан, эче китә бугай аның...

Капитан солдат күрсәткән ишекне каерып ачты: бәдрәф идәнендә Ленин кыяфәтле адәм аунап ята иде; аның баш очында әле яңа гына одеколоннан бушаган шешә утырып тора.

Идәндә аунаучыга итеге белән типкәләп караганнан соң солдат әйтте:

— Иптәш капитан, үлгән бугай бу, — диде.

Капитан өчен бу бик тә сөенечле хәбәр иде: мәетне буш каплавыч астына илтеп куясың да эшең бетте, кодагый. Безнең каравыл эсминәсе үтеп китә, мавзолейны икенче каравылга тапшырабыз да рәхәтләнеп гуләнкәгә таябыз, вәссәлам!

Нәкъ шулай башкарганнан соң, капитан канәгать елмайды:

— Уф, шөкер, котылдык бу Ленинннан!

Ләкин бу Ленинннан болай ансат кына котылуның гайрә табигый хәл, булмас эш икәнен капитан әлегә белми иде.

Икенче көнне тамашачы халыкны мавзолейга кертә башладылар. Бар да әләккәчә, барысы да тәртиптә иде. Әмма беренче булып кергән бәхетле совет ватандашлары Ленин карачкысы салынган пыяла каплавыч янына килеп җиткәч, мавзолейда мәхшәр башланды. Кемдер «аһ» итте, кайсыдыр йөрәген тотып, идәнгә ауды, кемдер акыра-бакыра кирегә томырылды.

Бу мәхшәрнең сәбәпчесе торып утырган Ленин иде. Ул ике кулын сузып:

— Баш төзәтергә бирегез, зинһар! — дип ялвара. — Йөз генә грамм бирегез, илле генә грамм хушбуй, одеколон, лосьон булса да ярый!

Кешеләрне куып чыгарып, тиз генә мавзолейны бикләп алдылар. Спецгруппа ябык мавзолейда әлеге сәрхуш сукбайдан, кыйнамыйча гына, бик шәпләп сорау ала башлады: кем ул, монда ничек кергән, Ленин мумиясен кая куйган, кайсы ил шпионы — Япониянекеме, Американыкымы? Сорау алу ысулларын үзгәртеп карасалар да, тоткын һаман бер сүзне кабатлый иде:

— Мине җәзалаганыгызны Феликс Эдмундович Ворошиловка әйтәм! Мин — Ленин! Баш төзәтергә илле грамм бирсәгез, барысын да сөйлим.

Илле грамм түгел, литры белән эчертсәләр дә, тоткыннан яңа сүз ала алмадылар. Спецгруппа читкәрәк китеп, киңәшә башлады. Тәкъдимнәр күп иде:

— Бу сәрхуш бәндәне одеколон, көмешкә эчертеп, йоклатырга да көн саен пыяла капкач астына ябып куеп, халыкка күрсәтергә, кичкә таба, ул айныр вакыт җиткәч, ишекләрне бикләп куярга, вәссәлам!

Бу тәкъдим дә кире кагылды.

— Махмыр исе мавзолейны гына түгел, дөньяны басачак. Кремль янынннан гел ямьсез ис килеп торачак. Аннан соң, кем катгыян ышандыра ала: тагын вакытыннан элек торып утырмасмы ул?

Эш шуның белән тәмамланды: бу исерекне Ленин карачкысын урлаганы, аның урынына кереп ятканы өчен унбиш ел алтын каезларга Себергә җибәрделәр. Бу, әлбәттә, бик яшертен эшләнде.

Шушы көннәрдә мавзолейда булганнар, бу вакыйганы күргән кешеләр кинәт кенә юкка чыга башладылар. Кайсысы поезд астына «ялгыш» барып кергән, кайсысына сыраханәдә пычак кадаганнар, кайсысын төн барганда урамда хулиганнар кыйнап үтергән. Ленинның терелеп, баш төзәтергә одеколон сорап утыруын күргән бер генә шаһит та калмады.

Капиталь ремонттан соң ун көн элек кенә ачылган мавзолейны тагын ремонтка ябып куйдылар. Ленинның чыраен тагын яңарталар икән, янәсе. Ябуын яптылар, ремонт — әйбәт сылтау, әмма мавзолейны яңадан ачар өчен Ленин карачкысын каян табарга? Кем алган аны? Әллә чыннан да Ленин үз аягы белән чыгып киткәнме? Монысы әлегә ачык түгел иде.

КГБның яшерен шымчыларына, бихисап җасусларына бөек бер миссия йөкләнде: шту быты, Ленинны мавзолейга кире кайтарырга!

Аслардан — азау ярганнардан гына төзелгән опергруппа берничә фаразны алга сөрде. Ниндидер бер маньяк мавзолейда качып калган да, мумияне ваткалап капчыкка тутырып качкан. Яки берәр үҗәт антиквар — иске нәрсәләр җыючы кеше, озакламый Ленин һәйкәлләрен, мавзолейны барыбер ватачаклар, җимерәчәкләр, дип мумияне урлаган.

— Гади карак кына булса, сөенер идегез. Ә менә Ленинның чынлап терелеп чыгуы үтә дә куркыныч нәрсә! — диде. Спецопергруппа башлыгы генерал Виссарион Бериевич Чазов.

— Өченче фараз әнә шундый, бөркетләр.

Һәр фаразга да аерым эзләүче-эзәрлекләүче шымчы-җасуслар куелды. Бу фаразлар буенча эзләнүләр нәтиҗә бирмәсә, Ленинга охшаш берәр кеше табарга һәм аны үтереп карачкысын ясарга да мавзолейга урнаштырырга. Бу эш Октябрь бәйрәменә, ягъни өч тәүлек эчендә башкарылырга тиеш!

(Ахыры 23 нче биттә).

«Казанның Тукай урамында»

«Известия» гәзите (200 нче сан) шундый баш белән Казан шәкертләренең элекке атаклы «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе урнашкан бинаны басып алулары, аның тәрәзәсеннән яшел байрак җилфердәве, аларга каршы милициянең шактый зур көче җибәрелүе турында хәбәр итә.

«Элекке мәдрәсә бинасын рәсми рәвештә дини оешмага кайтарып бирүләрен (Казанда дини оешмалар милке аларга бик акрын кайтарыла) көтеп тормыйча, Кабан арты мәчете каршындагы мәдрәсә шәкертләре мөфти Габдулла хәзрәт җитәкчелегендә узган дүшәмбедә әлеге бинага басып кереп, эчтән бикләнделәр. Биредә урнашкан кайбер учреждениеләр, шул исәптән «Крис» гәзите журналистлары бинаны калдырып чыгарга теләмичә, берничә тәүлек шунда кундылар. Бу вакытта телефон элемтәсе өзелгән иде...»

Вакыйга күңелсез, әлбәттә, әмма әлеге мәсьәләгә карата республика гәзитләрендә Татарстан хөкүмәтенең мөнәсәбәте белдерелде инде. Элекке «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе бинасы этаплап төрле учреждениеләрдән бушатылачак һәм дини оешмаларга кайтарылачак.

Печән базары мәчете ничек «Нурулла мәчете»нә әйләнде?

Бу сорауга **«Крис»** гәзитендә (20.10.95) басылган «Ә Габдулла хәзрәт кем ул?» дигән язмадан җавап табарсыз. Югарыда тасвирланган фетнәне оештыручы мөфти Габдулла хәзрәтнең күп кенә башбаштаклыклары турында сөйләгәннән соң, гәзиттә мондый юлларга тап буласың: «Печән базары мәчетенең «Нурулла» мәчетенә әйләнү факты да дин тотучыларда ачу тудыра. Ни өчен? Чөнки Нурулла — Мәскәүдәге атаклы «авторитет» Ленарның туганы. Нурулла мәчетен торгызуга миллион сум акча биргән, шуның нәтиҗәсе буларак, мәчет яңа исем алган».

Төркияне беләсезме?

«Аргументы и факты» атналыгының Татарстандагы кушымтасы кызыклы конкурс игълан иткән. Бу кушымта «Татурос» Татарстан-Төркия компаниясе белән берлектә «Сез Төркияне беләсезме?» дигән конкурс игълан итә. 43 нче санда басылган сорауларның 15енә дөрес җаваһ бирүчеләр кыйммәтле бүләкләр алачак. Иң зур приз — Төркиягә атналык сәяхәткә юллама.

Алданмасак иде...

«Алтын Урда» гәзитенең 28 нче санында танылган шагыйрь һәм публицист Айдар Хәлимнең Чаллы татар иҗтимагый үзәге җыенында әйткән сүзе урнаштырылган. Ул, Русия Дәүләт Думасына сайлауларга бойкот ясау нәтиҗә бирмәс, киресенчә, бу Думага мөселман депутатларны сайлау чараларын күрергә кирәк, дигән фикер әйтә. Югыйсә, «Дәүләт Думасы мөнбәреннән бөтен дөньяга Русия мөселманнарын, изелгән халыкларны яклап кем аваз салыр?» — ди ул.

«Кара» дәүләтнең якты нуры

«Татар иле» гәзите (37 нче сан) «Кара» дәүләт эчендә якты нур» дигән баш белән фәннәр докторы Г.Лисичкинның зур мәкаләсен тәкъдим итә. Анда нигездә Татарстан авыл хуҗалыгының уңышлы эшләве хакында сүз бара. Автор алдан ук: «Табышмаклы сүзләр белән укучыны аптыратмас өчен «караңгы» дәүләткә төшкән «якты нур»ның Татарстаннан икәнен әйтим, Мәскәү һәм Петербург кебек эре үзәкләрдән түгел — Татарстаннан», дип искәртә. Мәкаләдә «Ни өчен 90 нчы еллардагы М.Шәймиев 60 нчы еллардагы Ф.Табеевтан уңышлырак эш итә?» кебек сораулар куеп, аларга җавап бирә. (Бу мәкалә «Известия» гәзитенең 184 нче санынннан күчереп басылган.)

Әлеге гәзитнең «Татарские края» дип аталган урысча басмасы Мәскәүдә яшәүче татар галиме — тарих фәннәре докторы Әгъдәс Хөсәен улы Борһановны (элек ул Казан дәүләт университетында эшләгән иде) 75 яше тулу уңае белән тәбрикли. Шунда ук аның Русия Федерациясе Дәүләт Думасында тыңланган «Азчылык милләтләрнең хокукларын яклау турында»гы закон-проекты буенча язмасы урнаштырылган.

Намуссыз компанияләрдән сак булыгыз!

«Известия Татарстана» гәзите (25.10.95) язганча, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршындагы кыйммәтле кәгазьләр һәм фондлар базары комиссиясе менә нәрсәләр хәбәр итә: «Регион» чеклар инвестиция фонды һәм «Крис» инвестиция компаниясе гәзитләр һәм радио аша халыктан акча җыюы турында белдерә, — диелә анда. — Ләкин «Регион» фонды да, «Крис» компаниясе дә кыйммәтле кәгазьләр һәм бурычка акча бирү яки алу операцияләрен үткәрүдә РФ һәм ТР законнарын бозган өчен берничә тапкыр лицензияләреннән колак кактылар. Шулай булгач, аларга ышанырга нигез бармы соң?



Президент хуплый, банкир карыша

14 октябрьдә Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиев республикага Русиянең башка төбәкләрендәге банк акчаларын тарту кирәклеге турында әйткән иде. Моны ничек хәл итәргә соң? Президент фикеренчә, Татарстанда башка өлкәләрнең банкларын булдырганда, алардан бурычка акча алып торырга мөмкин. **«Сегодня»** гәзите хәбәр иткәнчә (198 нче сан), Татарстан Милли банкы җитәкчесе Евгений Богачев моңа каршы. Биредә чит төбәк банкларын булдыру, ди ул, республикадагы акчаны читкә җибәрергә мөмкинлек тудыра.

Шешә күпме тора?

Соңгы вакытта кешеләрдә шешә тапшыру белән кызыксыну беткән иде. Трамвай билеты 400 сум торганда, 80 сумга аны кибеткә кем илтеп йөрсен. **«Вечерняя Казань»** гәзите (24.10.95) хәбәр иткәнчә, бу өлкәдә җитди үзгәреш. Ярты литрлы башы борып ябыла торган шешәләр — 500әр сум, гади шешәләр — 400 сум, «фанта» һәм «пепси» шешәләре — 400 сум, 3 литрлы банка 700 сум, 05-0,33 литрлы шешәләр 200 сум тора.

Валерий КОКОВ,
Кабарда-Балкар Республикасы Президенты:

«Мәдәният дәүләтнең даими кайгыртуына мохтаҗ»

Сорау: Сездәге хакимият структуралары иҗат берлекләренә нинди ярдәм күрсәтәләр?

Җавап: Мин икеләнмичә әйтәм: мәдәният дәүләтнең даими кайгыртуына мохтаҗ. Ә милли дәүләтчелеген торгызучы җөмһүриятләрдә мондый мәсьәләнең әһәмиятлелеге бермә-бер арта. Бу исә халыкның аз санлы булуы һәм яшәү рәвешенең үзеннән килеп чыккан башка объектив сәбәпләр белән аңлатыла.

Һәрбер иҗат кешесенең нәтиҗәле эшләве өчен кирәкле булган көнкүреш һәм башка матди шартлар тудыру юнәлешендә теге яки бу карарга килү безнең өчен җиңелрәк. Әйтик, әле күптән түгел генә КБР хөкүмәте Язучылар берлегенә ярдәм күрсәтү буенча өстәмә чаралар турында карар кабул итте... Аерым алганда, берлеккә яңа бина бирергә, һәрбер каләм иясенә өстәмә рәвештә ике минималь хезмәт хакыннан ким булмаган матди ярдәм алу хокукын калдырырга ниятлибез. Гомерен иҗатка багышлаган шәхес, көнкүрештәге вак-төяк җитешсезлекләргә карамыйча, үзенең төп бурычын гамәлгә ашырсын өчен без барысын да эшләргә тиешбез.

Шул ук вакытта без язучыларның әсәрләре үз вакытында басылсын өчен дә мөмкин булган бөтен чараларны күрәбез. Бу җәһәттән дә махсус программабыз бар. Ә хәзер иң әһәмиятлесе — китапларның складларда тузан җыеп ятмавында. Тиздән хөкүмәт дәрәҗәсендә китап бастыру һәм тарату эшен камилләштерү буенча карар кабул ителәчәк.

Язучылар берлегенә ярдәм итү турында сөйләгәндә шуны да әйтеп үтәсем килә: без мондый уңай шартларны башка иҗат оешмалары әгъзалары өчен дә тудырырга омтылабыз. Кыскасы, хөкүмәт мөмкинлегеннән чыгып, Кабарда-Балкар Җөмһүриятенең барлык иҗат әһелләренә төрле яклап ярдәм күрсәтелә.

(«Литературная Россия»).

Тыйнак караклар

Хәзерге заманда кешенең киеменә карап, америкалылар әйтмешли, «күпме торганын» белергә була. Казанның Авиатөзелеш районында караклар финанс корпорациясенең бүлек җитәкчесе фатирына бәреп кереп, 50 миллион (!!!) сумлык чәшке тиресеннән тегелгән тунын алып чыгып китәләр. Башка әйберләргә тимиләр. Зыян күрүче хәзер туны өчен сейф ясатмаганына үкенә, имеш.

(«Милиция, законность, правопорядок»).

70 яшьлек карчык — биш игезәк анасы

Лос-Анджелеста 70 яшьлек Анна Лучи биш игезәк бала тапты. Ул хәзер, игезәкләр тапкан 59 яшьлек бөекбританияле хатынны узып, беренче урынга чыкты.

Ирле-хатынлы Эстебан һәм Анна Лучиларның дөньясы җитеш, тик балалары булмый. Анна ханымның бик тә ирен куандырасы — аңа бала бүләк итәсе килә. Әмма күп белгечләр бу яшьтә бала табарга киңәш итмиләр. Шуннан ул үз төбәкләрендә эшләүче акушер Делузга мөрәҗәгать итә, һәм доктор, төрле тестлар тикшереп, ханымның исән-сау бала тудырачагына ышана. Миссис Лучи, климакторик вакытта булганга күрә, үзенең яшьрәк туганыннан донор булуын үтенә. Миссис Лучиның 59 яшьлек ире Эстебан әфәнде һәм яшь хатын күзәнәкләре орлыкландырылып, аналыкка салына.

Табиблар биш күзәнәктән берсе яисә икесе генә орлыкланыр дип уйлаган була. Ләкин бөтенләй башка хәл килеп чыга — биш күзәнәкнең бишесе дә үсә башлый. 70 яшьлек ана өчен бик кыен булса да, миссис Анна көмәнлек чорын яхшы үткәрә. Соңгы өч аенда ул шәфкать туташлары күзәтүе астында гел урын өстендә ята. Балаларны акушер Делуз аналыкны ярып ала. 992 граммнан алып 1 кило 965 граммлы балалар да, ана да үзләрен яхшы хис итә.

Хосе, Роберто, Палома, Нубия һәм Солидадны өч шәфкать туташы карый, һәм, алар исәйгәч, әти-әниләрә сабыйларын туган илләре Перуга алып китәргә уйлый.

(«Всемирные новости»).

ЕГЕТЛЕКНЕҢ БЕР БАСКЫЧЫ

Язучы Җәүдәт Дәрзаманов иҗаты турында уйланулар

Апаска баргач, шунда яшәүче бер танышым белән китап кибетенә җыендык. Өйдә калырга, без кайтканчы йорт эшләре белән кайнашырга ниятләгән хатыны кинәт кенә киенә башлады.

— Сабыр итегез, мин дә барам.

Урамга чыгу белән көлеп куйды да чәчбикә, бик сәер тәкъдим ясады:

— Әгәр, Фәнзаман абый, син миңа ундүрт кенә битле бер китап җибәрер булсаң, мин сиңа бер машина китап төяп озатам.

Мәзәксенеп йөзенә карадым. Карашында шаян очкыннар уйнап торса да, сүзеннән кайтмаслыгы нык сизелә рәхмәт төшкерененең! Әһә, мәйтәм, дөнья бетереп эзләсәң дә табылмый торган тарихи экземпляр сорыйдыр бу.. Уемны ачып салгач, тагын бер мәртәбә рәхәтләнеп көлде:

— Юк-юк!.. Белгәнеңчә, мин бит балалар бакчасында тәрбияче Менә шунда сабыйларга хәреф таныта башлау, туган телгә мәхәббәт тәрбияләү өчен бик тә уңайлы китап бар күрше бакчада «Безнең әлифба» дип атала. Аның авторы сиңа туган да туры килми микән әле...

Тукта, тукта! Җәүдәт Дәрзаман китапчыгы турында бара түгелме соң моның сүзе? Автограф белән биргәләгән китапларының берсе нәкъ менә «Безнең әлифба» исемле сыман...

— Ярый, табам, — дидем. — Бер машина китабыңны әзерлә, сеңелем.

Җәүдәт белән туган булу түгел, капка баганаларыбызның да бер урманда үсмәвен аңлатып бетергәндә, кибет түбәнә килеп җиткән идек инде.

— Мин җибәрәсе китаплар шунда, — диде дә ханым, кибет ишеген беренче булып ачты. Кергәч, барысы да аңлашылды: шактый югары дәрәҗәгә ия булган ике авторның кирпечтәй калын китапларын кулыма алгач, сатудагы бәяләрен күргәч, көләргә дә, еларга да белмәдем. Берсе — 2 сум, икенчесе — 16 сум тора... Бер кап шырпы алу өчен йөз китап сатарга туры килә түгелме соң? 25 мең сумлык алсаң да, туп-тулы «КамАЗ». Ә андый акчага кирәкле, кадерле китапны бердән артык бирмиләр.

...Бүләкне бүләк итүнең бик үк ярап бетмәвен белсәм дә, тәвәккәлләдем — җибәрдем Җәүдәтнең китабын Апас ягына. Конвертка адрес язганда сөенә-сөенә фараз йөрттем: телләре яңа гына ачылган сабыйлар кумәкләшеп, гөрләшеп такылдасын әле мондагы кыска да, күңелле дә шигырьләрне! Кабатларлар, куанырлар һәм... кем белә, туган телнең сокландыргыч кодрәтен бала чактан ук тоеп, кайберләре шагыйрь булып та үсәр. Булмас, димә — дөнья бу!

Кыскасы, китте китап... Киткәнче, мин аны тагын бер мәртәбә укып чыктым — «А» хәрефеннән «Һ» хәрефенә кадәр.

Алма диләр алларын да,
Яшелен дә, агын да.
Гел аласы килеп тора,
«Алма!» — дигән чагында.

Шушы урында укучы да игътибар итәр: бер строфа шигырьдә гаҗәеп матур күренеш тә, гыйлем белән кызык та бар, шулай ук «А»лар да күп. Чөнки бу шигырь нәкъ менә «Безнең әлифба»дагы «А» хәрефенә багышлап язылган.

Кызылканат тарта дисәм,
Кысла капкан кармакны.
Ычкындырыйм дигән идем,
Кысты куйды бармакны!

Күренә ки, «К» хәрефен өйрәнгәндә дә бала кыкылдап кына утырмаячак. Үзе көләр, үзе куаныр, шул ук вакытта нәтиҗә дә ясар. Бу дөньяда кызылканат дигән балыкның да, аның кармакка эләгү ихтималын да, үз иркен кысарга маташучыларны кыса белүче кысланың барлыгын да наразый башындагы бер күзәнәгенә теркәп куяр.

Ярый, җитеп торыр. Чөнки минем максатым, күпме генә кызыксам да, 38 хәрефнең 38 шигырен күчереп язу түгел.

Китапны конвертка тыкканчы тиражны карадым. Сөбханалла, 150000 данә чыккан бу әлифба. Шулай да җитмәгән, дөнья буйлап эзләнелә торган басмага әверелгән. Ә теге туры мәгънәсендә генә түгел, рухи мәгънәсендә дә арзанлы китаплар моңарга караганда ун, хәтта кырык мәртәбә азрак чыккан һәм шулай да күп еллар буе тузан эчеп, кибеттә урын алып, сатучыларга комачаулап, сатылмый яталар. Китап кибете — ул әдипләр өчен Сабантуе, көрәш мәйданы кебек урын. Кемнең — хак язучы, кемнең хас язучы икәне шунда күренә. Гомумән, укучыга синең нинди дәрәҗәләр, бүләкләр алуың, кайсы сессия-съездларда депутат булып катнашуың кирәкми. Аңа сәнгатьчә югарылыкта язылган китаплар кирәк, һәм вәссәлам!

Апастагы танышымның гозерен үтәгәннән соң, тагын бер талпынып, каләмдәшемнең башка китапларын да өстәлемә өеп куйдым. Аларны укыганда, ни хикмәттер, ач, ялангач һәм ятим үткән моңсу балачагым күз алдымнан китмәде. Дөрес, ачлыктан, хәсрәттән күз яшьләре чыкканда да көлдерүчеләр, сөендерүчеләр табылды. Берсе — Фатих Кәрим, үзенең гармунчы аюы, җырчы маймылы белән... Икенчесе — Абдулла Алиш, сазга бата-бата, бака куып йөргән Гатасы, сертотмас үрдәге белән... Шуннан соң да әдәби дөнья балалар өчен язылган шигырь-поэмаларга, әкият-хикәятләргә мохтаҗ булмады. Әмма мин әлеге ике әдип кебек йөгерек тә, кызык та итеп яза белүчене дистә еллар буе тапмадым шикелле. Көтмәгәндә, исәп итмәгәндә хәзерге балаларны да җилкендерерлек, көлдерерлек, геройлары төшләренә керерлек тагын бер «Фатих Кәримгә», дөресрәге, Җәүдәт Дәрзаманга юлыктым.

Әкиятче оста булса,
Авызына карата.
Айбулатмы? Айбулат та
Әкиятләр ярата.
Яратуын ярата да,
Тыңлый гына Айбулат.
Ишеткәнен мыегына
Чорный гына Айбулат.
Мыек дигәч: «Каян килсен
Айбулатка мыек, — дип, —
Әле мыек үстерергә
Буыннары сыек!» — дип,
Уйламагыз!
Еллар узар,
Бер үсәр ич Айбулат.
Аптырата бабасын ул
Көн дә әкият сорап...

Кем ничектер, мин үзем киң сулыш белән укыла торган, әледән-әле телне төртелдерми-җәфаламый торган, шул ук вакытта елатырдай, елмайтырдай, тирән уйга да салып чайкардай шигъриятне якын күрәм. Дәрзаманның ошбу «Айбулат» поэмасын да өнә шул сыйфат-кодрәтләре өчен яраттым. Укый башлагансың икән, Җәүдәт «сихереннән» ычкыну юк — ике мең юллык бу әсәрен һичшиксез укып чыгасың һәм... әсәрләнеп каласың. Әле ул сакаллы сабый башың белән шулай. Әгәр чын сабый булсаң?..

Алиш рухын да дәртләтеп, яңартып җибәрде Җәүдәт Дәрзаман үзенең иҗатында: «...Менә нәкъ шул заманда, яшел хәтфә аланда яшәгән, ди, бер карчык. Өе булган, ди, урман, стенасы — җилдән, бикләгеч билдән...» «...Кәҗә ягына килсәк: күзе ут, үзе мут, урлашып тамагы тук...»

Әдипнең кайсы гына әсәрен укысаң да, милләтенә, халкының теленә, туган иленә гашыйклыгын тоясың. Гашыйк икәнсең, димәк, барысын да изге итеп саклый беләсең. Саклый да, кадерли дә белә Җәүдәт. Дистәләрчә китапларына тупланган шигырьләре, поэмалары, әкият-хикәятләре, повестьлары әнә шул изгелекне балаларның (аларның гына микән) күңеленә нур итеп иңдерә белә. Укыган саен күңелдәге өмет вә инануларның раслануын тоясың: татар теле дөньядагы һәр төсне һәм төсмерне сурәтләү, теләсә кайсы авазны, рухны, хис вә халәтне ачып салу, тасвирлау өчен Ходай тарафыннан махсус бирелгән илаһи тел икән, дисең. Бигрәк тә авторның соңгы елларда иҗат ителгән «Җиләкле көннәр», «Бизмән йолдызлыгы» повестьларын укыганда әлеге инану тагын да ныгый. Һәркемгә дә шулай тоелса, бер дә гаҗәпләнәсе юк. Чөнки Җәүдәт Дәрзаманның тормыш һәм әдәбият серләрен барлап, гаделлек һәм хаксызлыкларны төбенә кадәр татып өлгергән чагы — гомеренең беренче яртысыннан икенчесенә кереп барган вакыты.

Менә шушы 50 яше тулган көннәрдә язучы Дәрзаман, моң һәм сагышлары белән бергә бихисап шатлыкларын да бизмәнгә сала. Чөнки бу юбилей егет чактагы кебек алга таба гына ашкындырмый, әледән-әле үткән юлга да текәлеп карарга мәҗбүр итә.

...Кышкы күз ачкысыз буран. Буранны, караңгылыкны ярып, бер бала ерак юлга чыккан. Нинди нужа куып чыгарган, кая бара? Нужасы түгел, дәрте, максаты алга тарта малайны, ул туган авылы Сугышлыдан Лениногорскига әдәби утырышка бара. Ниһаять, редакциягә килеп керә малай. Инде утырышып өлгергән өлкәннәр аптырашта кала: «Син, энем, ялгыш кергәнсеңдер. Монда язучылар җыелышы бара», «Беләм, — ди малай. — Гәзиттән укып беләм. Мин шул утырышка килдем...»

...Кабат өч-дүрт елдан, ягъни 15 яше тулгач, Җәүдәт Дәрзаманов дигән әлеге малайның исеме республика гәзитләренә калкып чыга. Бер-бер артлы басылган шигырь циклларының авторы буларак таныла башлый бу исем.

Җәүдәт мәктәптә укыган чакта язган «Һинд кызы» исемле шигыре... Җәвад Тәрҗеманов имзасы белән дәреслектә басылып кайта. Китап чыгаручылар, мондый шигырьне мәктәп баласы язгандыр дигән уйны башларына да китермичә, өлкән әдипнеке итеп бастырганнар. Ә инде «бала-чага» шигыре икәнлеген ачыклагач, чираттагы басмада ук төшереп калдырганнар.

...Беренче «тәнкыйтьчесе« дип бабасын — әнисенең атасын таный Җәүдәт. Оныгының шигырьләрен укый-укый да карт, астыртын гына елмаеп куя:

— Син, улым, умарта кортлары, күбәләкләр турында язып йөргәнче, Хрущевны, кукурузны, партияне макта. Шулай итмәсәң, яшәргә дә, язганыңны чыгарырга да ирек бирмәсләр.

...Университетны тәмамлап, бер үк вакытта армия хезмәтен төгәлләп кайткан Җәүдәтне Татарстан радиотапшырулар комитетына эшкә чакыралар. Берничә тапшыруын эфирга чыгару белән Җәвад Тәрҗеманов шалтырата, аз гына сакаурак, әмма ягымлы, матур тавышы белән киңәш бирә:

— Син, энем, сөбрек эслә. Минем абруйга тап төсәрлек итмә. Сөнки монда һәр тапсыруыңнан соң миңа салтыраталар: «Нисек өлгерәсең син, Җәвад? Институтта укытасың, китап арты китап язасың, инде радиода да эсли баслагансың икән, молодец!» — диләр.

Радиокомитетның төрле редакцияләре белән җитәкчелек итте Җәүдәт Дәрзаман. Кайсында гына эшләмәсен, күңеле балалар дөньясына өйдәкләде, әдәбиятка, сәнгатькә сәләтле дистәләрчә балаларны табып кына калмады, эфир, гәзит-журналлар аша киң дөньяга чыгарды. Бушрак вакытлар тапса, шигырьләрен, кубызын, кураен кесәләренә тутырып, җиз телле тальянын култык астына кыстырып, кайсы да булса мәктәп тарафына йөгерергә күнекте. Балаларга кызык та, күңелле дә: чәче чалара башлаган бу абый бик әкәмәт кеше — шигырьләрен укый-укый да кубыз чиртә, курайда уйный, гармунда сыздырып җибәрә, тагын шигырь укый башлый — балалар да — бала, бу да бала.

...Шуңа да сөенә Җәүдәт: бу вазифага омтылучылар күп булуга карамастан, каләмдәш дуслары — язучылар һәм журналистлар аны — Җәүдәт Дәрзаманны «Ялкын» журналына хуҗа итеп сайладылар.

Танылган каләм әһеле тормышыннан кыска һәм саран эпизодларны санап чыгуымның хикмәте шунда. Җәүдәт әлифбасын ятлый-ятлый тел шомартучы сабыйлар да, аның китапларын укып җитлеккән егет һәм кызлар да, шуларның ата-аналары да милләтне, туган телне сакларга ярдәм итүче, иман иңдереп торучы әдипләрнең зур әдәбиятка килгәнче дә, гомер буе да гамьлә-мәшәкатьле, гыйбрәтле-сабаклы, матавыклы юллар үтүен белсеннәр, кызыгын да, кызганычын да күрсеннәр. Мәгълүм бит, бездә язучыларның истәлекле һәм сирәк килә торган бәйрәмнәрендә дә кайберәүләр «теоретик» болгатмалы, иҗатына карата «тирән анализлы» мәкаләләр бастырып чыгаралар, ә үзен пәрдә артына яшереп калдыралар. Мин дә бу язманың бу өлешен шул рухтарак язаргамы икән әллә, дип уйлаган идем. Әмма кире кайттым: беренчедән, Җәүдәт Дәрзаман ул бәяләрнең хаклысын да, хосеткә төрелгәннәрен дә күп күргән, тормышның суы белән утын гына түгел, җиз торбасын да сабыр кичкән — мактауларга мөкиббән китмәгән, арттан килеп түбәсенә суккан очракларда да иҗатына хилафлык китермәгән үзенчәлекле шәхес. Дөрес, үзе кебек үк балалар өчен язучы кайбер кордашларының аңардан да калкурак булып тоелуы ихтимал беркатлы укучыларга. Чөнки алар үзләренә зур дәрәҗәләр, ел саен диярлек Тукай премияләре дәгъвалап, депутатлык, түрәлек белән шаулап, хакимият карамагында «үз кеше»лекләреннән файдаланып, саллырак китаплар чыгарып дан алалар. Җәүдәтнең исә андый фанфаралар уйнатырга, үзен алга чыгарып күрсәтергә омтылу гадәте юк. Әле менә туган көне алдыннан да юбилей мөнәсәбәте илә ым-тын сизелмәде, ул көн үткәннән соң да хәрәкәт күренми... Бүтәннәр кебек бүләкләнүе дә ишетелми...

Соңгы җөмләгә җитә баруымны шәйләгәч, Җәүдәтнең иҗат байлыгын тагын бер мәртәбә барлап чыгасым килде. Әз булса да сөйли, күрсәтә алдыммы мин ул хакта? Чынлап та бик чамалы булгандыр. Ник дигәндә, төрле жанрларда иркен язучы әдипнең барлык каләм җимешләрен татып карарга омтылсаң, кызыклы һәм гыйбрәтле дә, гыльми дә китап язарга туры килер иде. Монысы — әдәби тәнкыйть белән шөгыльләнүче белгечләр өчен махсус хезмәт. Ә мин, шактый китапларын телгә алып үткән булсам да, күбесенең исемен дә санап чыгарга өлгермәгәнмен. «Ирбатыр», «Солдат булдым», «Гелназ мәктәпкә бара», «Илләр гизә Илгизәр», «Җир авазы», «Ночное приключение»... Ялгыш укымадыгыз, урыс балаларына да (урыс телле татар балаларына, дип тә өстәү кирәктер) мәгълүм Җәүдәт Дәрзаман шәхесе. Тәрҗемәчесенең кем булуы да горурлык — элекке СССР күләмендә олуг шагыйрьләрнең берсе булып танылган Рәстәм Кутуй! Ә инде Кутуй кебекләр, тәрҗемәгә вакыт исраф иткән сурәттә дә, чын мәгънәсендә лаеклылар иҗатын гына игътибарга алалар. Яхшы әсәрләрнең, кагыйдә буларак, тәрҗемәләре дә уңышлы:

Спать нельзя,
съедят с одеждой,
На спасенье нет надежды.
Вон зубами как стучат,
По-крысиному визжат.

Әйе, йоклый торган, канәгатьлектән изри торган заман түгел бу, тормышта да, әдәбиятта да егетлек сорый торган заман. Иҗатыңда өз генә тоткарланып торсаң да киемең-ниең белән йотылуың бар комсызлар, көнчеләр, үҗәтләр каш өстенә менгән бу «бөек» империядә. Син яшәгән заман нинди генә болганчык булмасын, үзеңнән соң яшәячәк буыннарга саф сулы чишмәдәй, чәчәкле болындай, сулап туймаслык һавадай мирас калсын! Кеше берничә гомер яши, дип юаталар да бит... Тик менә яңадан әдип, шагыйрь булып туарсыңмы әле, юкмы — бер Алла белә. Ашыгырга, гафил булып калмаска кирәк бу гомердә.

Фәнзаман БАТТАЛ.

Уңөченче бит

Гәрәй Рәхим кытыклары

Исемең матур, кемнәр куйган...

(Сәяси фараз)

Соңгы вакытта астрологлар, күрәзәчеләр, экстрасенслар, аклы-каралы маглар, сихерчеләр, тагын әллә ниткән ырым-шырымчылар тормышның төрле өлкәләрендә киләчәктәге үзгәрешләр турында фараз кыла башладылар. Гәзит-журнал битләре, китап-брошюралар, телевидение экраннары, радио дулкыннары әнә шундый күрәзәчеләрнең шаккатыргыч фаразлары белән тулды. Боларның берсенә дә ышанмаган, барысының да шарлатаннар гына булуына ныклы инану белән инанган мин дә заман шаукымына ияреп, киләчәктә Татарстан гәзит-журналларының исемнәре ничек булуы турында үземә күрә фәнни нигезләнгән бер сәяси фараз төзедем. Октябрь революциясеннән соң берничәшәр мәртәбә исемнәрен үзгәртә килгән татар матбагасы киләчәктә дә исем үзгәртми калмас ич инде. Хәзер Русиядә сәяси тормыш котырган чак, Думага сайлауларга әзерләнү шаукымы без суверен дип йөргән Татарстанда да киң колач ала. Әлбәттә, сәяси тормышта Жириновский дигән әһел лидерлыкны һич кенә дә бирергә теләми. Озакламый Татарстаны-ние белән губерналаштырылган Русия тәхетенә Жириновский әфәнде менеп утырмас дип кем әйтә ала?

Менә шуларны уйлап, мин Татарстанның 1917-1997 елларда басыла торган кайбер гәзит-журналларның еллар үткән саен үзгәрә барган исемлеген төзедем.

Чын мәгънәсендә — исемең матур, кемнәр куйган... дигән кебек килеп чыкты бу исемлек:

1. «Кызыл Татарстан» — «Совет Татарстаны» — «Социалистик Татарстан» — «Ватаным Татарстан» — «Русия Татарстаны» — «Жириновский Татарстаны».
2. «Кызыл яшьләр» — «Яшь сталинчы» — «Татарстан яшьләре» — «Русия Татарстаны яшьләре» — «Жириновкий яшьләре» (яки «Яшь жириновскийчы»).
3. «Известия Татарстана» — «Время и деньги» — «Российское время и деньги Татарстана» — «Время и деньги Жириновского».
4. «Татарстан хәбәрләре» — «Мәдәни җомга» — «Русия якшәмбесе» — «Жириновский шимбәсе» (яки «Шимбәләр Жириновские»).
5. «Яшь ленинчы» — «Сабантуй» — «Яшь русиячe» — «Жириновский Сабантуе».
6. «Казанские ведомости» — «Российские ведомости» — «Жириновские ведомости».
7. «Татар иле» — «Урыс иле» — «Жириновский иле».
8. «Татарские края» — «Русские края» — «Жириновские края».
9. «Алтын Урда» — «Русия Урдасы» — «Жириновский Урдасы».
10. «Атака» — «Совет әдәбияты» — «Казан утлары» — «Мәскәү утлары» — «Жириновский атакасы».
11. «Совет мәктәбе» — «Мәгариф» — «Русия мәгарифе» — «Жириновский мәктәбе».
12. «Азат хатын» — «Сөембикә» — «Русия Сөембикәсе» — «Жириновский Сөембикәсе».
13. «Чаян» — «Скорпион» — «Жириновский».

Быелның иң авыр көннәре

Әлеге дә баягы шул күрәзәчеләр агымдагы һәр айның иң авыр көннәрен алдап исәпләп матбугатта игълан итеп баралар. Мин дә быелгы елның икътисадый һәм финанс өлкәләрен өйрәнеп, катлаулы исәпләүләр алып бардым һәм шундый нәтиҗәгә килдем: 1995 елда иң авыр көннәр 1 гыйнвардан алып 31 декабрьгә кадәр булачак. Хәзер мин киләсе 1996 ел өчен исәпләүләр алып барам...

Октябрь балалары

Иске китаплар карап утырам. Балачактан өйрәнеп үскән бер җырны кычкырып укыйм:

Без — Октябрьдә туганнар,
Без — Октябрь баласы.
Октябрьдә туганнарның
Ленин була бабасы.

Буй җиткән улым җыр сүзләрен тыңлап торды да:

— Әти, нүжәли Ленин гаилә тормышында шул кадәр азгын булган? Октябрьдә туган һәр бала аның оныгы булса, бик күпкә китә бит ул, — дип куйды.

Мунчала һәм каеш

Торгынлык дип аталган теге елларда мин «Татарстан яшьләре» гәзитендә әдәбият-сәнгать өлкәсен алып бара идем. «Лира клубы» дигән махсус сәхифә ачып җибәрдем. Клуб тирәсенә рухи ирекке омтылган талантлы яшь артистлар, композиторлар, рәссамнар, язучыларны тупларга тырыша идем. Безнең, ягъни 60 нчы елларда татар сәнгатенә килүчеләрнең борынына Никита Хрущев китергән сәяси яз җылысы исе кереп, әдәбият-сәнгатьтә без шактый гына кыюланып өлгергән идек инде. Әмма Хрущевтан соң килгән Брежнев сүз иреген яңадан кыса башлады.

«Лира клубы»н шул чактагы алдынгы яшьләрнең иҗади кичәләрен уздыру өчен дә файдалана идек. Бу кичәләрдә сәхнәдән шактый гына ирекле сәяси сүзләр сөйләнеп, соңыннан гәзиттә эшләүчеләргә обком әһелләре тарафыннан катгый шелтәләр дә эләккәли иде. Билгеле булганча, «күп сөйләү» буенча беренчеләрдән булып Батулланың «яман» даны чыгып өлгерде. Әмма элеккеге актер буларак та, Батулла кичәләрне шәп алып бара.

Гәзитнең бүлек мөдире, ягъни минем нәчәлник — язучы Шамил Рәкыйпов. Һәр кичә аның хәер-фатихасы белән үтә. Әмма обком шелтәсе дә иң беренче булып аңа төшә.

Чираттагы бер кичәне үткәрүгә фатиха алу өчен мөдир бүлмәсенә кердем. Шамил абый кичә үткәрүгә каршы түгел, алып баручының кем булганын сорый. Мин Батулланы әйттем. Шамил абыйның чыраена сагыш кунды.

— Тагын күп сөйләп ташламасмы соң ул? — дип сорады ул миннән.

Мондый чакта мин ни әйтергә кирәген беләм инде:

— Юк, Шамил абый, без аңа әйтеп куярбыз, артыгын сөйләмәс.

— Сөйләмәс... сөйләмәс... — дип кабатлады Шамил абый мине үртәбрәк, — ә син беләсеңме соң, ул Батулланың теле бит мунчала белән генә бәйләп куйган, әһ дигәнче ычкына да китә...

Шулай да мин, Батуллага әйтеп куярбыз, ныгытырбыз, дип Шамил абыйны күндердем.

Кичәне алып баруны йөкләгәндә мин Батуллага Шамил абыйның «теле мунчала белән бәйләнгән» дигән сүзен әйттем.

Бу сүз Батуллага бик тә ошады, ул рәхәтләнеп көлеп җибәрде.

— Сәхнәдән ачы хакыйкатьне ярып салырмын дип уйлап йөри идем, — диде ул аннары, — Шамил абыйның сүзе бик ошады, эчемдәге рухи цензорыма әйтермен инде, сәхнәгә чыгар алдыннан телемне каеш белән бәйләп куяр.

Дәфтәр тышы гаепле

Билгеле булганча, драматург һәм прозаик Туфан Миңнуллин тормыштагы гыйбрәтле хәлләрне һәм аларга үзенең мөнәсәбәтен кызыл тышлы дәфтәргә теркәп куя. Аннары аларны «Кызыл тышлы дәфтәр»дән дигән гомуми исем астында республикабыз гәзит-журналларында бастыра бара. Шушы хакта ике язучы сөйләшеп тора:

— Мин Туфанга дәфтәр тышының төсен үзгәртергә тәкъдим итәм. Моның белән аның язмалары отачак кына.

— Монда дәфтәр тышының ни катнашы бар?

— Ул дәфтәрдән алып матбугатка бирелгән язмаларның шактый кызыл булуына дәфтәрнең тышы гына гаепле.

Барыйның бары

50 нче еллар азагы, 60 нчы еллар башында Казанның Бауман урамындагы «Казан» рестораны эчендә кечкенә генә бар эшли иде. Татарстан китап нәшрияты һәм Язучылар берлеге урнашкан Матбугат йорты аңа якын гына булганга, язучылар бу ресторанга һәм барга еш йөриләр. Әлеге барда бармен булып юан гәүдәле, гаять шаян һәм ачык йөзле Барый исемле бер татар абзыйсы эшли. Барый абзый язучыларны шул кадәр белеп бетергән ки, ул аларны ерактан ук сәламләп каршы ала. Эш шунда ки, ул елларда мондый барларда шәрабны бүлеп саталар иде. Нәшрияттан, гәзит-журналлардан гонорар алган язучылар шундук Барый абзый янына ашыгалар. Барый абзый аларны шул кадәр матур итеп, татлы сүзләр әйтә-әйтә сыйлый ки, ахыр килеп байтак язучы бөтен гонорарын монда калдырып китә иде. Җитмәсә, сыйлау сәнгатендә Барый абзый һәрвакыт ниндидер яңалык табып тора. Әйтик, барда язучылар күренүгә, Барый абзый алар белән һай-һу килеп исәнләшә дә: «Кадерләрем, бүген мин сезгә салават күпере ясап эчерәм, сез аны бары тик Барый абзагызда гына күрә аласыз», — дип эшкә тотына. Аның «Салават күпере» дигәне мондыйрак нәрсә икән: бокалның иң төбенә ул ике-өч йотымлык тозлаган томат согы сала. Шуннан соң бокалга пычак тыгып куя да, пычак йөзеннән генә аракы агыза. Болай иткәндә аракы сок белән аралашмый, ә үзенә аерым катлам булып сок өстендә тора. Бокалны күтәреп карасаң, өсте ак, асты кызыл — менә сиңа салават күпере. Болай итеп Барый абзый өче, әшәке тәмле аракы эчүгә бик нык җиңеллек китерә икән — аракы эчелеп бетүгә авызга тозлы томат согы килеп керә һәм син аракының әшәке тәмен белми дә каласың.

Барый абзый язучыларга тагын бер изгелек күрсәтә иде. Ул чакларда язучыларның күбесе гонорар биргән көннәрдән тыш шактый ярлы булалар иде (Ә хәзер инде без һәрвакыт ярлы). Ә баш төзәтәсе килә. Менә шул чакта Барый абзый ярдәмгә килә — баш төзәтүчегә шәрабны бушлай бирә. Әмма аның өстәл астында «кара кенәгә»се бар, кемнең ничә сумлык шәраб чөмергәне шунда язылып бара. Барый абзый белеп тора — гонорар бирү көне килеп җитте исә, бурычы булган һәр язучы аңа кесә тулы акча белән килеп кергәч, мондый шатлыклы көндә бурычын да түләячәк, хәтта чәйлек тә төртәчәк. Һәм ул шулай була да иде.

Барый абзыйның иң яраткан язучыларыннан берсе Нәби Дәүли иде. Бар тирәсендә Нәби абый беркайчан да вакланмады, үзен байларча тотты. Барый абзый белән аларның холыклары да килгән, куш тавыш белән бер гөрләтеп көлеп җибәрсәләр, «Казан» ресторанының тәрәзәләре ун минут буена зыңлап тора иде.

Нәби абый Барый абзыйны телдән генә булса да мәңгеләштереп калдырды. Ул аңа багышлап дүртьюллык шаян шигырь язды. Әлбәттә, «алкоголизмга каршы көрәш» белән илһамланган ул елларда бу шигырьне матбугатта бастырып чыгару мөмкин түгел иде. Ә хәзер инде була. Менә ул дүртьюллык.

«Казан»да бар бар иде,
Барда Барый бар иде
Барыйның барына кереп
Салган чаклар бар иде.

Укымышлылык турында

(Керәшеннәргә шаярту катыш юату сүзе)

...Укыган кеше — чукынган кеше...
...Чукынган кеше — чукыган кеше...
Татар үзе бит.. Татар үзе бит
Бу гыйбарәне тукыган кеше.

Шулай булгач син бер дә кимсенмә,
Башың горур тот, көрәш син, яме!
Татар әйтсә, ул хак әйтә инде,
Укымышлы, дип керәшеннәрне.

Әгәр бер абзый сүгенсә сиңа:
«Һай, син чукынчык керәшен!» — диеп,
Җавап бир: «Абзый, дөрес әйттең бит,
Туры оҗмахка керәсең! — диеп, —

Чукынганнарны укыганнар дип
Таныгач, инде гөнаһка кермә —
Чукынмаганнар укымаган дип.
Син үз-үзеңне кимсетә күрмә!»

«Бетсен бу әшнәлек, — диләр, —
Кулны кул юа», — диләр.
Кулны аяк юалмый бит
Әллә шуны белмиләр.

● Инде 1957 елда ук 9 нчы сыйныф укучысы Гәрәй Рәхим киләчәктә Рәсәй икътисадының һәм юмор-сатира жанрының бик нык түбәнгә тәгәрәячәген белеп, үз куллары белән аларны күтәрергә тотынган иде.

Бу рәсемдә сез аны трактор магнетосын кытыклаган чакта күрәсез — бәлки, берәр юмор килеп чыгар, янәсе...

Шәрыктән иңгән нур

(Әхмәд ибне Фазлан)

Һәр халыкның тарихында игътибарны гел үзенә тартып торучы исемнәр була. Тарихның аерым бер чорларында алар белән кызыксыну аеруча үсеп китә. Без хәзер нәкъ шундый дәверне кичерәбез кебек.

Бу тарту көченең, хәтта әйтергә мөмкин, аңлашылып бетмәгән мондый игътибарның сере нәрсәдә икән соң? Моның сәбәбе андый шәхесләрнең теге яки бу халыкның мәдәниятенә керткән өлешенең зурлыгына бәйле шикелле. Алардан калган мирас шул кадәр зур әһәмияткә ия була ки, доньяга аяк баскан һәрбер буын, аның әһәмиятенә исе китеп, бу мирасны янә күздән кичерә, аңа үз бәясен бирә һәм рәхмәтләрен укый. Әхмәд ибне Фазлан нәкъ менә шундый затларга керә

Аның тулы исеме Әхмәд ибне Фазлан ибне әл-Габбас ибне Рәшид ибне Хаммад. Бу кеше турында тарихта тулырак мәгълүмат сакланып калмаган. Галимнәргә аның Багдад хәлифәсе Җәгъфәр әл-Мөктәдирнең Идел Болгарстаны хакиме Шилке углы Алмыш-әлтабар хозурына җибәргән илчелегенең сәркатибе булуы билгеле Ул үзенең маҗаралар белән тулы сәяхәте, илчелекнең Багдадтан Болгарга кадәр үткән юлын тасвирлавы белән тарихка кереп калган. «Ислам энциклопедиясе» дә бу шәхес турында тулырак мәгълүмат бирә алмый. Әмма шунысы тәгаен билгеле ул 904-905 елларда Багдад хәлифәсенә Мисырны яулап алып биргән Мөхәммәд ибне Сөләйман дигән гаскәр башының өлкән битекчесе-чиновнигы булган Хәтта телгә алынган «Энциклопедия» Ибне Фазланның гарәп булу-булмавы хакында да өзеп кенә әйтә алмый Хәер, монысы безнең өчен алай ук әһәмиятле дә түгел. Әмма Ибне Фазланның ата-бабалары барысы да гарәп исемнәрен йөрткән.

Рәсми яктан бу илчелекне хәлифәнең хәрам агасы Сусан әр-Расси дигән кеше җитәкли, ә инде бөтен оештыру эшләрен алып баручы секретарь-сәркатип итеп Ибне Фазлан сайлана. Бу хәл хәлифә сараенда аның абруе шактый зур булуны күрсәтә. Шушыңа аның яклаучысы Мөхәммәд ибне Сөләйманның бу вакытта инде гүр иясе булуын да өстәсәң, илчелеккә сәркатипне билгеләгәндә беренче чиратта Ибне Фазланның эш йөртә белүе, зирәклеге-укымышлылыгы искә алынгандыр, дип уйларга нигез бар. Илчелекнең барлык оештыру эшләре, әлбәттә, сәркатип җилкәсенә төшкән һәм бу чараның нәтиҗәлелеге өчен дә ахыр чиктә ул җавап биргән.

Ерак һәм хәтәр юлга җыенган илчелек сәркатибе Ибне Фазлан алдына шундый бурычлар куела: болгарлар иленә килеп җиткәннән соң ул иң элек аларның хакименә хәлифә хәзрәтләренең хатын укып аңлатырга тиеш була. Аннан соң Ибне Фазланга болгар патшасына, аның якыннарына бүләкләр тапшыру йөкләнә. Ул шулай ук Алмыш-әлтабар үтенече буенча Ислам дине кануннарын өйрәтү өчен җибәрелгән мөгаллимнәр белән фәкыйһләрнең эшчәнлеген дә күзәтеп торырга тиеш була.

Тик сорау туа: мөэминнәр әмире әл-Мөктәдир беренче карашка шактый ышанычсыз күренгән шундый эшкә алынырга ничек үзенең фатихасын бирде икән? Ни әйтсәң дә, гарәпләр сакләби дип атап йөрткән, үзләре җиденче икълим-климат чигендә яшәгән бу төньяк халыкларына барып ирешү бер дә җиңел түгел бит Чөнки бу халыклар гарәпләргә билгеле дөньяның чигендә үк яшәгәннәр.

Эшнең башы исә 921 елның язында ук башланып китә — хәлифә хәзрәтләре сараена ерак-еракта, кайдадыр төньякта урнашкан илдән Габдулла ибне Башту әл-Хәзәри исемле бер илче килеп төшә. Ул хәлифә әл-Мөктәдирнең үзенә һәм сарай эчен саклаучылар башлыгы Надыйр әл-Һурамига болгарлар патшасыннан хатлар алып килә.

Беренче карашка, кайдадыр дөнья чигендә яткан Болгар иленнән дөньякүләм шаулаган Ислам мәмләкәте мәркәзе Багдадка илче җибәрү — кеше ышанмаслык хәл кебек тоела. Ни әйтсәң дә, бу ике дәүләтне — Гарәп хәлифәлеге белән тыйнак кына Болгар илен — берничек тә янәшә куеп булмый. Әмма бу беренче карашка гына шулай тоела. Әгәр дә без Шәрыкның Идел елгасы белән борын-борыннан ук ялганып киткән даими багланышларын искә төшерсәк, илче җибәрү алай ук сәер һәм кеше ышанмаслык эш булып күренмәс тә иде. Су юлыннан башка тагын кәрван юлларын да онытмыйк — алар Иделне Урта Азия белән тоташтырган. Харәземнән башланып китеп, кәрван юлы Арал диңгезен көньяклатып әйләнеп узган да коры плато Өс-йорт аша төрки-угызлар җиренә килеп чыккан, аннан Җаек суын кичеп, Идел буйлап төньякка күтәрелгән һәм Болгарга барып ирешкән. Ул заманда биредә халыкара ярминкә Ага-Базар булган. Шушы юл Бөек Ефәк юлының бер тармагы саналган. Болгардан ул төньяк-көнбатыш тарафка юнәлгән. Кыскасы, бу юл Төньяк Аурупа белән Шәрык илләрен тоташтырган, ә Болгар шуларның уртасында яткан. Әгәр дә без шушы факторны исәпкә алсак, мөэминнәр әмире әл-Мөктәдир хәзрәтләренә болгар илчесенең барып чыгуында алай ук кеше ышанмаслык нәрсә күрмәбез.

Ислам да Болгар иленә шушы ук юллардан үтеп керә. Шулай IX йөз ахырында Ислам дине монда тамыр җибәреп өлгерә, чөнки бу вакыт Болгар илендә Урта Азиядән чыккан мөселманнарның йогынтысы шактый көчле була.

Ни өчен Алмыш-әлтабар әллә кайдагы Багдад шәһәренә илчесен җибәргән? Бу аңа нигә кирәк булган? Күрәсең, бу адымны ясарга аны Болгар илендәге вазгыять, төрле сәбәпләр этәргәндер. Чыннан да, бу вакыт болгар кабиләләре үз дәүләтчелеген төзүнең икенче баскычына күтәрелергә инде өзер булалар.

Беренче баскычны алар әле YII йөз урталарында, Азак-Дон, Төньяк Кавказ, Кара диңгез буйларында яшәгән чакта ук узалар. Ул дәвердә Кобрат хан, болгар кабиләләрен бер йодрыкка туплап, Бөек Болгария дәүләтен төзүгә ирешә. Ләкин бу дәүләт кыска гомерле булып чыга. Кобрат хан үлгәннән соң хәзәрләр һөҗүменә каршы тора алмыйча дәүләт таркала. Яңа җирләргә күчеп утырган болгар этносына IX йөз ахыры — X йөз башында үзенең югалткан дәүләтчелеген торгызу өчен кабат шартлар туа. Ләкин моны тормышка ашыруга берничә сәбәп комачаулый.

Беренчесе, тышкы сәбәп — Болгар иленең Хәзәр каганлыгына бәйле булуы. Китабында Ибне Фазлан болгарларның хәзәр каганына салым түләвен турыдан-туры әйтә. Җитмәсә, ул әлтабарның улын үзендә әманат рәвешендә тота, көч кулланып, аның кызын да үзенә хатынлыкка ала икән.

Сәбәпләрнең икенчесе — Болгар илендә барлык ыру-кабиләләрне берләштерүче уртак монотеистик (бер аллага ышанучы) диненең булмавына бәйле. Әлегә болгар кабиләләре мәҗүси яки ярым мәҗүсиләр хәлендә күп аллаларга, ияләргә ышанып яшиләр. Бер аллага ышансалар, аларны берләштерү, бер байрак астына туплау мөмкинлеге ачылыр иде. Ә мәҗүсилек бу максатка берничек тә ярашлы була алмый. Һәм Алмыш-әлтабар шушы хәлне искә алып, үтә дә тәвәккәл һәм хәтәр эшкә алына: Аның ниятләрен хәзәр каганы белеп алса, башыннан сыйпамаячак, әлбәттә. Ә инде бу эш уңышлы барып чыккан очракта, Алмыш-әлтабар берьюлы ике куянга тидерәчәк: мөэминнәр әмире кулыннан Ислам динен кабул итеп, ул, беренчедән, үз халкын хак дингә күндерәчәк, икенчедән, бу адым аңа хәзәр каганы кулы астыннан чыгарга ярдәм итәчәк. Ник дигәндә, хәзәрләр белән көрәшергә аның әле көче җитеп бетми. Ә хәлифә әл-Мөктәдир хәзрәтләренә килеп сыену, аңардан яклау табу, мөселман дөньясыннан рухи-идеологик ярдәм-хәерхаһлык тою бүгенге көндә Алмышка сулаган һавадай зарури. Өстәвенә, Ислам мәмләкәтеннән фатиха алу болгарлар һәм күрше кавемнәр каршында әлтабарның абруен да үстереп җибәрәчәк.

Гарәп хәлифәлеге белән хәзәрләрнең үзара мөнәсәбәтенә килгәндә, алар гомер-гомергә бер-берсен дошман күрделәр. Шуңа күрә, хәлифә хозурына үз илчесен озатып, Алмыш-әлтабарның уңышка өметләнүе бөтенләй үк нигезсез булмаган.

Әлбәттә, дин хәтле дин кабул иткәндә, зур бер халык иман яңартканда барысын да салкын акылга, коры сәясәткә кайтарып калдыру бигүк дөрес булмас иде. Монда Ислам диненең эчке матурлыгы, камиллеге һәм кешелеклелеге дә зур роль уйнаган, хак дин болгарларны шушы сыйфатлары белән үзенә тарткан.

Башлаган эш, чыннан да, уңышлы тәгәлләнә. Әлбәттә, кыска гына мәкаләдә хәлифә сараенда барган катлаулы дипломатик уеннарга җентекләп тукталуның кирәге юк, чөнки бу мәсьәләләр А.Ковалевскийның әтрафлы мәкаләсендә бик яхшы яктыртыла.* Кыскасы, күпмедер вакыттан соң хәлифә сараенда, төньякта урнашкан сакләби-болгарларга илчелек җибәреп, алар белән элемтә урнаштыру турында уңай карар кабул ителә. Бу эшнең шулай тәгәлләнүендә мөселманнар әмиренең Ислам нурын ерак-еракларга тарату теләге белән беррәттән, Болгар илен хәзәрләр йогынтысыннан тартып алып, аларның борынына чиртәсе килүе дә үз ролен уйнамый калмагандыр.

Илчелек 921 елның 21 июнендә (һиҗри 309 елның 11 сәфәре) Багдад шәһәреннән юлга чыга. Борынгы калалардан Һәмәдан, Рәй, Нәйшапур кебекләрне һәм эреле-ваклы авылларны уза торгач, илчелек, ниһаять, Харәземгә килеп җитә. Иске Үргәнечтә бик озак тоткарланып тора, кышны да шунда чыга, аннан соң гына бары тик 922 елның 4 мартында (һиҗри 309 елның 2 зөлкагдәсе) гына кабат кузгала. Юлда илчелек угыз, бәҗәнәк, башкорт җирләре аша узып, Болгарга 922 елның 12 маенда гына (һиҗри 310 елның 12 мөхәррәме) аяк баса.

Алмыш-әлтабар урдасына килеп җитәргә бер тәүлек калачак, илчелекне дүрт болгар бие, әлтабарның туганнары, уллары зурлап каршы ала. Ибне Фазлан бу очрашуны болай тасвирлый: «Алар безне кулларына икмәк, ит, тары тотып каршы алдылар һәм юлны бергәләшеп дәвам иттерделәр. Падишаһ исә безне урдасыннан 2 фәрсах (12 чакрым) арада каршы алды. Күреп алганнан соң атланган атыннан төште дә, бөек һәм кодрәте чиксез Аллаһе Тәгаләгә рәхмәтләрен әйтеп, каршыбызда тез йөгенде». Шулай ерак сәфәрдә күп михнәтләр чигеп, 3 мең кешелек хәлифә илчелеге, ниһаять, юлын тәгәлли. Соңгы өч-дүрт көн дәвамында Алмыш-әлтабар урдасына төрле яктан Болгар иленең биләре, түрәләре, гаскәриләр һәм гади халык агыла, алар анда мөэминнәр әмиренең хатын игълан итүдә катнашырга әзерләнәләр.

Менә сәяхәтнең иң җаваплы мизгелләре якынлаша — хәлифә әл-Мөктәдирнең мәктүбен-хатын уку тантанасы башлана. Бу мәрасимне үткәрү өчен илчелек җитәкчеләре үзләре белән алып килгән ике кара байракны сүтеп җибәрәләр, әлтабарга бүләккә дип билгеләнгән ак юртак сыртына зиннәтле ияр салына, Алмыш-әлтабарга хәлифә сарае түрәләре генә кия торган затлы кара киемнәр, башына чалма киертелә. Бу тантананы үткәрүче җаваплы кеше Ибне Фазлан, ниһаять, хәлифә хәзрәтләренең хатын кулына ала да ашыкмыйча гына аерым бер вәкарь белән укырга керешә. Алмыш-әлтабар хатны аягүрә баскан килеш тыңлый.

«Тылмач укылган һәр сүзне тәрҗемә итә барды. Хат укылып беткәч, алар (болгарлар) барысы берьюлы «Аллаһе әкбәр! Аллаһе әкбәр! Аллаһе әкбәр!» дип шундый итеп кычкырдылар ки, бу авазлардан хәтта җир тетрәнеп куйды», — дип яза бу хакта Ибне Фазлан. Шулай Болгар иле Исламны дәүләт дине буларак рәсми рәвештә кабул итә. Һәм, хак дингә күчеп, зур мөселман дөньясының аерылгысыз бер өлешенә әверелә. Шушы акт нәтиҗәсендә Болгар иле дөньяның сәяси картасында инде тәмам оешып-калыпланып җиткән дәүләт буларак урын ала.

Багдад илчелеге Болгарга килеп киткәннән соң Ислам динен кабул иткән төньяк дәүләтләрнең иң ерактагысын Шәрык илләре аеруча зур игътибар белән күзәтә башлыйлар. Сәүдә әһелләрен инде әйткән дә юк, мөселман өммәтендәге байтак галим-голәма һәм язучыларны Болгар дәүләте торган саен үзенә ныг-

рак тарта. География һәм башка өлкәләргә багышлаган хезмәтләрдә болгарлар еш телгә алына. Тора-бара бу традициягә үк әверелеп китә, бабаларыбыз турындагы мәгълүматлар китаптан-китапка күчерелә һәм бу хәл күтәрелә барган Болгар дәүләтенең халыкара абруен үстерергә ярдәм итә.

Гарәп тарихчысы Әл-Бәлхи үзенең 920-921 нче елларда, ягъни Ибне Фазлан Болгарга килгәнче иҗат ителгән «Әшкәлел-билад» («Җир өсте күренешләре») дигән хезмәтендә Болгарда җәмигъ мәчете булуын яза. Аннан ерак булмаган Суар шәһәрендә дә шундый ук мәчет бар, ди. Аның замандашы, гарәп галиме, тарихчы Ибне Рөстә дә күпчелек болгарларның Ислам динен тотуын, авылларда мәчетләр һәм мәктәпләр булуын, аларны имамнар белән мөәзиннәр тәрбия кылуын яза. Ф.А.Хвольсон сүзләренчә, Ибне Рөстә дә үз хезмәтен 913 елга кадәр, ягъни Багдад илчелеге юлга чыкканчы язган булган.

Әлеге хәбәрләр Ибне Фазлан Болгарга килгәнче үк Исламның бу җирдә тирән тамырлар җибәрүе хакында сөйли. Табигый, Ислам дәүләт идеологиясенә әверелгәннән соң гарәп телен өйрәтү, дин китапларын укыту эше бермә-бер җиңеләя төшкән. Укый-яза белү белән беррәттән болгарлар арасында мөселман мәдәнияте-сәнгате, китапка хөрмәт тә киң тарала. Шушы нигездә болгарларның үз әдәбияты, фәне, фәлсәфәсе үсеп чыга, тарих, дин, хокук, тыйб-медицина һәм башка фәннәр буенча хезмәтләр языла башлый.

Иделнең аскы агымында ...ашкан Саксин каласында күпмедер вакыт яшәп ...ткән испан гарәбе Әбу Хамид әл-Гарнатый (1135-1136 һәм 1150 нче елларда Болгар шәһәренә дә сәяхәт кыла һәм анда шәһәрнең казые, «Болгар тарихы» дигән хезмәт язган Якуб бине Ногман белән очраша. Бу галим үз вакытында борынгы Нәйшапур шәһәрендә белем алган була. Болгар иленнән чыккан кайбер зыялылар башка илләргә китеп торалар, анда хезмәтләре белән дан-шөһрәт казаналар. Урта Азиядә һәм Шәрык илләрендә киң таралган «Әл-җәмигъ», «Әт-тарика», «Әл-фәваид» кебек хезмәтләрне иҗат итүче Хуҗа Әхмәд әл-Болгари исемен тарих безнең көннәргә җиткергән. Галимнәр фикеренчә, ул телгә алынган Әбу Хәмид әл-Гарнатыйга хәтле бер гасыр элек яшәгән. Ә XII йөзнең беренче яртысында иҗат иткән Сөләйман бине Дауд Суваринең фарсы телендә әхлак мәсьәләләренә багышланган 70 бүлекле хезмәт язуы билгеле. Күпмедер вакыттан соң, ул бу хезмәтен гарәп теленә тәрҗемә иткән, аны «Нөзһәтел-көлүбел-мәраз» («Авыру күңелләрне сөендерүче») дип атаган. Соңрак бу хезмәтен яңабаштан карап чыгып һәм бераз кыскартып, аңа «Зәһрәтер-рийаз вә нөзһәтел-көлүбел-мәраз» («Авыру күңелләрне сөендерүче бакча чәчәге») дип исем кушкан. Бу хезмәт Идел-Урал, Хәзәр диңгезе тирәләрендә генә таралмыйча, Анадолу, Урта Азия, хәтта Һиратта да билгеле була. Һәм теләгән очракта тарих чоңгылыннан мондый мисалларны тагын да тартып алып булыр иде.

Бу мисаллар олуг мөселман дөньясына килеп сыенган Болгар дәүләтендә рухи мәдәниятнең бик нык үсеп китүе хакында сөйлиләр. Әгәр 922 елда рәсми рәвештә Ислам дине кабул ителмәсә, болгар халкында Кол Галинең «Кыйссаи Йосыф»ы кебек гүзәл әсәр туар иде микән. Болгар-татар мәдәниятендәге күп казанышлар фәкать Исламны кабул итүгә бурычлы.

Рушан ШӘМСЕТДИНОВ рәсеме.

Яңа дин кабул итү үзенә күрә бер доминанта, ягъни этәргеч көч сыман хезмәт иткән һәм шушы вакыйга Болгар иленең мәдәни җәгәрен хәрәкәткә китергән. Ә инде бер-ике гасырдан соң бу үсеш без әле дә горурланып туймаслык гаҗәеп зур нәтиҗәләр биргән.

Шушы хәлләрне искә алганда А.Ковалевскийның телгә алынган мәкаләсендәге кайбер фикерләр инде тәнкыйтьне күтәрә алмыйлар дип әйтергә туры килә. Мәсәлән, ул болгарларның «төп массасы» Ислам динен кабул итүдән баш тарта, һәм акрынлап көнбатышка, Иделнең уңъяк ярына күчеп утыра башлый. Халыкның бу өлеше үзенең элекке суваз-чуваш атамасын саклап кала, — дип яза. Монда шуны искәртергә кирәк: беренчедән, Иделнең уңъяк яры беркайчан да болгар халкының «төп массасы» яшәгән җирләр булмаган. Моңа Ибне Фазлан үзе үк күрсәтә. Ул, суваз ыруының бер өлеше үзен мөстәкыйль дип игълан итте һәм аларның башлыгы ниндидер Вырыг дигән бер адәм иде, дип яза. Моннан сувазларның бер өлеше генә аерылып чыккан булуы ап-ачык аңлашыла. Ә болгар конфедерациясендә ыру-кабиләләр суваздан башка да байтак булган.

Икенчедән, болгар мәдәнияте, тарихи перспективада алганда болгар-татар мәдәнияте дә — мөселман дине белән сугарылган мәдәният. Кайберәүләр болгар мирасына тартып кертергә тырышкан чуваш халкы исә беркайчан да мөселман динен тотмаган һәм бу археологик материаллар ярдәмендә кире кагып булмаслык итеп күптән исбатланган нәрсә.

Әхмәд ибне Фазланның болгар-татар тарихына керткән өлеше турында уйлана башласаң, хәтергә ирексездән «тарих атасы» дип исем алган борынгы грек галиме Геродот килеп төшә. Әйе, Ибне Фазлан да безнең тарихка, Геродот Аурупа халыклары тарихы өчен башкаргандай, зур һәм мөһим өлеш керткән шәхес. Бу тыйнак һәм эшлекле гарәп безнең тарихыбызны коткарып калган олуг затлардан саналырга хаклы. Шушы хезмәте белән ул үз исемен мәңгеләштергән. Аның юлъязмалары сакланмаган очракта, борынгы заманнарда булып узган бихисап вакыйгалар чылбырында безнең өчен үтә дә кадерле һәм мөһим бер буынның җитешмәве үзен бик нык сиздерер иде. Һәм без аңа моның өчен гомергә рәхмәт әйтергә, аны олыларга тиешбез.

Мин үзем, мәсәлән, көннәрдән бер көнне мәдәниятебез һәм тарихыбыз каршында күрсәткән бөек хезмәте, шәхси фидакярлеге өчен Әхмәд ибне Фазлан хәзрәтләре истәлегенә болгар-татар җирендә һәйкәл куелыр дигән өметтә яшим. Бөек хезмәте белән ул үз-үзенә һәйкәлне инде куйган. Чират безгә җитте.

Солтан ШӘМСИ.

• Кит: Ковалевский А.П. Книга Ахмеда ибн-Фадлана о его путешествии на Волгу. Харьков, 1956.

Сакләбиләр патшасына

әл-Мөктәдирдән илче булып барган Әхмәд ибне Фазлан китабы

(Борынгы текстны СОЛТАН ШӘМСИ эшкәртте һәм тәрҗемә итте)

Бу китап Әхмәд ибне Фазлан ибне әл-Габбас ибне Рәшид ибне Хаммад тарафыннан язылды. Ул мөэминнәр әмире әл-Мөктәдир хәлифәнең сакләбиләр[1] патшасына җибәргән илчесе иде. Шушы сәфәрендә Әхмәд ибне Фазлан төрекләр, хәзәрләр, руслар, болгарлар , башкорт һәм башка кәвемнәр яшәгән илләр аша узды. Китабында ул анда күргәннәре, әлеге халыкларның дин тотудагы үзенчәлекләре, патшалары һәм башка эш-гамәлләре, йолалары хакында хәбәрләр өсти.

Мин, Әхмәд ибне Фазлан, бәян итәм:

Болгар патшасы Шилке углы Алмыш әлтабарның[2] мөэминнәр әмире әл-Мөктәдиргә юллаган хатында ул үз хозурына дин өйрәтүче, шәригать хөкемнәреннән дәрес бирүче, мәсҗетләр төзи белүче, төзелгән мәсҗетләрдә хәлифә хәзрәтләре хөрмәтенә гыйбадәт кылырлык һәм дә үзе белгән җирләрдә вәгазьләр сөйләрлек кешеләр җибәрүен үтенде. Шушы ук хатында Алмыш-әлтабар дошмани патшалардан саклану өчен хәлифә хәзрәтләренең аңа кальга-ныгытма төзәргә ярдәм итүен дә үтенде. Бу эш мөэминнәр әмире әл-Мөктәдир хәлифәнең хатта телгә алынган үтенечләрне кабул итүе, аларны үтәргә фатиха бирүе белән тәмамланды.

Бу эштә хәрам агасы Надыйр әл-Һурами арадашчы сыйфатында йөрде. Миңа исә болгарларның әлтабарына хәлифәнең җавап хатын укып бирү, җибәрелгән бүләкләрне тапшыру һәм фәкыйһләр белән мөгаллимнәр өстеннән күзәтчелек итеп тору вазыйфалары йөкләнде. Болгар әлтабарына кальга-ныгытма төзү һәм дә фәкыйһләр белән мөгаллимнәргә хезмәт хакы түләү өчен тотылган акчалар Надыйр әл-Һурамига тәгаенләнде. Акчаларны безгә юлда, Харәзем өлкәсендәге Арсахушмисан дип аталган бер утар бәрабәренә түләячәкләр иде. Моңарчы бу утар хезмәтеннән азат ителгән вәзир Ибне әл-Фуратныкы булган.

Болгар патшасыннан әл-Мөктәдир хәлифәгә илче сыйфатында чыгышы белән хәзәрләрдән булган Башту углы Габдулла дигән кеше килде. Ә хәлифә ягыннан илче итеп Надыйр әл-Һурами кешесе Сусан әр-Расси билгеләнде, аны төрек Тәкин әт-Төрки, сакләби Барс әс-Сакләби һәм, әйткәнемчә, мин үзем озата бардык. Шулай итеп, миңа әлтабарның үзенә, хатынына, улларына, туганнарына һәм дә биләренә тапшыру өчен бүләкләр бирелде. Тагын болгар әлтабары Надыйр әл-Һурами аша соратып алган даруларны да мин тапшырырга тиеш идем.

Менә ерак сәфәргә чыгып китәр көн дә килеп җитте. Без Мәдинәт әс-Сәламиннән[3] 309 елда сәфәр аеның 11 төне узгач чыгып киттек (921 елның 21 июне). Әүвәл без ән-Ниһриванда тукталдык. Анда бер көн ял иткәннән соң ашыгычлык белән әд-Дәскәрәгә юнәлдек. Анда өч көн тордык. Аннан соң бернигә дә карамыйча шундый ук тизлек белән Хулванга килеп җиттек. Монда ике көнгә тукталдык. Аннан Кармисинга юл алдык, монда ике көн тордык, юлны дәвам иттереп, Һәмәданга барып ирештек тә анда өч көнгә тукталдык. Моннан соң юл безне Сәвәгә китерде, анда ике көн тордык та әр-Рәйга барып җиттек. Биредә безгә унбер көнгә тоткарланырга туры килде, чөнки Саглукның туганы Әхмәд бине Галине көттек. Ул бу вакытта Хувар әр-Рәйга киткән булган икән.

(Бу вакытта әр-Рәй шәһәре өчен хәлифә, саманыйлар һәм Иран феодаллары арасында туктаусыз көрәш бара. 915-916 нчы елда, әр-Рәй шәһәрен хәлифә әл-Мөктәдир гаскәрләре басып алганнан соң, анда хәлифәнең губернаторы билгеләнә. Бераздан (919 нче елда) шәһәрне Әхмәд бине Гали үз кулына төшерә. Хәлифә файдасына ел саен 160 мең динар акча түләргә риза булганнан соң гына хәлифә әл-Мөктәдир аны рәсми рәвештә шәһәр хакиме итеп раслый. Шулай итеп, илчелек юлны дәвам иттерү өчен Әхмәд бине Гали ярдәменә мохтаҗ булган, күрәсең. Аны көтеп торуның сәбәбе шуның белән аңлатыла. — С.Ш.).

(Дәвамы бар).

---

[1] Сакләби — ул заманда гарәпләр төньякта яшәүче халыкларны «сакләби» дип атап йөрткәннәр. Бу очракта «сакләби» сүзе «болгар» дигәнне аңлата.

[2] Әлтабар — болгарлар хакименең титулы.

[3] Мәдинәт әс-Сәламин — Багдад шәһәренең икенче исеме, ягъни Иминлек шәһәре

Индус СИРМАТОВ

МУЛЛАГАЛИ НИ КҮРГӘН?

Кар кешеләре. киң җиһаннан килгән җан ияләре. әллә кайсы күл төбендә яшәүче галәмәт тә зур җанварлар турында онып да башлаган идек инде. Сөн буе авылларының берсендә яшәүчеләр үткән җәйдә тагын өкәмәт бер хәлгә очраганнар. Чияле дигән авылның Муллагали исемле кешесе үз урманнарында бер җан иясен күреп кайткан.

— Ничек булдыралсаң. шулай яз. — диде ул. — Түлке соңыннан миңа претензи белән килерлек булмасын. Ачуым да бер килмәгәе. кешегә яхшылык итим дип. дөресен генә сөйлисең дә. шуны әллә нилә кыландырып. болгатып. күпертеп. йә гәзиткә, йә тагын берәр җиргә язып бирәләр. Укып карагач. моны мин сөйләдем микәнни. дип аптырап каласың Шуның өчен дә мин сиңа исем-фамилиямне әйтеп тормыйм. Чияле авылына килсәң. мине любой дурак белә. Авыл башына кереп сызгыр да. Камыт Исламы кайда яши. дип кенә сора. хәзер табып бирәләр. Түлке мин сөйләгәннәрне берәүгә дә әйтәсе булма, Муллагалидән үзем ишеттем. диген.

Башта. бер-ике сүздән генә булса да. ул кеше белән ничек очрашуымны әйтеп узарга кирәктер.

Үткән җәй эссесендә әлсерәп электричка көтеп утыра идем. Ни өчендер миңа таба карый-карый бер кеше узып китте Берәр танышымдыр. дип кенә уйладым да. бүтәнчә аңа игътибар итмәдем. Дөресрәге. аның турында оныттым. Әмма ул. үзен оныттырырга теләмәгәндәй. тагын әйләнде. Бу юлы ул инде хәтта елмайгандай да итеп узды.

Шулайдыр. берәр танышымдыр. беткәнмени күпер башында кул сугыштырган кешеләр, дип. укый торган гәзитемә яңадан чумдым. Тик бу юлы да озак утырырга туры килмәде. Теге кеше, бәйләнчек кигәвендәй, өченче кат әйләнеп килде.

Монысында инде ул янымда ук эскәмиягә чүмәште. Кулъяулыгын чыгарып. тирләгән маңгаен сөртте дә. берәүгә дә атамыйча гына:

— Ачуым да бер килмәгәе: чыстый миләр агып чыга инде бу кызудан. — дип куйды.— Карале, малай. син «Мәдәни җомга» укыйсың түгелме соң? Әллә шунда эшлисеңме? Син болай үзе. грамытный кешегә охшагансың. Менә мин сиңа бер әйбер сөйлим әле. Мин аны үзем үк язып җибәрермен бер дип йөри идем. Вакыт кына тими. Аннан минем грамыт азрак бит инде. Урта мәктәп кенә бетергән мин. Син берәр техникум-мазар бетергәнсеңдер әле. Шулаймы? Шулай булмаса, «Мәдәни җомга»да эшли алмас иең. Ай-һай, малай, анда эшләргә дә баш кирәктер ул. Әллә берәр институт-мазар бетердеңме? Син кайсы гәзиттә эшлисең соң шулай да?

— Берсендә дә түгел.

— Соң, кулыңда гәзит ич.

— Болай гына укыйм.

— Болай гына гәзит укымыйлар Кайда эшләгәнеңне юри яшерәсеңдер әле. Синең бармаклар да яза торган кешенекенә охшаган. Син менә, яза торган кеше булсаң. язып җибәр әле. Ачуым да бер килмәгәе. рәхәтләнеп укырлык бер нәмә сөйләем мин сиңа хәзер.

Барыбер котылып булмас моннан. электричка килгәнче такылдасын әйдә, дидем дә. тыңларга әзер икәнемне сиздереп. аңа карадым

— Болай ул. Сөн елгасы ул. иптәшкәй. парахут йөрерлек үк булмаса да, бөләкәй елга түгел. Бераз төбен казысаң, парахут та керергә булыр ие әле. Менә шул Сөн елгасы. иптәшкәй. безнең Татарстан белән Башкортстанның границасы. Минзәлә или Чаллы ягыннан карагандa Сөннең бу ягында Татарстан. теге ягында Башкортстан булыр. Теге якта Татарстанның бер адым да җире юк дияр ием. ялганчы булырмын. Өч дүрт авыл бар анда Шуларның берсе Чишмәле баш. берсе Чияле. туест безнең авыл. Чишмәле баш дигәнендә утызлап өй булса. Чияле дигәнендә алтмыш ике өй булыр Икесе дә тау башында утыра алар Сөнгә аякларын сузып. Ну ул таулар инде Сөн буйлап тезелеп китә дә Урал тавына барып тоташа диләр Дөрестерме юктырмы. ансын белмәем. барып караганым булмагач. Ну менә шул ике авылның урманнары .. Алар тайга урманына тоташа Ансын точно беләм Картадан караганым бар Элек бу ике авыл урманында куяннан башка бернәмә юк ие. Хәзер бүре дә бар, төлкесе дә. кабан чучкасы да. Пошилар да бик хәтәр күп Әле кайчандыр аю да күргәннәр дип сөйләнделәр Тайгадан килми. каян килсен инде алар? Ну. малай. аның монысы әллә ни гаҗәп түгел әле Менә Муллагали күргәне исең-акылыңны җуярлык.

— Юлбарыс күргәнмени? — дидем мин, кызыксына төшеп.

Бу кеше миңа. исәр бәндәгә караган кебек багып алды да. мыскыллагандай көлеп куйды

— Мин сине юньле кешегә санап утырган булам тагын Юлбарыс кына булса. мин аны сиңа сөйләп тораммыни! Юлбарыс күрмәгән кешемени мин?! Ботаник бакчага барганың юкмы әллә? Клетка эчендә әрле-бирле килеп йөри бит ул. юлбарыс Ә Муллагали күргәне. ачуым да бер килмәгәе, юлбарыстан ике-өч тапкыр зуррак. ди.

— Белмим шул. нинди хайван булыр икән ул Сөн буенда?

— Кем әйтте аны сиңа хайван дип? Кеше ди ул. По крайней мер Муллагали шулай сөйләде. Бүтән кеше сөйләгән булса. ышанмас та ием. Муллагали андый кеше түгел Эчми. тартмый, дигәндәй. ну. аккуратный кеше инде. Бөтен авыл белә аның парядычный икәнен. Бер ел помбригадир булып да эшләде әле ул. Икемә, өчме атна Юньсез кешене помбригадир итеп куялармыни?!

Вәт шул: Авылыбыз зур түгел дим бит. Кырык җиде генә хуҗалык. Авыл зур булмагач, терлек-кура да күп түгел. Терлек азлыктан көтүче дә яллап булмый. Өй рәтеннән чиратлап үзебез көтү көтәбез. Бер сыерың бар икән — бер көн көтәсең. өч сарыгың булса — шулай ук бер көн. Бер сыерың, өч сарыгың бар икән, значит. ике көн.

— Өч кәҗәң булса?

— Кәҗә дә булдымы мал! Кәҗә асрарга Чияледә дураклар яши дип белдеңме?! Бүлдерми генә тыңла син; яме! Минем вакыт — абрез. Пуез килгәч то китәм мин. Конендә Арчага барып кайтасым бар. Кайда калдым әле? Ә, әйе. чиратлап көтү көтәбез. Кайсы числода икәнен хәзер оныттым инде. Берконне чират Муллагалигә җитә. Аның ике сыеры. ике танасы. бер фермалык сарыгы бар. Вапшым. аз дигәндә. бер атна йөрергә тиеш бу. Аккуратный булса да. хитри ул Муллагали. Көтүне үлән мулрак бер җиргә кертеп туплый да. үзе тегендә-монда чыштыйн-пыштыйн китеп бара. Бу көнне дә Алкаби тавы итәгендә кеше мәңге аяк басмаган чытырманлыкка куып кертә дә көтүне. үзе. өенә кайтып. тегесен-монсын эшләштереп китмәкче була. Ну шуннан. кояш төшлеккә күтәрелеп. малларны Сөн буена куар вакыт җиткәч. көтү янына барса, бөтен сыерлар чытырманлык читенә чыгып түгәрәкләнеп басканнар. ди. Түгәрәк эченә сарыклар кереп тулган. ди Берсе бер нәмә ашамай. бөтенесе, башларын күтәреп. чытырманлыкка карап торалар. ди Бүре-мазар бардыр. дип уйлап ала инде бу. Шуннан. чыбыркысын шартлатып. көтүне Сөн буена таба куалый башлый Сарыкларның исәбенә чыга торган түгел инде. Сыерларны саный — барсы да исән Шуңа сөенеп, китә башлый Кинәт. ди. Муллагали әйтә. чытырманлыкта. чаж-чож килеп. әллә нәмә чабып узды. ди Бүре булса. көпә-көндез кешегә ташланмас әле дип. үз-үзен тынычландырып, көтүне алып китә бу. Киткәндә барыбер шикләнеп артына борылып карый Караса, тегендә: чытырманлык эчендә, печән кибәненнән бер кара шәүлә карап тора моңа Бөтен тәнен йон баскан Башы мендәр чаклы. ди, ике күзе ике чәй тәлинкәсеннән ким түгел. ди авызы да ачык ди. Тырышыбрак ачса. авызына сарык бәрәне шуып кына кереп китәрлек. ди инде. Шуннан ди Муллагали әйтә, куркудан кычкырып җибәрдем дә бу мине берәр нәмә эшләтеп ташламасын тагын ичмасам кеше-мазар күренмиме дип тирә-ягыма карана башладым ди Үзем чыбыркы шартлатам ди Шул арада шатыр-шотыр агач ботаклары сынган тавышка борылсам теге кеше выжлап чытырманлык эченә кереп китте ди Имән куаклары өстеннән без алабута арасыннан чабып узган кебек кенә сикереп кереп китте. ди Шуннан соң. Муллагали, бу нәмә кешегә зыян итә торган түгел, үзе дә чыбыркы шартлавыннан курка икән. дип тынычлана да, көтүне Сөн буена алып китә Кичке якта көтүне Алкабига алып бармаган инде. шүрләгән Кич авылга кайткач сөйләгән ул. Ышанмаганнар. Көлгәннәр генә үзеннән

Икенче көнне Алкаби тавы ягына борылып та карамадым. ди Өченче. дүртенче көнне дә Вапшым. чиратының соңгы көнендә яңадан көтүне шунда алып чыга бу Мондаен коры җәйдә хайванны үләнсез җирдә интектерүдән файда юк бит инде Алкабидә үлән мул. Үлән мул булгач. маллары да рәхәтләнеп йөри Төш җиткәндә аларны Сөн буена төшерәсе бит инде Андый чакта без сыер хайваннарын гына саныйбыз Муллагали дә шулай итә инде Вапшым. бер сыер малы чыкмый моның Авылда кемнең нинди малы бар икәнен беләбез бит инде Муллагали әйтә. Тәкә Сабирының кышлау үгезе юк. ди. Сөзгәк Шуны эзләп чытырманлык арасында йөри торгач. Алкаби тау итәгенә төшеп җитә бу. Әле әйтмәгәнием. безнең Алкабинең бер сикрите бар аның Элек заманда тау итәгендә бер зур тишек булган Ачуым да бер килмәгәе. атка атланып кереп йөрерлек ие. дип сөйли картлар. Тора-бара ул тишек бәләкәйләнгән, аннары бөтенләй күмелгән. Без аны чүкеп тә карамакчы иек. картлар тучны гына урынын күрсәтә алмадылар. Вапшым. Муллагали тау итәгенә төшеп җитсә. тишек. ди И диствителни. рәхәтләнеп атка атланып керерлек. ди Тишек авызы алдында гына комлы кызыл балчык өстендә әллә ниткән өкәмәт эзләр. ди. Үзе кеше табаны эзенә охшаган. ди. Түлке галәмәт тә зур, ди. Ачуым да бер килмәгәе. илле тугызынчы размер итек киюче генә калдыра ала ди мондый эзне. Әле тагын дүрт бармак эзе — бер якка, бишенче — баш бармак эзе икенче якка, кырыйгарак карап тора, ди. Ул бармак уңган чөгендердән дә ким булмаска тиеш. ди.

Аптырап карап тора моңа Муллагали. Караса, сыер тоягы эзе дә бар. ди. Тәкә Сабирының сөзгәк үгезе шунда кереп киткәнме әллә. дип, тишеккә якынрак килсә, бервакыт, үкереп. дүртаяклап чабып. сөзгәк үзе килеп чыга. Ә койрыгына теге нәмә ябышкан. ди. Чабышып чыгалар да болар, чыга-чыгышка Муллагалине дә бәреп егалар Ну. үзе егыла инде тегеләр бәрелгәч. Или куркуданмы.

Сикереп торса, сөзгәк белән теге нәмәнең сугышып ятуларын күреп ала бу. Үгез, малай, дүрт аягын да терәп баскан да әрле-бирле алпан-тилпән килеп саклана. ди. Ә теге нәмә моны ике мөгезеннән эләктереп алды да, бөгеп тә салды. ди. Сабир сөзгәге. мескен, яман итеп үкерде дә «гөрс» итеп барып төште, ди.

Муллагали нишләсен инде, бичарадан — ни чара, дигәндәй, чыбыркысын шартлатып җибәрә. Шуннан теге нәмә моңа таба ямьсез итеп карап ала да тау тишегенә чабып кереп китә. Мин аны юньләп күрә дә алмадым, ди Муллагали Ир кеше икәнен генә күреп калдым, ди.

— Ансын күрергә өлгергәнмени? — дидем мин көлемсерәп. Камыт Исламы минем мыскыллап көлүемә игътибар да итеп тормады.

— Күрмәскә. Әле кайтып сөйләгәч, Чияле хатыннары, бер генә кичкә безнең авылга менеп төшсен иде ул, дип көлешкәннәр ди, паразитлар Аларга тел чарларга гына булсын.

Муллагали сөзгәкнең сыртына чыбыркы белән шартлатып сыдыра да, үгез сикереп торуга, тегенең койрыгына ябыша. Үгез дә, мескен, тау башына менеп җиткәнче тын да алмый чаба Менеп тә җитә, тагын гөрселдәп егыла Вапшым, үгезне авылга алып кайтып суйдылар Дүрт кабыргасы шартлап сынган ие.

Ул арада электричка килеп җитте дә, без икебез ике вагонга кереп киттек Камыт Исламы минем турыда нәрсә уйлагандыр, әйтүе кыен Мин үзем кешене рәнҗетүемә юл буе үкенеп бардым Мәзәк өчен генә сөйләгән булса, аерылганда, күзләрен мөлдерәтеп, бигрәк тә рәнҗүле үпкәле караш белән карап калмаган булыр иде

Дөньяда нилә генә юк Әгәр дөресен сөйләгән булса? Чыннан да Муллагали ни күргән икән?

КЕШЕ ХӘЛЕН КЕШЕ БЕЛМИ

Фатир мәсьәләсе, элекке СССРның, кайсы гына почмагына барып чыксаң да, бик күпләрнең иң авырткан урыныдыр, мөгаен. Шушы хакта сүз кузгалгач, минем бер танышым, үзе кичергәннәрен, үз интегү-борчуларын бер уч төбенә төйнәп дигәндәй, болай дип әйткән иде:

— Фатир — ул бәхет тә, яхшы кәеф тә, сәламәтлек тә, уңышлы эш тә, яхшы тормыш та.

Ә фатирың, ягъни өең булмаса нишләргә? Шуларның барысыннан да мәхрүм булу дигән сүз түгелме соң бу? Өстәвенә, балаларың, ирең дә авыру булса...

Казанның Можайский урамындагы 10 нчы йорттагы 7 нче фатирда (5 нче бүлмә) яшәүче Миңлегөл Сөләйманова менә шундый хәлдә гомер сөрә. Ул 12 квадрат метрлы бүлмәдә ире, алты яшьлек кызы, ике яшьлек улы белән яши.

Менә санитария-эпидемиология күзәтүе буенча дәүләт комитетының Киров районы хакимияте башлыгына юллаган хатыннан бер өзек: «Дәүләт санитария-эпидемиология шәһәр үзәге белгечләре уздырган тикшерү гаризада күрсәтелгән яшәү шартларының дөрес булуын раслады: бүлмә диварлары, түшәме юеш, почмаклар күгәрек белән капланган, һаваның чагыштырмача дымлылыгы 92-96 процент тәшкил итә. Бу исә тиешле дымлылыктан шактый артып китә».

Бу фатирдагы башка бүлмәләрдә ялгыз ир-атлар яши.

Редакциягә М.Сөләйманова юллаган хаттан өзек: «Аларның берсе дә кухня, коридор, бәдрәф җыештырмый. Балаларым хакына бу ир-атларның пычрагын гел миңа җыярга туры килә. Әлеге ир-атларның берсе еш кына притон оештыра. Бу «бәйрәмнәр»дән соң бәдрәф идәнендә аларның кече хаҗәтен башкарудан җыелган сыеклык тонып тора башлый. Әлеге исерекбашны, миңа үч итеп, 19 нчы торак-эксплуатацияләү идарәсе урнаштырды».

Миңнегөл, аның ире, балалары менә шундый мәхшәр оясында интегеп гомер итә. Андый шартларда яшәгән кешегә сәламәтлек, сау йөрәк каян килсен инде? Миңлегөлнең олы кызы туберкулез таякчыгы йоктырган һәм фтизиатр күзәтүендә тора. Ә бу исә кыз әлеге чир белән авырып китү куркынычы алдында тора дигән сүз. Ике яшьлек улы Айрат биш айлык чагыннан бирле бронхиаль астмадан җәфалана. Сау кеше өчен дә нык зарарлы һаваны сабый сулый алмый интегә. Миңлегөлнең икенче группа инвалид иренә дә тынычлык кирәк. Борчу-мәшәкатьләр, ыгы-зыгылар аның саулыгын артка сөйри. Ә 12 квадрат метрлы бүлмәдә дүрт кеше яшәгәндә һәм аның икесе кече яштәге бала булганда, тынычлык каян килсен соң?

Гаилә башта шушы 12 квадрат метрлы бүлмәдә барысына да түзеп дигәндәй яши. Булганына шөкер итеп айларны, елларны уздыралар.

Барысы да икенче балалары — уллары Айрат туар көннәр җиткәч башлана. Моңа кадәр кызлары бала караватында, ә әтисе белән әнисе диван-караватта йоклый торган була. Ә туачак сабыйны кая салырга соң? Аңа карават куярга бүлмәдә урын юк лабаса.

Миңлегөлне айлар, еллар буе «Нишләргә?» дигән сорау бимазалый. Гадәттә, торакларны эшләгән урыннардан бирәләр. Миңлегөл үзе 10 нчы шәһәр хастаханәсендә шәфкать туташы булып эшли. Сәламәтлек саклау министрлыгы үзе бер нәрсә дә төземи, гомумән, бу өлкәдә эшләүчеләр торак белән бик начар тәэмин ителгән. Шуңа күрә әлеге тарафтан фатир өмет итеп булмый.Ире исә 19 нчы торак-эксплуатация , участогында башта слесарь, аннары урам җыештыручы була. Хезмәтен тырышып, тел-теш тидермәслек итеп башкара. Ул җыештыра торган Юбилей урамының 3 нче йортында яшәүчеләр аның исеменә рәхмәт әйтеп хат та язалар. Миңлегөл ире эшләгән 19 нчы торак-эксплуатация участогына барырга ниятли. Хаттан өзек: «Мин участок башлыгы Андрюшинга бер бүлмәле фатир булса да бирүләрен үтенеп бардым . Ул мине үзенең булышачагына ышандырды. Мин бер ай дәвамында атнасына ике тапкыр аның янына бардым. Әмма ул биргән вәгъдәләр сабын күбегедәй буш булып чыкты. Аннары мин әлеге 19 нчы торак-эксплуатацияләү участогы буйсынган торак хуҗалыгы тресты управляющие А.Блиновка мөрәҗәгать иттем. Ул да баштарак берничә тапкыр мине фатир булырына өметләндерде. Янәсе, берәр фатир бушый-нитә калса, аны безгә бирергә ниятлиләр. Мин ул вакытларда башлык янына одеялга төрелгән балам белән бара идем Ни хәл итәсең, баланы калдырыр кеше юк. А.Блиновка бу хәл бер дә ошамаган икән. Ул мине, үзен кызгандырыр өчен, шулай бала белән килә, дип уйлаган һәм көннәрдән бер көнне ул миңа болай дип әйтеп салды. «Әлле кайларга, әллә кемнәр белән бар, әмма торак ала алмаячаксың». Бу сүзләр шулкадәр көчле тәэсир итте ки, мин, аякка көч-хәл белән басып, баламны күтәреп өйгә кайтып киттем. Өйдә ирем миннән торак мәсьәләсендә башлыгы белән булган сөйләшүнең ничек узуын сорады Мин аны-моны уйламыйча, А.Блинов белән булган сөйләшүне сүзгә-сүз җиткердем. Ирем моңа шулкадәр борчылды ки, шуннан соң аны психиатрия хастаханәсенә озатырга туры килде

Сабыемны хастаханәдән алып кайткач, баштарак тирән тимер ләгәндә йоклаттык. Ул вакытта мин коляска괄ның өске өлеше салдырылуын белми идем. Аннары баланы өстәлгә куелган коляскага салдык. Айратыбыз бер ягыннан икенчесенә әйләнгәли, башларын күтәрә башлагач, аны бала караватында йоклата, кызыбызны исә үзебез янына сыендыра

башладык. Хәзер караватыбыз янына ике табуретка, бер урындык куябыз. Әлеге утыргычларда, билгеле ки, миңа йокларга туры килә. Бу хәл инде ике ел шулай дәвам итә. Ә бит бу минем кебек йөрәк һәм аяк кан тамырлары киңәюе авырулары белән җәфаланучы кеше өчен бик тә зарарлы.»

Миңлегөл Сөләйманованың фатир юллап йөри башлавына хәзер өч ел булып килә. Улы туганнан соңгы һәр иртәсе шушы уй, шушы мәшәкать белән башлана. Һәр иртәне ул, ризык төйнәп, сабыен күтәреп нинди дә булса оешмага юл тота. Көннәре такы-токы белән тукланып дигәндәй уза.

Менә шулай йөри торгач, Киров районы хакимияте Сөләймановларга Чкалов урамындагы 1 нче йортның 31 нче фатирын (мәйданы — 28 квадрат метр) тәкъдим итә. Әмма монда да Миңлегөлне төрле буталчыклыклар көтеп тора.

Хаттан өзек: «Бу фатирны беркайчан да бушатмадылар. Чөнки биредә яшәп вафат булган кешеләрнең кызы, элек анда теркәлмәгән булса да, закон буенча алты ай яшәргә хокуклы. Ул бу фатирны, билгеле вакыт узганчы (октябрь аена кадәр иде), суд аша законлы рәвештә үзенеке итте. Хәзерге вакытта минем ул фатирны кире кагуым турында ялган акт (29 май, 1995 ел) төзелгән. Ялган, дим, чөнки минем аңа беркайчан да кул куйганым юк. һәм әлеге актны, озак вакытлар сорап йөрсәм дә, күрә, кулыма ала алмадым Әмма закон буенча өч авыруга 28 квадрат метрлы торак мәйданы гына тиеш түгелдер, дип уйлыйм. Минем иремә дә, сәламәтлеге буенча, өстәмә торак мәйдан таләп ителә бит әле Кешегә өстенлекле исемлек бары тик бер тапкыр гына бирелә».

Казан шәһәре хакимиятенең сәламәтлек саклау идарәсе башлыгы М Мөхәммәтҗановның Казан шәһәре хакимияте башлыгы К.Исхаковка юллаган хатыннан өзек «Сөләйманов Ф. — психик сырхау, икенче группа инвалид. Ул ВЦИК һәм СНКның (Халык Комиссарлары Советы) 1930 елның 28 февралендә кабул ителгән карарлары нигезендә өстәмә торак мәйданы белән файдаланырга хокуклы, ә СССРның 1983 ел, 28 мартында расланган авырулар исемлеге һәм СССР Министрлар Советының 1983 ел, 13 гыйнвары карары нигезендә торак белән беренче чиратта тәэмин ителергә хокуклы»

Миңлегөл Сөләйманованың редакциягә юллаган хаты буенча мин Киров районы хакимияте башлыгы Владимир Соловьев торак хуҗалыгы тресты идарәчесе Александр Блинов янына бардым

Владимир Соловьев миңа әлеге мәсьәлә буенча түбәндәгеләрне әйтте

— Сөләймановларның яшәү шартлары белән якыннан танышмын Аларга булышырга, ярдәм итәргә кирәк Шуңа күрә Сөләймановларның гомуми исемлектә чиратлары ерак (495 нче) булса да, без аларга Чкалов урамындагы 1 нче йорттан ике бүлмәле фатир тәкъдим иттек тә инде Әмма ул аны алмады. Без үзебез төземибез, бушаган торакны гына бүләбез Ә өч, дүрт бүлмәле фатирлар бик сирәк бушый Без аңа ярдәм итәргә тырышып карадык, ул үзе теләмәде

— Сөләймановага сез тәкъдим иткән фатир беркайчан да бушатылмаган бит.

— Әгәр дә башта ул безнең тәкъдимне кире какмаган булса, без аны бушаттыру өчен тырышкан булыр идек. Ул әлеге фатирдан баш тартты Җай чыгып, тагын шундый ике бүлмәле фатир тәкъдим итә калсак, ул аңа тагын ризалашмас Әмма әлегә безнең Сөләймановларга булышырдай мөмкинлекләребез юк.

Торак хуҗалыгы тресты идарәчесе Александр Блинов сүзләрендә дә Сөләймановлар гаиләсенә фатир бирү мәсьәләсендә өмет чаткылары сизелмәде

— Әйе. Ф Сөләйманов бездә эшләгән иде Хәзер ул авыру сәбәпле эштән чыгарылды Әмма фатир алу буенча чираты сакланып калды. Хәзер ул трест буенча бирелә торган фатир алучылар исемлегендә беренче булып тора. Без аңа бер бүлмәле торак тәкъдим иткән идек (М Сөләйманова бу фактны кире какты). Алар аны алмадылар Бездә гел бер бүлмәле фатирлар гына була. Мин биредә 10 ел управляющий булып эшлим. Җитәкчелек иткән чорда ике-өч бүлмәле торак булганы юк. Шуңа күрә мәсьәләне район хакимияте аша хәл итәргә тырышкан идек. Сөләйманова ул фатирны да алырга теләмәде Дөрес, ул, фатир бушамады, анда кызы яши дип, сылтау итә Әгәр дә Сөләйманова шул вакытта әлеге фатирга күчәргә ризалашкан булса, без чарасын күрер идек.

Районыбызда күбесенчә иске йортлар, коммуналь торакларда яшәүчеләр күп. Аннары районнарны бүлгән вакытта «Ленинград» проекты белән төзелгән йортлар Мәскәү районында калды Бездә хәзер нигездә «хрущевка»лар гына. Белүемчә, райондагы бер генә предприятие дә бүгенге көндә төзелеш алып бармый. Шулай булгач, торак мәсьәләсе көннән-көн кыенлаша бара...

Беренче карашка хуҗаларның сүзләре барысы да дөрес кебек. Ә авыру Сөләймановларның коточкыч кыен шартларда яшәве дөресме соң? Мәсьәләнең әле бит икенче — әхлакый ягы да бар Юеш парлы бүлмәдә бер гаебе булмаган ике яшьлек сабый Айрат тыны бетеп, азапланып яши, нәни кыз — Айгөл туберкулез кебек яман чир белән авырып китү куркынычы алдында тора, Ф.Сөләймановның авыруы аза бара. Бу хакта шәһәр мэры Камил Исхаков, Киров районы хакимияте башлыгы Владимир Соловьев исеменә «Фтизиатрия» ГСМОсы баш табибы И.Казаков, шәһәр психоневрология хастаханәсе баш табибы В.Казаков, ТР Сәламәтлек саклау министрлыгының баш психиатры И.Халитов, Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры К.Зыятдинов үтенеч язуы белән мөрәҗәгать иткәннәр. Аларның әлеге балалар, гаилә башлыгының сәламәтлеге буенча борчылулары җитди. Һәм бу мәсьәлә берничек тә хәл ителмичә кала алмый. Казан шәһәре, Киров районы хакимиятләре башлыклары да моны аңларлар, әлеге мәсьәләнә хәл итү юлларын бергәләп эзләрләр, дип ышанасы килә.

Сөембикә КАШАПОВА,
махсус хәбәрчебез.

P.S. Сөләймановларныкы кебек гаиләләр бездә аз түгел. Бүгенгедәй кыргый бер заманда әхлак турында сүз кузгату үзе үк урынлы түгелдер, бәлки. Ләкин әхлак — беренче, закон — икенче, диләр бит. Әхлак та, закон да кеше сәламәтлеге ягында дип тә сөйләргә яратабыз. Димәк, кешеләр саулыгы өчен әхлак та, закон да, соңыннан күп миллион сум акча түгәчәк икътисад та торырга тиеш. Әгәр без, мунча керүнең кыйбатлыгы аркасында бет үрчетсәк, инде килеп, игътибарсызлыгыбыз, мөнсезлегебез, наданлыгыбыз аркасында чир аздырсак, ул безнең намусыбыз чире булачак һәм соңыннан бик күп матди чыгымнар сораячак.

Мәгърифәтле анадан тусак та...

I

Кеше акылына Ватан төшенчәсе беренче чиратта милли-мәдәни һәм дини, шул ук вакытта камил мәгариф системасы аша сеңдерелә. Кешелек цивилизациясе, нинди җәмгыятьтә булуына карамастан, милли-мәдәни һәм әхлак кагыйдәләренә нигезләнеп төзелә. Дөрес, гасырлар дәвамында үсеп формалашкан, буыннардан-буыннарга күчкән традицияләр төрле халыкларда төрлечә булырга мөмкин Бу очракта төрле тарихи шартларда формалашкан халыкларның милли-мәдәни һәм дини традицияләрен, мәгарифен бер-берсенә каршы куярга ярамый. Шуңа күрә Кешелекнең киләчәге, кеше психологиясенең үсеше һәм камилләшүе дә әлеге төп принципларга барып тоташа.

Халыкны аның зирәк акылыннан, тирән белеменнән, күпкырлы талантлы шәхесләреннән чыгып бәялиләр. Татар халкы гомер-бакый аң-белемгә омтылып яшәде, талантлы шәхесләрне дә тарих мәйданына күп бирде. Аның белем алуга омтылуы, талантларга мохтаҗ булмавы нидән килә соң? Моның сәбәпләре нәрсәдә? Әлбәттә, сәбәпләр төрле. Шуларның берничәсен генә күрсәтеп үтик.

Беренчедән, Бөек Болгар дәүләте 922 елда Ислам динен рәсми рәвештә кабул итә. Бу, бер яктан, төрле диндә яшәгән төрки халыкларны берләштерергә ярдәм итсә, икенче яктан, гарәп цивилизациясе тудырган мәдәният, фәнни әдәбият һәм шулай ук борынгы цивилизация үрнәкләре үтеп керүгә этәргеч бирә. Шушы чорда Болгарда мәчетләр төзелеше алга китә, мәчетләр каршында мәдрәсәләр ачыла. Болгарның үзендә дә күренекле галимнәр үсеп чыга.

Икенчедән, Болгар дәүләте оешкан чорда аның күрше халыклар белән зур сугышларга керүе күзәтелми Әлеге дәвердә халыкның имин, тыныч хезмәте, күрше илләр, шулай ук Хәрәзем, Хорасан, гарәп, Кытай дәүләтләре белән сәүдә кәрваннарының алмашып торуы ил икътисадының ныгуына, һөнәрчелекнең үсүенә уңай тәэсир итә.

Өченчедән, XIII—XYI гасырларда булып узган сугышлар Болгар дәүләте һәм Казан ханлыгының милли-мәдәни үсешенә зур тоткарлык ясый. Милли психология тирән үзгәреш кичерә. Бер яктан, милли сыйфатларны югалтмыйча яшәү теләге көчле булса, икенче яктан, милли һәм дини традицияләргә хыянәт итү дә сизелә, татар халкының эчке структурасында барган милли-мәдәни һәм дини каршылыклар яисә бәрелешләр милли дәүләтчелекнең җимерелүенә китерә. Шуңа да карамастан, милли азатлыгын югалткан татар халкының яшәешендә төп чыганак булган Ислам культурасы милләтне саклап калуда уңай роль уйный. Әлбәттә моңа Шәрыкның классик әдәбияты, фәнни ачышлары аерым алганда, Фараби, Әбүгалисина, Фирдәүси, Низами кебек галим вә шагыйрьләр тудырган җәүһәрләрнең дә татар халкына бай традицияләр алып килүе сәбәп булгандыр. Шуларга нигезләнеп, татар әдәбиятының күренекле вәкилләре үзләре үк үлемсез әсәрләр иҗат итәләр.

Гадәттә, без татар әдәбияты һәм мәдәнияте тарихын өйрәнгәндә, мәгърифәтчелек идеяләренең үтеп керүен XIX гасырның икенче яртысы, ягъни Русиядә капиталистик мөнәсәбәтләр үсү белән бәйләп карыйбыз. Хәлбуки, урта гасыр әдәбиятындагы, Шәрык классикасы тәэсирендә туган, гуманистик принципларга нигезләнгән әдәби әсәрләрнең асылында да мәгърифәтчелек идеяләре ята. Тарих мәйданында капиталистик мөнәсәбәтләрнең, тууы үзеннән-үзе милли-мәдәни һәм дини структурада үзгәрешләр таләп итә. XIX гасырның 50-60 нчы елларында завод-фабрикаларның җитештерүчәнлеге арта, коллыктан котылган крестьяннәр эш эзләп шәһәрләргә ашыга, станоклар белән идарә итү өчен белемле кешеләр кирәк була башлый. Шул рәвешле, капиталистик мөнәсәбәтләрнең үсүе уку-укыту принципларының яңача юнәлеш алуына китерә, бу чорда дини идеологиянең дә заман таләбенә яраклашуы мәҗбүри санала. Дөрес, урта гасыр милли-мәдәни һәм дини цивилизациясендә кеше аңы һәм психологиясе формалашуда Ислам мәдәниятенең гуманистик принциплары уңай нәтиҗә бирсә дә, алар, дини идеология буларак, XIX йөзнең икенче яртысы — XX гасыр башында яңача фикерләүдә мәгариф системасында каршылыкларга очрый. Чонки Ислам диненең нигез ташы булган Коръән серләрен, дини идеологиянең асылын аңлап җиткермәү, мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укыту ысулларының урта гасырчылыктан алга таба җитди сикереш ясый алмавы татар милләтенең милли-мәдәни аңы үсүен тоткарлап тора.

XX гасыр башында Русия колониаль системасы изүе астында яшәгән татар милләте азатлык өчен көрәшнең яңа этабына керә. Илдә башланып киткән революцияләр шаукымында милли азатлык хәрәкәтенең сәяси төсмере көчәя, шул ук вакытта мәгърифәтчелек идеяләре дә сүнми-сүрелми. 1905-1907 елгы революция тәэсирендә дөньяга килгән милли матбугат татар мәгариф системасына үзгәрешләр кертүне, ягъни җәдидчелекне яклап чыга. Татар шәкертләре арасында башланган «Әл-ислах» хәрәкәтенең дә ярдәме зур булды. «Әл-ислах» башлап җибәргән яңача укыту принципларын татар шәкертләре яклап чыга.

Татар халкының күренекле мәгърифәтчесе Риза Фәхретдин нәшер иткән «Шура» журналында 1912 елда басылган «Мәгариф эше» исемле мәкаләгә аерым тукталырга булдык. Мәкаләнең авторы — Хәлил Ибраһим. Ул: «Русиядә ибтидаи мәктәпләр (4 нче класска кадәрге башлангыч мәктәпләр — Р.М., З.М.) бары тик 1861 елгы реформадан соң гына үсеп китә алды», — дип билгеләп үтә.

Эре җир биләүчеләр крепостнойлык хокук хөкем сөргән дәвердә крестьяннәргә белем бирергә бик ашкынып тормый. Капиталистик реформалар һәм революцион күтәрелешләр башлангыч белем бирү системасын булдыру, сәяси һәм икътисади үзгәрешләр кирәклеген раслый. Шуңа күрә дә, Александр II 1855 елда тәхеткә утыру белән мәгариф системасында да реформалар үткәрү зарурлыгын танырга мәҗбүр була.

Хәлил Ибраһим 1861 елгы реформага кадәр чит мәмләкәтләрдә яшәгән алдынгы карашлы урыс язучыларының, зыялыларының үз дәүләтләренә кайтып мәктәпләр ачуын, газит-журналлар чыгаруга керешүләрен хуплап чыга. Ул: «19 февраль акциясе берлә фәрманлык коллыктан чыгарып бәрничә миллион крестияннең уку эшләре турында уйларга, аны юлга салырга һәм бу хакта күп законнар төзергә мәҗбүрият күрелә. 19 февраль акциясенә кадәр читтә йөргән, ул вакытка кадәр халыкка файда китерергә юл таба алмаган күп затлар 19 февральдән соң Ватаннарына — Русиягә кайтып халыкны укытырга ябыштылар... Шул ук елны мәшһүр Лев Толстой чит мәмләкәттән кайтып тирә-ягында мәктәпләр ачарга кереште вә «Ясная Поляна» исемле тәрбия вә тәгълим даир бер журнал да чыгара башлады», — дип, бөек урыс язучысының мәгариф өлкәсендәге эшчәнлеген фәкать уңай яктан гына искә ала.

Югарыдан башланган ислах нәтиҗәсендә мәгариф системасында үзгәрешләр сизелсә дә, 1862 елда барлык якшәмбе мәктәпләре, өлкән яшьтәге кешеләрне укыту өчен ачылган ликбезлар ябыла. Фәкать руханилар ярдәме белән һәм алар аркылы гына төрле ибтидаи мәктәпләр ачарга рөхсәт ителә. Шулай итеп, уку-укыту эше түбән баскычка төшерелә. Шуңа карамастан, тоткарлык озак дәвам итми, 1864 елда «Ибтидаи гомум мәктәпләре хакында» исемле берничә маддәдән гыйбарәт канун чыгарыла. Шул канун нигезендә Русиядә ибтидаи мәктәпләргә нигез салына.

Шул ук вакытта дәүләт төзелешендә дә реформалар үткәрелә. Русиянең Аурупа өлешендәге утыз ике губернасында земстволар оештырыла. 1864 ел кануны буенча земствога «Халык арасында мәгърифәт таратуда хөкүмәткә ярдәм итү һәм земство хисабына ачылган мәктәпләрне законда күрсәтелгән юл берлә генә идарә кылу һәм карашу» хакына гына рөхсәт бирелгән.

1869 елдан уку-укыту эшен камилләштерү нияте белән земстволар каршында уку-укыту эшләре буенча инспекторлар вазифасы кертелә. Ун ел вакыт үткәннән соң, 1874 елда кабат «ибтидаи гомум мәктәпләр» хакында яңа закон дөньяга килә. Хәлил Ибраһим бу хакта: «Гомум мәктәпләрне һәм мәгариф эшен яман тәэсирләрдән саклауны дворяннарга тапшыру бәрабәренә хөкүмәт үзен бераз тынычландыра һәм шушы ысул гына хөкүмәт гомум мәктәпләрне, гомумән, Русиядә мәгариф эшен «тиешле» эзгә салырга муафыйк була. Бу көндәге «ибтидаи мәктәпләр» хакындагы һәрбер законда 1864 елда чыгарылган кагыйдәләр рухы саклана. 1874 ел законы соңгы көндә тәртип ителгән һәммә мәктәп законнарына нигез булып хезмәт итә», — дип, законга уңай бәя бирә.

Автор үз мәкаләсендә 1880 елда Русиянең 60 губернасында ибтидаи гомум мәктәпләр торышы, уку-укытуның хәлен беренче тапкыр тикшерелүен һәм моның нәтиҗәләрен хәбәр итә. Мәкаләдән күренгәнчә, Русиянең 60 губернасында барлыгы 22720 ибтидаи гомум мәктәп булып, аларның 2266сы 1861 елга кадәр, 1984 мәктәп 1861-1864 елларда, ә 13466 мәктәп 1864 елдан 1870 елга кадәрге дәвердә ачылган. Мәкаләдә бу мәктәпләрнең 40 проценты земстволар, 38 проценты авыл халкы, 14 проценты хөкүмәт, 5 проценты рухани идарә һәм 3 проценты шәхси кешеләр тарафыннан ачылуы хакында бәян ителә.

Шул ук тикшерү күрсәткәнчә, 59 губернасындагы ибтидаи мәктәпләр өчен җәмгысе 6157155 сум акча тотылган. Бу сумманың 53,2 проценты земстволар, 33,7 проценты авыл халкы, 6,4 проценты аерым кешеләр, ә казна тарафыннан фәкать 2,1 процент кына тотылган.

1881 елда Александр II нең үтерелүе мәгариф системасындагы реформаларга тискәре йогынты ясамыйча калмый, билгеле. 1884 елда кабат мәгариф эшен руханилар кулына тапшыру мәсьәләсе кузгатыла. Хәтта 1899 елда гомум мәктәпләрне земстволар кулыннан алу турында докладной записка да әзерләнә.

Шул рәвешлә, Русиядә мәгариф системасында реформа үткәрү тирән каршылыклар белән барган. Бу каршылыклар, һичшиксез, татар мәгариф системасына да тәэсир итмичә калмаган.

XIX гасыр дәвамында күренекле татар мәгърифәтчеләре Ш.Күлтәси, Ш.Мәрҗани һәм К.Насыйри мәктәп-мәдрәсәләрдә уку-укытуның схоластик формаларына каршы чыгалар. Алар Ислам идеологиясенең тәраккый юнәлешләрен билгеләүдә тоткарлыклар булуның һәм заманга яраклаша алмауның мәгърифәт идеяләре үтеп керүгә, мәгариф системасы үстерүгә тискәре роль уйнавын ассызыклап әйтә киләләр.

XX гасырдагы милли күтәрелешләр мәгариф эшенә, уку-укыту ысулларына реформа үткәрүне тизләтә. Милли матбугатта уку-укытуга караган материаллар, мәдрәсә программалары еш басыла. Бу күренешләр татар милли мәгарифен үстерүгә уңай тәэсир итә. Без элекке матбугатта яисә нәшриятта басылган материалларны өйрәнү һәм аларны дөньяга чыгару татар мәгариф системасын торгызуда ярдәм итәр дип исәплибез.

Рамил МИНҺАҖЕВ,
педагогия фәннәре кандидаты,
Казан дәүләт педагогия
университеты доценты;
Зөфәр МӨХӘММӘТШИН,
Г.Ибраһимов исемендәге
Тел, әдәбият һәм тарих
институты фәнни хезмәткәре.

ИЗГЕЛЕК ЭШЛӘ, ИГЕЛЕК КҮР

Илдәге тәртип юлдан башлана

Милициянең дежур бүлекчәсендә телефон чылтырый. Билгесез берәү Чирмешән елгасы буенда хатын-кыз мәете ятуы турында хәбәр итә. Тиз арада оператив группа оеша һәм җинаять кылынган урынга юнәлә. Үлгән хатын авыр тән җәрәхәтләре алган һәм тәненең шактый өлеше тупас очлы әйбер белән кискәләнгән була. Озакламый тирә-юньдәге авыллардан чакыртылган кешеләр ярдәмендә аның шәхесе ачыклана. Ул Түбән Балтай авылында яшәүче Асия Гаффарова икән. Әлеге ханымны шушындый мәсхәрәле үлемгә дучар иткән вәхшиләрне эзләү башлана. Бер көн дигәндә җинаятьчеләр табыла да. Эзләү эшендә криминаль милиция начальнигы капитан Д.Хәйруллин, прокуратура тикшерүчесе Д.Нәфизов һәм республика дәүләт авиаинспекциясе идарәсе трасса полкының Апас районы буенча подразделение командиры А.Фатыйхов катнаша. Бу язма әлеге кешеләрнең өченчесе — Айрат Фатыйхов турында.

Совет гаскәрләренең Германиядәге чикләнгән контингенты кире кайтарылу сәбәпле, Айрат та, хәрби офицер дәрәҗәсендә 5 ел хезмәт иткәннән соң, туган ягына әйләнеп кайтты. Кайтса, биредә дә хәлләр шәптән түгел икән. Һәркайда мәшәкатьләр, акчасызлык, эшсезлек... Ләкин бәхет елмая үзенә. Нәкъ шул чорда республикада трасса полкы оешты. Аңа әлеге полкның Апас һәм Кайбыч зоналары буенча оештырылган патруль-пост подразделениесенең командиры вазифасын тапшырдылар

— Һәм ялгышмадык, — диде республика трасса полкы командиры урынбасары Равил Нәбиуллин, — өлкән лейтенант Фатыйхов беренче көннәрдән үк тырышып эшли башлады. Минем шәхси фикерем шундый, соңгы вакытта, әлеге төбәктә юл-транспорт һәлакәтенең шактый кимүендә Айратның өлеше зур.

Чыннан да, Р Нәбиуллинның фикере белән килешмичә мөмкин түгел. Әйтик, узган елның шушы чоры белән чагыштырганда, әлеге төркем контрольлек иткән юлларда аварияләр 40 процентка кимегән. Агымдагы елда нибары 6 юл-транспорт һәлакәте булган. Шулардан 1 кеше үлгән, алтысы төрле тән җәрәхәтләре алган. Хәтта гади кешегә дә аңлашыла чагыштырмача алганда, мактауга лаек күрсәткеч бу. Нәкъ менә А.Фатыйхов җитәкчелегендәге төркемнең даими рәвештә юлларда тикшерүләр уздырулары һәм районнардагы җирле ГАИ хезмәткәрләре белән берлектә хезмәт бурычларын тиешенчә үти алулары нәтиҗәсе.

Алар күзләренә чалынган юл хәрәкәте кагыйдәләрен бозу бер генә очрагын да кисәтүсез калдырмый. Моны раслау өчен түбәндәге саннарны китерү дә җитә: агымдагы елда 6169 шофер административ җаваплылыкка тартылган. Күбесе — руль артына исерек хәлдә утыручылар, тизлекне арттыручылар һәм тимер юлны аркылы чыгу кагыйдәләрен бозучылар. «Күп аварияләр шулар аркасында килеп чыга. Шуңа



күрә андыйларны үз вакытында кисәтеп калырга тырышабыз. Барыннан да бигрәк, хәвефле хәлләр кабатланмасын өчен», — дип сөйли Айрат.

Болары, әлбәттә, милиция өлкән лейтенантының көндәлек мәшәкатьләре. Кечкенәдән үк хәрби офицер булырга хыялланса да, ахыр чиктә язмышының ГАИ хезмәте белән бәйләнүенә үкенми ул. Дөрестән дә, шул ук даими киеләргә тиешле форма, шул ук хәрби дәрәҗәне билгеле торган гаскәри погоннар. Айрат үзе дә бу хакта шаяртып искәртә: « Еш кына автомобильләр күземә танклар кебек күренгәли», — ди. Аның бу шаяртуында армиядә хезмәт иткән чакларын сагынуы сизелә...

... Без Ключи авылы янындагы ГАИ постында торабыз. Биредә А.Фатыйхов җитәкләгән төркемнең берничәсе даими күзәтчелек итә. Беренче карашка ук егетләрнең үз вазифаларын теләп башкарулары күзгә ташлана. Машина кабинасында кул кушырып утырмыйлар. Шикле тоелган транспортны тоткарлыйлар. Машина номерларын, техник документацияләрен җентекләп тикшерәләр һәм моның уңай нәтиҗәсе дә бар: быел гына ялган документ белән йөрүчене ачыклаганнар. Шулай ук үзләре белән утлы һәм салкын корал тыгып юлда явыз хулиганлык кылып йөрүчеләрне һәм хәтта колхоз кырларыннан тоннасы белән чөгендер урлап ташучыларны тоткарлаганнар. Әлеге эшләрдә аеруча өлкән инспектор З.Бикчуров, инспекторлар Р.Сәлахов, З.Хилавиев һәм Ф.Сабировлар зур тырышлык куя. Соңгысы хакында аеруча әйтеп үтәсе килә. Ул барлык төр техниканы әйбәт белә. Күптән түгел күрше республикадан килгән «МоАЗ» маркалы скриперны (җирне казып төягеч җайланма) туктата. Руль артында утыручы чамадан тыш исерек Фаид аңа кабинадан төшәргә боера. Алга таба рульгә үзе утырачагын әйтә. Йөртүче мәсхәрәле караш белән ризалаша: Йөртә белсәң, утыр янәсе. Фаид менеп тә утыра, озак капшанып тормыйча куәтле техниканы алып та китә. ГАИ хезмәткәренең мондый өлгерлегенә сәрхуш шакката.

Мин аларның командирлары хакындагы шәхси фикерләре белән кызыксынам. Аны гел мактап кына телгә алалар. Авыр чакларда хәлгә керә белә, юкка-барга җикеренеп-акырынып йөрми, диләр.

Гомумән кыска гына вакыт эчендә биредә Айратны яратып та өлгергәннәр. Апас районы администрациясе башлыгының беренче урынбасары Ф.Вахитов аның турында менә нинләр сөйләде:

— Айрат миңа хуҗалык эшчәнлеген яхшы белүе белән ошый. Монысын ул колхоз рәисе булып эшләгән мәрхүм әтисе Шәһит абый Фатыйховтан үзләштергән күрәсең. Ул урып-җыю чорында аеруча зур ярдәм күрсәтә. Анда-монда бушка болганып йөрүче машиналарны юл уңаенда колхозлардан дәүләт амбарларына йөк ташу эшенә җигә. Безнең хуҗалыкларда техникага ягулык материалларга кытлык булган чорда бу аеруча әһәмиятле.

ГАИ инспекторына районның юллар төзү һәм ремонтлау идарәсе начальнигы Ренат Камалов аеруча рәхмәтле.

— Безнең эштә кышын бик кыен вакытлар була, аеруча буранлы көннәрдә. Чөнки юлларга кар көрте өелә. Машиналар хәрәкәте бөтенләй туктала. Шактыйлары кырда кунып калырга мәҗбүр була. Биредә инде ГАИ хезмәткәрләре ярдәменнән башка мөмкин түгел. Шунлыктан мин гел Фатыйховка мөрәҗәгать итәм. Ул беркайчан да гозеремне кире какмый. Төнләме-көндезме юлга чыга. Тирә-күрше колхозлардан бульдозерлар чакырып, махсус ярдәм килгәнче юлны чистарту эшләрен башкарта тора. Быел март аенда шундый максат белән китеп, Айрат үзе дә ике көн юлда кунып калган иде.

Күптән түгел А.Фатыйховның тырыш хезмәтен Татарстан Республикасы эчке эшләр министры И.Галимов махсус фәрманында билгеләп үтте. Монысы яшь инспектор эшчәнлегенә бирелгән бәянең иң зурысы мөгаен.

Айратны гаиләдә дә үрнәк ата буларак беләләр. Айраттан бу хакта кызыксынгач, ул сүзен кыска тотты:

— Без икебез дә милиция хезмәткәрләре. Улым да милиционер булырга хыяллана. Хатыным Әлмира белән дус тату яшибез. Өйдә «буран» куптарырга вакыт калмый — сирәк очрашабыз, эш тыгыз.

... Без Айрат белән әңгәмә корып утырганда, бүлмәгә борчулы кыяфәтле ханым килеп керде.

— Айрат җаным, апа үлем хәлендә ята. Хирург Казаннан кайтырга чыккан. Тик аларның машинасы сезнеке кебек җитез йөри алмый. Зинһар берәрсен җибәр инде, каршы алсыннар иде, — диде ул ялварулы тавыш белән.

Инспектор урыныннан торды.

— Апа, андый эшләргә мин фәкать үзем генә алына алам, — диде ул һәм минем белән саубуллашып китеп барды.

Әңгәмәбез шул урында өзелде. Әмма моңа күңелем төшмәде. Исән-имин йөрсен, күңеле беркайчан да изгелектән аерылмасын дигән теләк теләп калдым мин аңа.

Рамил ВӘЛИЕВ.
Апас

● **Кама елгасы аша Саесканнар тавы — Мурзиха кичүендә.**
Әкрам ШӘФИГУЛЛИН фотосы.

(Дәвамы Башы 15 нче санда).

Алар кайбер пәйгамбәрләргә әүлияләргә. изге затларга яки кош, яки хайван ялсә бөҗәк. йә булмаса балык. яки болыт һ б терек ияce, ияcә җансыз сурәттә килгәннәр. күренгәннәр вә мәңге Кыяметкәчә шушы хаслыкларын саклап калырлар вә күркәм дин ияce бәндәләрне шулай хозурлалар Адәм балалары гөнаһ вә бозыклык кылалар, әмма фәрештәләр мондый гамәлләрдән тәмам азат вә ирекледәр. Алар һәммәсе дә бер Аллаһы Тәгаләнең генә әмерләренә буйсынучылар. шул рәвешле һәрдаим мактауга вә зурлауга лаеклылар Боларның сәбәбе — аларда нәфсе вә һәвәс кебек тойгыларның юклыгыннан Әгәрем ки фәрештәләр адәм балалары төсле ризыкка. киемгә, торыр йортка. җенескә мохтаҗ булсалар. ул вакытта алар да безнең кебек бозыклык куркынычы астында яшәр иделәр Кайчан Һарут белән Марут фәрештәләр җиргә төшерелеп. адәмиләргә хас сыйфатлар белән үзгәртелделәр. шунда ук күңелләрендә нәфсе вә һәвәс уты пәйда булып. теләкләрен тыя алмадылар вә Ахирәт көненә кадәр җәзага тартылып. Аллаһы Тәгаләдән миһербан үтенүдә котылу юлын таптылар Бу хәбәрдән шул аңлашыладыр. бәндәләр һәрьяклап та мохтаҗ кылынып. нәфсе вә һәвәс утыннан котылырга. һәрдаим Аллаһы Тәгаләгә таянып, оҗмах өчен теләк тотып, рухи камиллеккә омтылырга тиешләр.

ягъни адәм балаларына хас булган һәртөрле дөнья эшләре белән мәшгуль кылып, тормыш коралар, авырыйлар, савыгалар, гамь утын йоталар. хаҗәт күрәләр һ.б Әмма бар эшләренең асылында гаделлек, дөреслек, акыл вә хөрмәт ятар, күңелләре дөрес булыр

Пәйгамбәрләрнең барчасы да ир-ат җенесеннән сайланган, хатын-кызлардан пәйгамбәрләр юк. Сәбәбе — күңелләре йомшак булуда, шайтан коткысы алдында адашырга мөмкинлекләре аркасында вә акылларының ир-ат белән чагыштырганда күпне күтәрә алмавы белән бәйле. Әмма хатын-кызлар арасыннан әүлияләр булыр. Мөхәммәд пәйгамбәр — ахыргы пәйгамбәр, аннан соң килгән затларда пәйгамбәрлек сыйфатлары күренсә дә, асылда пәйгамбәр булмаслар, бәлки әүлия аталырлар. Исламда тормаган, аны белмәгән акыл ияләре әүлиялек йөген тарта алмаслар, юллары хаталыдыр.

Иман китергәндә шулай ук Ахыр көнгә, Кыямәт көненә инану тиешле. Аны «...вәл йәүмил-ахири...» дигән сүзләрне әйтү белән белдерербез. Ягъни, «Әмәнтү билләһи вә мәләикәтиһи вә кутүбиһи вә рүсүлиһи вәл йәүмил-ахири...» дип. «Вәл йәүмил-ахири» дигән вакытта «һәм Аллаһы Тәгаләнең Ахирәт көненә китерәчәгенә инандым» дигән мәгънә икәнлеген онытмаска кирәк.

Моны ничек дип аңларга кирәк соң?

Фәрит ЯХИН

ИСЛАМ ДИНЕНЕҢ ТӨП НИГЕЗЛӘРЕ БӘЯНЕ

Коръәндә әйтелгән:

تنزل الملائكة والروح

Аның мәгънәсе: «Ул Кадер кичәсендә фәрештәләр һәм Рух иңәр». Моннан шул билгеле булыр: Рух дигәндә Җәбраил галәйһис-сәлам күздә тотылыр, чөнки тагын да аны икенче төрле «Рухыл-Әмин» дип атап йөртерләр. Ул фәрештәләр арасында иң мәртәбәлесе вә күркәме саналыр, аның янәшәсендә шулай ук олуглык белән Микяил, Исрафил, Газраил исеме белән аталган мәләкләр, ягъни фәрештәләр дан тоталар.

«Әмәнтү билләһи вә **мәләикәтиһи** вә кутүбиһи...» дигәнебездә «вә кутүбиһи» сүзе «мин Аллаһы Тәгаләнең китапларына инандым» дигән төшенчәне бирә. Бу китаплар Җәбраил фәрештәнең пәйгамбәрләргә килүендә Аллаһы Тәгаләдән иңдерелгәннәр вә барчасы да изге булып торалар Бу төшерелгән, ягъни пәйгамбәрләргә иңдерелгән китапларның баштагылары йөз сәхифә күләмендә. ун битлесе — Адәм галәйһис-сәламгә, илле сәхифәлесе — Шис пәйгамбәргә, утыз битлесе — Идрис галәйһис-сәламгә, ун сәхифәсе — Ибраһим пәйгамбәргә бирелеп, тагын да дүрт олуг китаплардан Тәүрат (Библия), Зәбур (Псалмы). Инҗил (Евангелие), Коръәннең беренчесе — Муса пәйгамбәргә, икенчесе — Давыт галәйһис-сәламгә, өченчесе — Гайсә пәйгамбәргә. дүртенчесе — өммәтебезнең пәйгамбәре Мөхәммәд галәйһис-сәламгә насыйп кылынды вә алардан бу китаплар дөньяга мәшһүр булдылар бәндәләргә ирештеләр.

Бу адәм балалары өчен пәйгамбәрләренә бирелгән һәм алар тарафыннан аңлатылган китаплар арасында иң бөеге вә өстене — Коръәне Кәрим. аларның иң соңгысы да шушы китап. Болар — аның башка китаплар каршында дөреслеген белдерәләр. Аллаһы Тәгалә аның моңа кадәр китерелгән китапларның ялгышлы булуыннан азат итеп хак бәндәләренә тапшырды. Ул китерелгәннән бирле Инҗил дә, Төүрат та, Зәбур да нәсех ителделәр. Гыйбадәт өчен Коръән дөрес һәм ышанычлы, гыйбадәттә бары тик аңа гына таянырга тиешлебез. Башка китапларга гыйбадәттә таяну ярамый, әмма аларны Аллаһы Тәгаләнең бәндәләргә биргән гыйлеме буларак өйрәнергә вә белергә тиешлебез. Коръәне Кәрим белән гамәл кылу дөрес. Аның хөкемнәре Кыяметкә кадәр хак, Кыяметкә кадәр торачак.

Без тагын да әйтербез: «...вә рүсүлүһи...» дип. Ягъни, «Әмәнтү билләһи вә мәләикәтиһи вә кутүбиһи вә рүсүлиһи...» дип. «Вә рүсүлүһи» дип әйткәнебездә «Аллаһы Тәгаләнең пәйгамбәрләренә инандым» дигән әманәтебезне бирәбез. Ягъни. Аллаһы Тәгаләнең әмерләрен колларына ирештерүчеләрнең пәйгамбәрләр булуын танырга тиешлебез. Пәйгамбәрләр һәммәсе дә ялган сүздән һәм хыянәт итүдән азат, олы һәм кече гөнаһлардан пакь. Иман китерәбез икән, моның шулай булуына инану тиешле. Адәм пәйгамбәрдән алып Мөхәммәд саллаллаһы галәйһи вә сәлләмгә кадәр күпме генә пәйгамбәрләр килмәсеннәр. алар чыннан да Җир йөзендә булганнар, болар хакында гайре табигый вакыйга вә риваять-кыйссалар сөйләнүләргә дә карамастан (хәтерләребез кыскадыр. кай хәбәрләрне әкиятләргә дә әверелдергәнбездер). аларның тарихта булулары вә яшәүләре хак, монда ялган юк. Ул пәйгамбәрләр чыннан да Аллаһы Тәгалә тарафыннан сайлап алынганнар Адәм галәйһис-сәлам үзе Җир йөзенә җәннәттән чыгарылган, шуннан төшерелгән. башкалары исә анадан вә атадан туганнар, Адәм пәйгамбәрнең нәселеннән саналалар.

Пәйгамбәрне тану һәм белү тиешле Ул кешеләр арасында яхшы гадәтләр белән сыйфатланган була дөрес вә туры-хак сүзле, ышанычлы һәм Аллаһы Тәгалә әмерен вә таләбен өммәтләренә ирештерүче, заманасына күрә иң акыллы, зирәклектә камил, һәртөрле начарлыклардан. көнчелектән-нәфрәттән азат. кешеләргә зыян ясаудан. башкаларны нәфрәтләндерүче кече вә олы гөнаһтан имин, бар төрле яхшылыклар ияce икәнлекләре хак. Әмма аларның пәйгамбәрлеккә кадәр ялгышулары һәм нәби булгач та дөрес юлдан тайпылып китүләре мөмкин Мондый вакытта алар хакында «аягы таеп киткән» дип әйтү кирәкле Чөнки тиз ара төзәтеп. дөрес юлларын төзекләндерерләр Пәйгамбәрләр һәммә кешеләр төсле ук өсләренә кием киеп йөриләр ашыйлар эчәләр. әмма хәрамга кызыкмыйлар Алар шулай ук хатын алалар гаилә коралар, балалар үстерәләр, гашыйк булалар,

Һәр кеше үлгәннән соң яңадан терелтелеп, кирәдән элек яшәгән хәленә кайтарылачак, Мөнкир белән Нәкир фәрештәләр каберебезгә килеп, пәйгамбәребездән, динебездән, әлбәттә инде, иң элек Раббыбыздан сорап, сөаль итәчәкләр. Кабер газабы да бар. Сират күпере, җәннәт, тәмугның булуы хак. Дөньяда яшәгән дәверендә һәр кешенең яхшы вә яман эшләрен теркәп торган гамәл дәфтәре дә бар. Бу дәфтәр укылып, Ахирәт көнендә бәндәләрнең хисап тотулары да хак. Җәһәннәм өстенә тартылган кылдан нечкә, кылычтан үткер күперне кичеп, җәннәткә керү дә дөрес. Кемнәр җәһәннәм әһеле булдылар, аларның газапка тартылулары да хак. Шунысы да бар, кем дә кем иман белән китә, иманлы була, ул бәндәсен Аллаһы Тәгалә вә пәйгамбәре ташламый, Җир йөзендә кылган гөнаһларына бәрабәр газап вә җәзаларын алып, ул кеше ахыр чиктә, яманлыклары шулай юылып, җәннәткә кертелә. Әгәр дә менә шушыларның барысына да инанасың икән, димәк, син Ахирәт көненең булачагына вә барлыгына чын күңелдән ышандың дигән сүз.

Һәм әйтербез: «...вә бил-кадәри хайриһи вә шәрриһи мин Аллаһы Тәгалә» дип, шуның белән иман кәлимәсен тәмам итәрбез. Бу сүзләрнең мәгънәсе болардан гыйбарәт икәнен белеп тору кирәк: Адәм балаларына килгән хәер вә каза Аллаһы Тәгаләдән икәнен һәркем төшенергә тиеш. Әгәр дә бәндә үзенең көчен яхшылык теләүгә вә күркәм эшләргә сарыф итә икән, әлбәттә, аңа хәер-яхшылык ирешер, әгәрем ки яманлыкка тартылса вә начар эшләр кылса, ул вакытта казаланыр вә җәзасын алыр. Шуның өчен явызлыктан йөз чөерү, качу зарур, савапка тартылырга кирәк. Шуның өчен дә изгелек вә явызлык Аллаһы Тәгаләнең тәкъдире һәм теләге белән була дигән сүзгә инандым дию тиешле. Димәк, бәндәләрнең язмышы Аллаһы Тәгалә кулында, әмма кеше үз гомерендә, гамәлләрендә тәкъдире белән уйный, явызлыкны яки савапны эзли һәм Аллаһы Тәгалә теләге белән таба. Моннан шул аңлашыла: бәндәләрнең тәкъдире Аллаһы Тәгаләдән булса да, үзләренең дә теге яки бу казада гаепләре бар, һәм дә теге яки бу савапта гамәли өлешләре юк түгел.

Шулай итеп, без Иманның асыл мәгънәсе нидән гыйбарәт булуын тикшереп аңлаштык, «Әмәнтү билләһи вә мәләикәтиһи вә кутүбиһи вә рүсүлиһи вәл йәүмил-ахири вә бил-кадәри хайриһи вә шәрриһи мин Аллаһы Тәгалә» дип иман китергән вакытта шушы мәгънәләрне эченә алган сүзләрне әйтүебезне төшендек. Әмма болар берсе дә Аллаһы Тәгаләне танып-белүдән башка була алмый һәм дөрес түгел. Шунлыктан әһеле сөннәт һәм җәмәгать гадәтенчә Аллаһы Тәгаләнең сыйфатларын белү зарур.

آمنت بالله وملائكته ورسله واليوم
الآخر وبالقدر خيره وشره من الله تعالى

Аллаһы Тәгаләнең сыйфатларына әһеле сөннәт һәм җәмәгать гадәтенчә инану юлы

Аллаһы Тәгаләне барлык камил сыйфатлар белән зиннәтләнгән зат итеп беләбез, әмма андый затны яшәешебездә күрү мөмкин түгел. Аның фәкать бар булуын тану гына фарыз. Шунлыктан Аны һичкем вә һичнәрсә белән чагыштыру ярый торган эшләрдән түгел. Акылыбызга килергә, фикеребезгә урнашырга мөмкин һәртөрле камил рәвешле вә сыйфатлы зат Аллаһы Тәгаләнең үзенчәлекләре түгел. Ул алар белән генә чикләнми. Белергә мөмкин булган, яшәешебездә очраган һәртөрле яхшылык вә камиллекләр генә түгел, бәлки без күз алдыбызга да китерергә мөмкин булмаган өстенлекләр вә пакьлекләр дә хас. Аңа бу өлкәдә һәммәбезнең хыялы вә танып белүе чикләнгән. Әмма максатыбыз шуңа омтылырга, лаек булырга юнәлдерелгәндә генә яшәешебез бар, тормышыбыз бәхет вә сәгадәткә, үсеш вә тәрәккыяткә таба бара ала. Безнең, нинди генә гүзәл вә камил хыялларыбыз булмасын, Хак Тәгалә каршысында алар түбән. Димәк, тагын да күркәмрәк итеп уйларга вә өметләнергә тиешлебез. Ничек кенә булмасын, Аллаһы Тәгаләнең без белергә мөмкин сыйфатларын голамә вә дин кешеләре бәян итеп калдырганнар. Иман юлыбызның ныклыгын төзегән борынгы галимнәрдән мәзһәбебезнең имамы Әбү-Мансур Матриди хәзрәтләренең өйрәтүләре буенча, Аллаһы Тәгаләнең егерме ике сыйфатын белү бар. Аларның берсе — затына күрә сыйфаты, бишесе — сәлибия, ягъни раслаучы һәм ачык дәлил белән белдерелүче сыйфатлары, сигезе — мәгънәвия сыйфатлары, ягъни мәгънәсенә төшенеп аңлау белән бәйлә үзенчәлекләре. Болар барысы да Аллаһы Тәгаләне танырга вә белергә ярдәм итә.

(Дәвамы бар).

АТНАЛЫК МАНЗАРА TV

ДҮШӘМБЕ

6 НОЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.05 Мультфильмнар 18.45 Балалар өчен «Тамчы» 19.00 «Бүген Татарстан Республикасы Конституциясе көне» ТР Дәүләт Советы Рәисе В.Н.Лихачев чыгышы 19.10 «Телебуклет» Тапшырулар анонслары. 19.20 Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры турында документаль фильм: «Сәяр йолдызлыгында» 20.05 «Әлли-бәлли-бәү» 20.25 «Эстрада концерты» 20.45 Экранда кинокомедия: «Где находится нофелет?» Рольләрдә А.Панкратов-Черный, В.Меньшов. 21.55 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 «Эфирда — музыка» 7.30 «КиноМеню». 8.00, 10.55 — «Юл патруле». Атналык йомгак 8.15 «Сул аяктан» 8.55 — «Даруханә». 9.05 «90x60x90». 9.25 Мультсериал: «Ветер в ивах». 9.50 Нәфис фильм: «Веселое сновидение, или смех и слезы» 11.10 «Атна фаразлары». 11.40 Нәфис фильм: «Полет в страну чудовищ». 12.55 «Хәрби телевидение» 13.25 Нәфис фильм: «Мичман Панин». 15.00 Телесериал: «Флиппер». 11 нче һәм 12 нче серияләр. 15.55 «Кино музыкасы» О.Даль. 16.10 «Минем кино» В.Меладзе. 16.50 Нәфис фильм премьерасы: «Золотой туман». 19.10 Мультфильм: «Волшебное кольцо». 19.30 «Видеомода». 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.20, 0.25 — «Шәһәр» информацион программасы 20.45 «Камиллек» 21.15 Телеэкспресс. 21.35 «Криминаль хроника тележурналы». 22.05 Нәфис фильм: «Тайны фирмы». 1 нче серия.

1 НЧЕ КАНАЛ

7.30 Иртә. 9.00, 15.00, 18.00, 0.00 — Яңалыклар. 9.15 Телесериал: «Тропиканка». 10.05 «Мультитроллия»дә кунакта: Винни Пух һәм башкалар. 10.35 Кино актерлары җырлый. 11.15 Г.Польских һәм Е.Евстигнеев «По семейным обстоятельствам» фильмында. 1 нче һәм 2 нче серияләр. 13.30 Балалар телевидениесе фестивале. «Нәни компания өчен». 14.15 П.И.Чайковский. «Ел фасыллары». М.Плетнев башкара. 15.20 Мультфильм: «Аленький цветочек». 16.00 «Йолдызлар сәгате». 16.35 В.Грамматиков комедиясе: «Усатый нянь». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.00 «Без». В.Познерның авторлык программасы. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.00 «Вакыт». 21.50 Фантастик детектив: «Электронные жучки-5». «Убийство на свадьбе». 22.50 «Аңа кадәр һәм аннан соң». М.Молчанов алып бара. 23.30 «Яңа обывательләр» программасында «Лицедеи». 0.10 Теннис. «Кремль кубогы»на халыкара турнир. 1.05 Кискен сюжетлы фильм: «По данным уголовного розыска». Төнге канал: 2.20, 3.00 — Л.Гурченко катнашында телевизион музыкаль фильм: «Любимые песни».

«РУСИЯ»

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 — Хәбәрләр. 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30 «Вовкулакия, яки Доктор Никодимның табышмагы». 8.45 Балалар өчен нәфис фильм: «Одиссея» (Канада). 9 нчы серия. 9.10 «Алтын ачкыч». 9.30 «Әдәплелек». 9.40 «Парламент атнасы». 10.25 «Ретро-шлягер». «Меридиан» триосы. 10.55 «Пилигрим». Русиянең сәясәтләр бюросы. 11.40 Клип-антракт. «Браво» төркеме. 11.45 НБАның иң яхшы уеннары. 12.45 Информацион күңел ачу программасы: «Фаэтон». 13.15 «Карьера». 13.45 «Кайнар Уллык». 14.25 «Де-факто». 14.40 «Расследования комиссара Мегрэ» сериалыннан нәфис фильм: «Мегрэ в Виши». 2 нче кисәк. 15.30 «Беренче нөсхә». 15.40 «Футболга чикләр юк». 16.20 «Популяр булмаган тема». 16.30 «Ел укытучысы». 17.00 Җырлы биеннале: «Мәскәү — Санкт-Петербург». В.Чернов. 17.50 А.Гурнов: «Саф инглизчә репортаж». 18.00 Теннис. «Кремль кубогы». «Олимпийский» спорт комплексыннан трансляция. 19.00, 20.25 — Телеэкран премьерасы: «Кодекс бесчестия». 1 нче һәм 2 нче серияләр. 22.05 «Бизәүсез». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 «299-00-00» хезмәте. 23.55 Төнге телесериал. Нәфис фильм: «Бремя доказательства» (Эй-би-си). 1 нче серия. 0.45, 1.30 — «Сәнгать мәйданы».

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

9.00 «Ышанам, яратам...» В.Цыганова. 9.50 Мультфильм. 10.10 «Яшәү стиле». 10.25 Нәфис телефильм: «Узник замка ИФ». 11.30 «Ретро-экран». В.П.Соловьев-Седой музыкасы. 13.00 «Тагын бер Русия». Төбәкара телеканалын ачу. 13.25 Телефильм: «Сирота страны Советов» (Курган). 14.00 «Ашыгыч ярдәм». 14.30 Телефильм: «Мануэла». 15.20 Телеканал: «Тагын бер Русия». Турыдан-туры тапшыру. 15.25 Телефильм: «Человек, который сделал себя сам» (Калининград). 15.15 «Тагын бер Русия» 16.20 Телефильм: «Рогачев» (Сыктывкар). 16.50 «Тагын бер Русия». 16.55 Телефильм: «Губернские подробности» (Новгород). 17.15 «Тагын бер Русия». 17.20 «Санкт-Петербург — Новгород — Сыктывкар» телевизион күпере. 1 нче кисәк. 17.50 «Тагын бер Русия». 17.55 Телефильм: «Вперемешку» (Коньяк Сахалинск). 21.40 Күпсерияле нәфис телефильм: «Противостояние». 1 нче серия. 22.45 ТВ мәгълүматлары. 23.05 Телефильм: «Мы в дем перемен. Точка опоры» (Санкт-Петербург). 23.25 «Тагын бер Русия» Көн йомгаклары. 23.40 «Парадлар парады». Музыкаль шоу. 0.40 «Петербург көзе-95» халыкара мини-футбол турниры. Ярымфинал.

СИШӘМБЕ

7 НОЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.20 Мультфильмнар 19.00 Ф.Яруллин. Балалар өчен спектакль. «Тиен малае Тим-Тим» 19.40 «Телебуклет» Тапшыру анонслары 19.50 «Әлли-бәлли-бәү» 20.10 Р.Динәхмәтов концерты 21.40 Нәфис фильм: «Свадьба в Малиновке» Рольләрдә П.Пуговкин, З.Федорова. 22.00 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 «Эфирда — музыка». 7.30, 20.20, 23.05 — «Шәһәр» информацион программасы 7.55 Телеэкспресс (6 ноябрь). 8.15 «ПОСТ — музыка яңалыклары» 8.30 — «Даруханә» 8.40 «Сул аяктан!» 9.20, 12.20 — «90x60x90» 9.35 «Диск-канал» 10.10 Мультсериал: «Ветер в ивах». 10.35 Нәфис фильм: «На графских развалинах». 11.45 «Барысын да белергә телим» 12.00 «Атна һәлакәтләре» 12.45 Нәфис фильм: «Бег» 1 нче һәм 2 нче серияләр. 16.00 Сериал: «Мстители» 17.00 Сериал. «Спасатели Малибу» 17.55 «Музыка һәм матбугат» «Каләм осталары» Б.Моисеев. 18.50, 21.05 — «Эфирда — музыка» 19.00 Сериал: «Против течения» 9 нчы серия. 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.45 «Коммерция өйләнмәсе» 21.15 Телеэкспресс. 21.35 «Заречье»га — 70!» 21.55 Русия киносы көне. Нәфис фильм: «Детонатор». 23.30 Нәфис фильм: «Кровь и песок».

1 НЧЕ КАНАЛ

7.30 Иртә. 9.00, 15.00, 18.00, 0.00 — «Яңалыклар». 9.15 Телесериал: «Тропиканка». 10.05 «Мультитроллия»дә кунакта. Простоквашинодан өчәү һәм башкалар. 10.45 В.Золотухин «Бумбараш» фильмында. 1 нче һәм 2 нче серияләр. 13.00 Мультфильм: «Умная собачка Соня». 1 нче һәм 2 нче серияләр. 13.15 «Шлягеры столетия». Дәүләт академия симфоник оркестры уйный. Дирижер П.Сауль. 14.05 Документаль фильм: «Почему ты жив?» 15.20 Б.Бабочкин «Чапаев» фильмында. 16.55 Мультфильмнар: «Крошка енот», «Утренняя музыка». 17.15 Музыкаль программа: «Шәмәхә томан» 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.00 «Югалтылганнарны эзләгәндә». Ф.Раневская. Г.Скороходов алып бара. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.00 «Вакыт». 21.50 Е.Петросян дуслары арасында. 22.45 Л.Гурченко «Любимая женщина механика Гаврилова» мелодрамасында. 0.10 Теннис. Халыкара турнир. «Кремль кубогы».
Төнге канал: 1.05, 2.55 «Ялта — Мәскәү — транзит-95» эстрада җырларың яшь башкаручыларның халыкара телевизион конкурсы.

«РУСИЯ»

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.25 «Йолдызлар сөйли». 8.30 Мульти-пульти: «Волшебник Изумрудного города», «Веселая карусель» № 7. 9.00 Кыска метражлы нәфис фильм: «В.Давыдов и Голиаф». 9.30 Нәфис-публицистик цикл премьерасы: «Русия. Мәхәббәттә аңлашу». 10.15 Г.Преображенскаяның чакыру билеты. 11.00 «Репортер». 11.15 «Цирк... Цирк... Цирк!» 12.05 Киноконцерт. 12.35, 14.25 — Нәфис фильм: «Двенадцать стульев». 1 нче һәм 2 нче серияләр. 15.40 «Золотой Остап» клубында 25 елдан соң. 16.50 «Мода хәбәрчесе». 17.20 «Шарман-шоу». 18.15 Теннис. «Кремль кубогы». «Олимпийский» спорт комплексыннан трансляция. 19.10 «L» клубы. 20.25 Нәфис фильм: «Ты есть». 22.10 Күңел ачу программасы: «Шәһәрчек». 22.40 «Киноафиша». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 «299-00-00» хезмәте. 23.55 Төнге телесериал. Нәфис фильм: «Бремя доказательства» (Эй-би-си). 2 нче серия. 0.45 «Агата Кристи» төркеме концерты.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

9.00 Концерт. 10.20 «Яшәү стиле». 10.35 «Наобум». В.Леонтьев. 10.50 Нәфис телефильм: «Узник замка ИФ». 2 нче һәм 3 нче серияләр. 13.30 Мультфильм. 13.40 «Йолдыз» белән рандеву. Программа сәхифәләре буенча. 14.30 Телесериал: «Мануэла» (Италия). 15.20 «Балтыйк кубогы-95». Спорт биюләре буенча халыкара турнир. 16.00 «Петербург көзе-95» мини-футболы буенча халыкара турнир. Финал. Кышкы стадионнан трансляция. 17.20 Мультфильм. 17.30 «Мәхәббәт тиңлешә...» 18.00 «Сәлам! Санкт-Петербург!» Мариинский театры артистлары катнашында концерт. 20.50 Нәфис телефильм: «Противостояние». 2 нче серия. 22.45 ТВ мәгълүматлары. 23.05 Детектив. Нәфис фильм: «Чет и нечет» (Италия). 0.55 «Хит-парад» телекомпакты.

ЧӘРШӘМБЕ

8 НОЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.45 Мультфильмнар 19.00 «Татарстан» 19.35 «Телебуклет» Тапшыру анонслары 19.40 «ТАТЕХ» — икеләтә көчләрәк. 20.00 «Әлли-бәлли-бәү» 20.10 А.Фәйзрахманов «Аулак өй»гә чакыра 20.30 Телесериал премьерасы: «Вспышка» 1 нче серия 22.00 «Гашыйклар телеканалы» 22.45 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 «Эфирда — музыка» 7.30, 20.20, 0.30 — «Шәһәр» информацион программасы 7.55 Телеэкспресс (7 ноябрь тапшыруын кабатлау). 8.15, 11.05, 17.55 — «Юл патруле» 8.30, 14.45 — «Даруханә» 8.40 «Сул аяктан» 9.20, 13.00 — «90x60x90» 9.40 «Диск-канал» 9.55 «Минем йолдыз» М.Зудина. 10.40 Сериал: «Один к десяти» 11.20 «Атна низаглары» 11.50 «Валюта бәясе» 12.00 Сериал: «Флиппер» 13.15 Нәфис фильм: «Высокий блондин в черном ботинке» 15.00 «Атнага бер тапкыр» 15.35 Нәфис фильм: «Возвращение высокого блондина» 17.00, 18.10 — «Зәңгәр ут» сәхифәләре буенча 17.40 «ПОСТ — музыка яңалыклары» 19.00 Документаль фильм: «Страсти по Евгению» 19.20 «Янгын куркынычсызлыгы айлыгы» «Утсыз төтен булмый» 19.25 «Поза» 19.50 «Кыюлар һәм матурлар» 20.45 Документаль фильм: «Кайф». 21.15 Телеэкспресс. 21.35 «Үз кешеләр» 22.10 Нәфис фильм: «Тайны фирмы». 2 нче серия. 0.50 «Red Wave» тәкъдим итә.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 Иртә. 9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 0.00 — «Яңалыклар» 9.15 Телесериал: «Тропиканка» 10.05 «Югалтылганнарны эзләгәндә» Ф.Раневская. Г.Скороходов алып бара. 10.50 «Хайваннар дөньясында» 11.30 Телеуен: «Көен таны». 12.10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 12.50 Сериал: «Два капитана». 1 нче серия. 14.05 А.Габрилович фильмы: «Кино нашего детства» 15.20 Мультсериал: «Виджит спешит на помощь». 15.40 «Кактус һәм К». 15.50 «Күңелле ноталар». 16.10 «Джунглилар чакыруы». 16.35 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» (Франция). 17.00 «Тет-а-тет». 17.30, 1.45 — «Спортның җиде көне». 18.20 Телесериал: «Тропиканка» 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать» 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.00 «Тема». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр» 21.00 «Вакыт». 21.50 А.Делон «Полицейская история» фильмында. 0.10 Теннис. «Кремль кубогы» халыкара турниры (дәвамы). 0.55 Сериал: «Твин Пикс»
Төнге канал: 2.15 Музыкаль фильм: «Лимита». А.Апина.

«РУСИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр». 8.25 «Кирәк, кирәк...» 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Барысы да аз-азлап». 9.40 «Телегазета». 9.45 «Крестьян мәсьәләсе». 10.05 Телесериал: «Санта-Барбара». 11.20 «Милиция хроникасы». 11.30 «Музыкаль экспромт». 11.45, 17.20 — Мультсериал: «Камень сновидений». 12.10 «Сәүдә йорты». 12.15 «Яңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Русия». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 «Көн дә бәйрәм». 16.30 «Яңа тармак». «Ерак Көнчыгыш» 17.45 Теннис. «Кремль кубогы». «Олимпийский» спорт комплексыннан трансляция. 18.40 «Сезнең партнер» «Монтажспецбанк». 18.55 «Телебәхәсләр». 19.25 «Үз уены». 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара». 21.30 «Фортедан пьяного кадәр». 22.10 «Тикшерүләр бюросы». 23.30 «Вакыт елгасы». 23.35 «Автомизгел». 23.40 «299-00-00» хезмәте: 23.55 «Эшләпә эчендә калыгыз».0.25 «Криминаль хәбәрләр экраны». 1.50 Беата Тышкевич «Смерть Детороба» фильмында.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә». 7.45, 11.45 — «Тәҗрибә» 8.45 Балалар өчен. 9.15 «Гүзәллек» 10.10 «Бибу-шоу». 10.20 «Төш юрау» 10.40 «Такмаклар». 11.15 «Аукцион». 12.10 «Джаз». 12.40 «Кунак». 13.00, 15.30, 22.45 — ТВ мәгълүматлары. 13.10 «Яшәү стиле» 13.25, 15.40, 22.35 — «Музыка мизгеле». 13.30 ТВ мәгълүматлары. Немец дулкыны. 13.45 Мультфильм. 14.00 «Ашыгыч ярдәм» 14.30 Телефильм: «Мануэла». 15.20 Бакчачыларга киңәшләр. 15.45 Нәфис фильм: «Чет и нечет». 17.35 Балалар телевидениесе: «Балтийская руна». «Три колеса, фолиант и...» 18.20 Мультфильмнар.
22.00 «Блеф-клуб» 23.00 «Спорт, спорт, спорт ..» 23.15 Юмористик программа: «Золотой телец» 0.15 Нәфис фильм премьерасы: «Валентина» (Италия). 11 нче серия.

ПӘНҖЕШӘМБЕ

9 НОЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.45 Мультфильмнар 18.50 «ГАИ мәгълүматлары» 19.00 «Татарстан» 19.35 «Хөкүмәт сәгате» 20.05 «Әлли-бәлли-бәү» 20.15 «Авыл» Сарман районында очрашулар 20.50 «Өйләнеп кайт әле» Лилия Мансурова җырлый 21.10 Нәфис фильм: «Ревизор» Рольләрдә И.Толубеев, М.Яншин. 22.50 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 «Эфирда — музыка» 7.30, 20.20, 0.00 — «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (8 ноябрь тапшыруын кабатлау) 8.15, 11.05 — «Юл патруле» 8.30, 14.45 — «Даруханә» 8.40 «Сул аяктан» 9.20, 13.00 — «90x60x90» 9.40 «Диск-канал» 10.00 «Минем кино» В.Меладзе 10.40 Юмористик сериал: «Один к десяти» 11.20 «Нью-йорк, Нью-йорк» 12.00 Сериал: «Ночная жара» 13.15 Нәфис фильм: «Возвращение высокого блондина» 15.00 «Тегеләр, кемнәр» 15.20 «Ток-шоу» «Мин үзем» «Менә хакимият үзгәртмәдә» 16.20 Нәфис фильм: «Опасный возраст» 17.55 CNN «Стиль» 18.20 Сериал: «Джаз в Джексонвилле» 7 нче серия 19.20 «Ушуайя» 19.40 «Заречье» банкы мәгълүмат бирә 19.50 «Кыюлар һәм матурлар» 20.45 «Коммерция өйләнмәсе» 21.05 «Казанские ведомости» нәрсә турында язды?» 21.15 «Телеэкспресс» 21.35 «Бары тик кызык өчен генә» 22.05 Нәфис фильм: «Люди в длинных плащах»

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 Иртә 9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 0.00 — «Яңалыклар» 9.15 Телесериал: «Тропиканка» 10.05 «Тема» 10.50 «Сәяхәтчеләр клубы» 11.40 «Төмле» 12.10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 12.50 Сериал: «Два капитана» 2 нче серия. 14.05 А.Габрилович фильмнары: «Дворы нашего детства» 1 нче фильм. 15.20 Мультсериал: «Виджит спешит на помощь» 15.40 «Лего-го» 16.10 «Тин-тоник» 16.35 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» 17.00 «Рок-дәрес» 17.30, 2.30, 3.00 — «Спортның җиде көне» 18.20 Телесериал: «Тропиканка» 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать» 19.35 «Лотто-миллион» 20.00 «Күзгә-күз». А.Любимов алып бара. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр» 21.00 «Вакыт» 21.50 Кшиштоф Занусси фильмы: «Год спокойного солнца» 23.50, 0.10 — Теннис. «Кремль кубогы» халыкара турниры. 0.55 «Музыка күзәтүе» 1.40 Сериал: «Твин Пикс»

«РУСИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты» 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр» 8.25 «Кирәк, кирәк...» 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 «Ритмика» 8.50 «Барысы да аз-азлап». 9.40 «Телегазета» 9.45 «Крестьян мәсьәләсе» 10.05 Телесериал: «Санта-Барбара» 11.20 «Милиция хроникасы» 11.30 «Музыкаль экспромт» 11.45, 17.20 — Мультсериал: «Камень сновидений» 12.10 «Беркем дә онытылмаган» 12.15 «Яңа тармак» 12.30, 14.20 — «Эшлекле Русия» 16.05 «Шау-шулы яңалыклар» 16.20 «Көн дә бәйрәм» 16.30 «Яңа тармак» «Изгелек кыл» 17.45 Теннис. «Кремль кубогы» «Олимпийский» спорт комплексыннан трансляция: 18.40 «Сезнең партнер», Русиянең тимер юллары. 18.55 «Мин — өйдән баручы» 19.25 «Барлык кешеләр өчен музыка» 20.25 «Бәйнә-бәйнә». 20.35 Телесериал: «Санта-Барбара» 21.30 «Битлек-шоу» 22.15 «Мәхәббәт астрологиясе» Анне Вески. 22.45 «Криминаль хәбәрләр экраны» 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23.40 «299-00-00» хезмәте. 23.55 Кыска метражлы нәфис фильмнар: «Пол-листа бумаги» «Выходец из метро». «День обаятельного человека» 1.31, 2.01 — Сәүдә йорты: «Ле Монти»

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7.00 «Хәерле иртә» 7.45, 11.45 — «Тәҗрибә» 8.45 «Язалар». 9.15 «Гүзәллек» 9.40 «Рекордлар». 10.10 «Бибу-шоу» 10.20 «Төш юрау» 11.15 «Аукцион» 12.10 «Спартак» 12.40 «Кунак» 13.00, 15.30, 22.45 — ТВ мәгълүматлары. 13.10 «Яшәү стиле» 13.25 «Музыка мизгеле» 13.30 ТВ мәгълүматлары. Немец дулкыны. 13.45 Мультфильм. 14.00 «Ашыгыч ярдәм» 14.30 Телесериал: «Мануэла» 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр» 15.40 Нәфис фильм: «Ночь святого Лаврентия» 17.30 Мультфильм. 17.45 «Бөтен Русия буйлап» 18.00 «Ленинград өлкәсе» телекомпаниясе күрсәтә.
21.30, 23.15 — Милиция көненә багышланган концерт Трансляция буенча. 23.00 «Спорт, спорт, спорт ..» 0.45 Нәфис фильм: «Ночь святого Лаврентия»

ҖОМГА

10 НОЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7 00—8.00 «Чулпан» информацион программасы 18 55 Мультфильм 19.00 «Татарстан» 19 35 «Видеоспорт» 19 50 «Досье-02» 20.10 «Әлли-бәлли-бәү» 20.25 «Җомга көн кич белән» Альманах. 21 15 «Туган ай яктысында» Язучы Т Миңнуллин 21 40 «Татар халык моңнары» 21 55 Тапшырулар программасы.

«ЭФИР»

7 00 «Зарядкага басыгыз!» 7 10 «Эфирда — музыка» 7 30, 20.20, 1.00 — «Шәһәр» информацион программасы 7.55 «Телеэкспресс» (9 ноябрь тапшыруын кабатлау). 8 15, 11 05 «Юл патруле» 8.30, 14.45 — «Даруханә» 8.40 «Суп аяктан» 9.20, 13.00 — «90х60х90» 9.40 «Диск-канал» 10.40 Юмористик сериал: «Один к десяти» 11 20, 15.55 — «Спорт атнасы» 11 50 «Валюта бәясе» 12.00 Детектив сериал: «Ночная жара» 13.15 Нәфис фильм «Опасный возраст» 15.00 «Тегеләр, кемнәр..» 15.20 Сериал: «Мелочи жизни» 16.25 Нәфис фильм: «Фехтовальщик» 18.20 «POST — музыка яңалыклары» 18.40 «Видеогид» 19.00 Нәфис фильм: «Корабль любви» 10 нчы серия. 19.50 «Кыюлар һәм матурлар» 20.45 «Көннәрнең ямьсезләре булмый» 20.55 «Автомобильдән саклан» 21.05 «Эфирда — музыка» 21 15 Телеэкспресс. 21.35 «Симха» 21.40 Нәфис фильм: «Смерть на Ниле» 1.25 «Эротека Венеры» телепрограммасы.

1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 Иртә. 9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 0.00 — «Яңалыклар» 9.10 Телесериал: «Тропиканка» 10.00 «Күзгә-күз» А.Любимов алып бара. 10.40 «Таң йолдызы» 11.25 «Бар да өйдә чакта» 12.10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 12.45 Сериал: «Два капитана» 3 нче серия. 14.05 А.Габрилович фильмнары: «Дворы нашего детства». 2 нче фильм. 15.20 Мультсериал: «Отверженные» 15.45 «Яңа чынбарлык» 16.10 Фильм-әкият «Морозко» 17.30, 1.20 — «Спортның җиде көне» 18.20 Телесериал: «Тропиканка» 19.10 «Кыргый кыр» 19.25 «Кешә һәм закон» 19.55 «Могҗизалар кыры». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр» 21.00 «Вакыт». 21.35 Милиция көненә багышланган концерт 23.15 «Караш» 0.10 Спорт программасы: «Трасса» 0.30 Теннис. «Кремль кубогы» халыкара турниры.
Төнге канал: 1.50 Телефильм: «Небесная ласточка» 1 нче серия. 2.55, 3.40 — «Җыр-95».

«РУСИЯ»

7.30 «Эшлекле кешеләр вакыты» 8.00, 11.00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр» 8.25 «Кирәк, кирәк...» 8.30 «Йолдызлар сөйли». 8.35 Сәүдә йорты. «Лә Монти» 8.50 «Ритмика» 9.05 «Барысы да аз-азлап» 9.40 «Телегазета» 9.45 «Крестьян мәсьәләсе» 10.05 Телесериал: «Санта-Барбара» 11.20 «Милиция хроникасы» 11.30 «Музыкаль экспромт» 11.40 Мульти-пульти: «Веселая карусель № 8». «Волшебник Изумрудного города» 12.15, 17.20 — «Яңа тармак» 12.30, 14.20 — «Эшлекле Русия» 16.05 «Шау-шулы яңалыклар» 16.20 «Көн дә бәйрәм» 16.30 «Озынайтылган көн» 16.50 «Ай тотучы» 17.50 «Җомга саен Дисней» Нәфис фильм: «Зорро». 29 нчы, 30 нчы сериялэр. 18.50, 20.35 — Теннис. «Кремль кубогы» «Олимпийский» спорт комплексыннан трансляция. 19.25 Вертикаль. «Хөкүмәтнең эш көннәре» 20.25 «Бәйнә-бәйнә» 21.05 Телесериал: «Санта-Барбара» 22.10 «К-2» тәкъдим итә: «Ню» программасы. «А.Блокның яшерен мәхәббәте» 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23.40 «299-00-00» хезмәте. 23.55 Нәфис фильм: «Обнаженное танго» (АКШ). 1.30, 2.00 «Төнге дилижанс»

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

7 00 «Хәерле иртә» 7 45, 11 45 — «Тәҗрибә» 8.15 «Киңәшче» 8.45 «Балалар өчен» 9.15 «Гүзәллек» 10.10 «Бибу-шоу» 10.20 «Төш юрау» 10.45 «Такмаклар» 11 15 «Коллекционерлар» 12.10 «Джаз» 12.40 «Кунак» 13.00, 15.30, 22.45 — ТВ мәгълүматлары 13.10 «Яшәү стиле» 13.25, 15.40, 21 30 — «Музыка мизгеле» 13.30 ТВ мәгълүматлары Немец дулкыны 13.45 Мультфильм 14.00 «Ашыгыч ярдәм» 14.30 Телесериал: «Мануэла» 15.20 «Бакчачыларга киңәшләр» 15.45 «Кино йорты» Дж Лоллобриджида, Даниэль Ольбрыхский, Кшиштоф Занусси, Барбара Брыльска һәм башкалар. 16.45 ТВ мәгълүматлары «Европа калейдоскобы» 17 15 Балалар телевидениесе «Кешә саен бер иман» «Балаларга җәнлекләр турында» 18.00 «Ленинград өлкәсе телекомпаниясе күрсәтә» 21 35 Нәфис телефильм. «Противостояние» 3 нче серия 23.00 «Спорт спорт спорт» 23.15 «Шәхси эш» 23 45 Нәфис фильм «Джошуа» (АКШ)

ШИМБӘ

11 НОЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы 18.05 «Ял сәгатендә» 19 00 «Татарстан» 19.35 «7 нче стиль» 20.05 «Әлли-бәлли-бәү» 20 15 «Көлкә корольләре» Гала-концерт 21 15 Тамашачылар соравы буенча «Мөслим көзе» 22.25 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!». 7 10, 22.10 — «Эфирда — музыка» 7 30, 20 20, 23 10 — «Шәһәр» информацион программасы 7 55 Телеэкспресс (10 ноябрь тапшыруын кабатлау) Узган атна тапшырулары 8 10 «Коммерция өйләнмәсе» (7 ноябрь тапшыруын кабатлау) 8.30 «Видеомода» 8 50 «Камиллек» 9.20 «Көннәрнең ямьсезләре булмый» 9.30 «Поза» 9.55 «Үз кешеләр» 10.30 «Заречье»га — 70!» 10.55 «Автомобильдән саклан» 11.00 «21 параграф» 11 30 «Атнага бер тапкыр» 12.00 Сериал «Флиппер» 12.55 «Хәрби телевидение» 13.25 «Сез шаһит» 13.45 Сериал: «Мелочи жизни» 14.20 «Рок-риваятьләр» 15.25 Документаль фильм «Фонтаны Рима» 16.20 Телесериал: «Детективы на полставки» 17 15 «Яшерен йомыш» 17 40 «Йозак тишеге» 18.00 «Исәнмесез» 20.45 «Мавыгулар дөньясы» 21 15 Телесериал: «Тропическая жара» 22.10 «Музыкага чикләр юк» 23.35 Нәфис фильм: «Черная акула» 1 10 «Эротека Венеры» телепрограммасы.

1 НЧЕ КАНАЛ

7.45, 9.10 — «Уяныгыз» телеканалы 8.45 «Пастырь сүзе» Митрополит Кирилл 9.00, 15.00, 18.00, 0.00 — Яңалыклар 10.30 Балалар өчен күңел ачу программасы: «Оттырма» 11.00 «Иртәнге почта» 11 35 «Тәмле» 11.50 Телесериал: «Живопись великие имена — Ван Эйк» 12.20 «Бомонд» 12.45 А.Укупникның «Хид-парад»ы. 13.50 Хәтер фильмнары: «Взрослые дети» 15.20 «Автомобиль һәм мин» 15.50 «Хайваннар дөньясында» 16.30 «Америка М.Таратута белән» 17 00 «Шулай бервакыт» 17 10 «Бәхетле очрак» 18.20 М.Ростропович концерты. 19.00 «Алтын серия» 1987 ел. «Человек с бульвара Капуцинов» 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр» 21.00 «Вакыт» 21 50 Тарихи сериал: «Приключения королевского стрелка Шарпа» (Бөекбритания). 23.00 «Русиянең иң яхшы мультипликациясе» «Происхождение видов-1» 23.10 «Брейн-ринг» 0.10 Теннис. «Кремль кубогы»на халыкара турнир 1.05 Кира Муратова фильмы: «Среди серых камней»
Төнге канал: 2.40 Телефильм: «Небесные ласточки» 3.45, 4.25 — И.Дунаевский музыкасына фильм-балет «Лунный вальс»

«РУСИЯ»

8.00, 14.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр» 8.25 «Йолдызлар сөйли» 8.30 «Вовкулакия, яки Доктор Никодимның табышмагы» 8.45 «Рост» компасы. «Алтын антенна» 9.00 Балалар өчен телесериал: «Одиссея» 9.25 «Алтын ачкыч» 9.45 «Әдәплелек» 9.55 «Клип-антракт» В.Меладзе 10.00 «Парламент атнасы» 10.45 «Тынлыкта җиде нота» 11 15 «Ничек яшәрбез?» 12.00 «Пилигримм» «Русиянең сәяхәтләр бюросы» 12.45 НБАның иң яхшы уеннары. 13.45 «Кайнар Унлык» 14.25 «Дә факто» 14.40 «Расследования комиссара Мегрэ» сериалыннан нәфис фильм: «Трубка Мегрэ» 15.25 «Синең мөмкинлекләрең, кешә» 15.55 Нәфис публицистик программа. «Веди» 17 10 «Икә катлы портрет» 18.00 Теннис. «Кремль кубогы» «Олимпийский» спорт комплексыннан трансляция. 19.50 «Клип-антракт» «Дюна» төркеме белән кофе эчкәндә 20.25 Нәфис фильм: «Над темной водой» 22.15 В.Ерофеев программасы. «Әдәби эзләнүләр» 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23.40, 0.55 — «299-00-00» хезмәте. 23.55 «А» программасы. 1.00, 3.00 — Марлен Дитрих «Рыцарь без доспехов» фильмында.

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

9.00 Музыкаль-шоу «Телекомпакт» 10.00 «Яшәү стиле» 10.15 «Наобум» И.Костолевский. 10.30 «Кино йорты» Тонино Гуэрра, Марлен Хуциев, Владимир Наумов, Эмир Кустурица һәм башкалар 11 05 Балалар өчен нәфис фильм «Царевич Проша» 12.30 «Минем музыка» «Коз. Пушкин Музыка.» 13.00 «Теледоктор» 13.20 Документаль фильм «Чистая вода Петербурга» 13.50, 21 30 — «Музыка мизгеле» 14.00 Эшкә урнаштыру телевизион хезмәте 14.15. «Тарихи альманах» 14.45 Нәфис фильм «Дон Кихот» 16.25 «Гыйбадәтханә» 16.55 «Алтын ачкыч» 17 10 Әкият арты әкият «Бородулинский барабан» 17 50 Музыкаль клиплар фестивале «Бәллүр ачкыч» 21 40 «Оранж» телевидениесе «Телемәсәң — карама» каналын тәкъдим итә 22.25 «Теле-граф» 22 45 ТВ мәгълүматлары 23.00 Нәфис фильм «Чужак» (АКШ) 0.25 «Алкышлап!» «Парадлар парады» тәкъдим итә Л Черникова

ЯКШӘМБЕ

12 НОЯБРЬ

«ТАТАРСТАН»

7 00—8.00 «Чулпан» информацион программасы 19 00 «ТОН» (атналык телекүзәтү) 19 35 «Автокалейдоскоп» 19 50 «Телебуклет» Тапшыру анонслары 20 00 «Шигърият» Ж.Дәрзаман 20 20 «Әлли-бәлли-бәү» 20.35 А Аббасовның иҗат кичәсе 20 45 Р Вәлиев Телевизион фильм «Яшисе килә» 1 нче бүлек 22.50 Тапшырулар программасы

«ЭФИР»

7 00 Телеэкспресс (атналык тапшыруларны кабатлау) Узган атна тапшырулары 8.30 «Шәһәр» 8.55 Коммерция өйләнмәсе (9 ноябрь тапшыруын кабатлау) 9 15 «Бары тик кызык өчен генә» 9.45 «Ушуайя» 10 05 «Видеогид» 10.25, 17 40 — «Эфирда — музыка» 10.55 «Мавыгулар дөньясы» 11 50 «Атна фаразлары» 12.20 «Подводная «Одиссея» команды Кусто» 13 10 «Каләм осталары» Б.Моисеев 14.00 Нәфис фильм «Алые паруса» 15.30 «Атнага бер тапкыр» 16.00 Нәфис фильм «Если туфелька подойдет» (АКШ) 17 50 Телесериал «Детективы на полставки» 18.45 Сериал «Спасатели Малибу» 6 нчы серия 19 45 «КиноМеню» 20 15 «Җирле вакыт» Информацион программа. 20.45 Нәфис фильм «Его возвращение» 22.30 «Исәнмесез!» (11 ноябрь тапшыруын кабатлау)

1 НЧЕ КАНАЛ

7.50 «Спортлото» тиражы 8.00, 9 10 — «Уяныгыз!» телеканалы 9.00, 15.00 18.00, 0.00 — Яңалыклар 10.30 «Бар да өйдә чакта» 11 00 «Таң йолдызы» 11 50 «Турыдан-туры» 12.00 «Русиягә хезмәт итәм» (хәрби йомышчы) 12.30 «Уйна, гармун!» 13 00 «Лукошкино авылы рейтингы» 13.25 «Ап-ачык, акылга сыймаслык» 13.55 Телесериал «Мой друг — пошадь» 6 нчы фильм 14 25 «Көлкеле манзара» Е.Петросян алып бара 15.20 «Хыял вокзалы» Ю Башмет алып бара. 16 15 «Сәяхәтчеләр клубы» 16.55 «Эшлә кешә» программасы 17 15 Мультфейерверк «Легенды острова сокровищ» «Погонщики динозавров» 18.20 «Футбол күзәтүе» 18.50 «Цирк-шоу» 19.20 «Саф һавада әңгәмә» Л.Гурченко Э.Рязановның авторлык программасы 20.05 Стивен Сигал «Захват» бәевигында 22.00 «Якшәмбе» 23.05 Тарихи сериал «Приключения королевского стрелка Шарпа» 23.50, 0 10 — Теннис «Кремль кубогы»на халыкара турнир 0.55 «Бер күрүдә ярату» 1 35, 3 10 — «Ялта-Мәскәү-транзит-95» эстрада җырларын яшь башкаручыларның халыкара телевизион конкурсы

«РУСИЯ»

6.25 «Формула-1» классында автоузышлар буенча дөнья чемпионаты Австралия гран-приe Аделаидадан трансляция 8.30 «Теремкәй» 9.00 Балалар телесериалы «Одиссея» (Канада) 9.25 «Хроно» Авто һәм мотоспорт дөньясында 9.55 «Хәерле иртә» 10.25 «Аты-баты» 10.55 «Консолидация» 11 00 «Сәгать 11 дәгә хәбәрләр» 11 15 «Урыс лотосы» 12.00 «Зур хоккей» 12.40 «Расследования комиссара Мегрэ» сериалыннан нәфис фильм. «Трубка Мегрэ» 13.30 «Китап киштәсе» 14.00, 20.00, 23.00 — «Хәбәрләр» 14.25 «Кисеп бетерә алмаслык» 14 40 Теннис. «Кремль кубогы» «Олимпийский» спорт комплексыннан трансляция 16.55 «Тапшырулар тартмасы» 17 10 «Өч баһадир» 18.00 Мультфильмнар. «Чокнутый» «Новые приключения Винни Пуха» 18.55 Фредди Старр «Комедия положений» 19.25 «Ксюшада кунакта» 20 25 Л.Гурченко «Вокзал для двоих» фильмында. 1 нче һәм 2 нче серияләр 23.30 «Вакыт елгасы» 23.35 «Автомизгел» 23.40, 0.55, 1 10 — «299-00-00» хезмәте 23.55 «Туган ай»

«САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

8.05 «Сезнең көнегез» 8.30 «Шифалы сүз» 9.00 Музыкаль шоу «Парадлар парады» 10.00 «Яшәү стиле» 10.15 Мультфильм 10 30 «Музыка мизгеле» 10.40 Нәфис фильм «Московская любовь» 12.00 «Якшәмбе лабиринты» 13 10 «Страсти-мордасти» 13.25 «Кино нашего времени» циклыннан телефильм «Андре төшине» 14 15 «Классика-5» «Җәйгә кич төше» Балет «Комише опер» (Германия) 15.00 Цирк программасы «Антре» 15.20 Мультфильм 15.30 «Депутатларга сүз бирәбез» 16.00 «Буй-буй хит» «Зебра»га музыкаль өстәмә 16.30 Нәфис фильм «Первая любовь»
20.35 Нәфис фильм «Противостояние» 22.45 ТВ мәгълүматлары 23 10 «Адәм алмасы» тәкъдим итә «Ноу смокинг» 23.55 «Музыкаль җәннәт» 0.25 Спорт гимнастикасы буенча Европа чемпионаты

ДҮШӘМБЕ, 6 НОЯБРЬ

Татарстан Республикасы Конституциясе көне 7 02, 7 58 14 55 — Һава торышы 7 04 «Бәйрәм белән!» 7 45 14 55 — Тапшырулар программасы 7 50 Белдерүләр 8.00 15 00 — Радио-1 10 05 «Авызың ни әйткәнен, колагың ишетсен» 11 45 Г Сабитов Радиопостановка «Ай сукмагы» 12 45 Бәйрәм концерты 13 40 Яңалыклар эстафетасы 14 24 Р Мөхәммәдиев «Истәлек өчен Гыйлемханга» әсәреннән өзек

СИШӘМБЕ, 7 НОЯБРЬ

7 02, 7 58, 13.55 — Һава торышы 7 04 Концерт 7 45, 13.55 — Тапшырулар программасы 7 50 Белдерүләр 8.00 14 00 — Радио-1 11 45 «Хәтер» Әдәбият редакциясе программасы 12 15 Татарстан сәнгать осталары концерты 13 10 «Танышу» «Татар җыры-95» конкурсы лауреаты З Шаһбанов 13 40 Көн темасына

ЧӘРШӘМБЕ, 8 НОЯБРЬ

6.00 «Көн темасына» 6 15 «Татарстан дулкынында» 6.48 20 33 — Татарча өйрәнәбез 6.53, 7 58, 13 25 20 38 — Һава торышы 6.55 7 50 — Белдерүләр 7 00 Информацион-музыкаль программа 7 45 12.25, 20.38 — Тапшырулар программасы 8.00 13.30 18.30 20 45 — Радио-1 12.25—13 30 «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы Чыгарылышта 12 30 Концерт «Без Татарстан җирендә яшибез» 13.05 Соңгы хәбәрләр 13 10 Республика газеталарына күзәтү 14 00 Җырчы, композитор музыка эшлеклесе Г Әльмөхәммәтов 18.00 «Тормыш барометры» 19 15 Соңгы хәбәрләр 19 45 Сораулар буенча концерт

ПӘНҖЕШӘМБЕ, 9 НОЯБРЬ

6.00, 7 00 13.05, 19 15 — Соңгы хәбәрләр 6 15 «Иртәнге дулкында» 6.48 20.33 — Татарча өйрәнәбез 6.53, 7 58 13.25 20 38 — Һава торышы 6.55, 7 50 — Белдерүләр 7 15 Концерт 7 45, 12.25 20 38 — Тапшырулар программасы 8.00 13 30 18.30, 20 45 — Радио-1 12.25—13 30 — «Көн үзәге» информацион-нәфис каналы Чыгарылышта 12.30 «Балалар җырлый» 13 10 Республика газеталарына күзәтү 18.05 «Старт» (рус телендә) 19.45 Яшь башкаручылар концерты

ҖОМГА, 10 НОЯБРЬ

6.00 «Балкыш» 6.48, 20 30 — Татарча өйрәнәбез 6.53, 7 58, 13.25 20.35 — Һава торышы 6.55, 7 50 — Белдерүләр 7 15 Концерт 7 45 12.25 20.35 — Тапшырулар программасы 8.00, 13.30, 18 30, 20.42 — Радио-1 12 30—13 30 — «Көн үзәге» информацион нәфис каналы Чыгарылышта 12 30 М Ногман шигырьләренә язылган җырлар 13 05 Соңгы хәбәрләр 13 10 Республика газеталарына күзәтү 18.00 «Чишмәләр» (чуваш телендә) 19 00 Соңгы хәбәрләр 19.30 Беренчә татар профессиональ музыка белгече Х.Булатова-Терегулова

ШИМБӘ, 11 НОЯБРЬ

6.00, 7 00 — Соңгы хәбәрләр 6.15 Авыл эшчәннәрә өчен концерт 6.58, 7 58 13.33 — Һава торышы 7 15 Концерт 7 45, 14 33 — Тапшырулар программасы 7 50 Белдерүләр 8.00, 11 00 14 40 — Радио-1 8.15 «Сезнең хатларыгыз» 8.25 «Мәсьәләгә бер караш» 8.40 «Көмеш кыңгырау» 9.00 «Шигърият» программасы «Ноябрь» 9.30 Р Мөхәммәтҗанов һәм Х.Закиров хикәяләре 10.30 «Танышу» 11 45 «Кардәшлеккә чикләр юк» 12 15 «Таныш моңнар» 13 13 Яңалыклар эстафетасы 13.30 «Яшьлек» студиясе 14 05 «Әбугалисина» клубы

ЯКШӘМБЕ, 12 НОЯБРЬ

7 02, 7 58, 13.40 — Һава торышы 7 04 «Хәерле иртә!» 7 45, 13.40 — Тапшырулар программасы 7 50 Белдерүләр 8 00 «Идел белән Урал арасында» Алты республиканың берләштерелгән радиожурналы 9 00 «Тылсымлы каләм» 9 30 «Мирас» 10 10 15 50 Радио-1 11 45 «Кредо» 12 15 «Тел күрке сүз» 12 45 «Ял концерты» 13.45 «Татарстан дулкынында» 14 18 «Гүзәл иҗат үрнәге» Язучы М Маликова иҗатына багышланган кичәнең язмасы

Хәвефле өч көн

(Ахыры. Башы 10 нчы биттә).

Дөньяның ЦРУлары, ФБРлары, Өченче бүлекләр, җасуслык — шымчылык, өлөкчелек оешмалары безнең КГБ белән ярыша аламыни?! Ярыша алмый! Ярышсалар да оятка калачаклар. Кыгыбышниклар, могҗиза ясагандай, бу эшне бик тиз вә бик маһир башкардылар. Җиденче ноябрьнең таңында, иртән сәгать дүртләрдә пыяла капкач астында Ленинның бик матур эсвежий карачкысы ята иде инде. Өч тәүлек эчендә каракны эзләп, эш барып чыкмагач, терелгән Ленинны тота алмагач, башка юл белән киттеләр. Адәм майтара алмаслык батырлыклар күрсәтеп, кыгыбышниклар Шурганск шәһәрчегендәге театрда гомере буе Ленинны уйнаган, ярымсәрхуш бер артистны табып бик куандылар. Куануын куандылар, әмма Ленинны уйнаучы мәшһүр артистны ничек үтерергә? Аны терелөй урлап китү хәтта КГБ өчен дә шактый катлаулы эш иде. Поездга бәрелеп үлсә дә, урамда кыйнасалар да Ленинның чырае бозылачак.

Опергруппа тарафыннан:

— Эчертеп үтерергә! — дигән карар кабул ителде. — Эчертеп үтерергә дә, җирләгәннән соң мәетен казып алып, Мәскәүгә алып китәргә!

Ләкин артист Иван Сулейманович Кацман үләсе урында эчкән саен гайрәтләнә генә барды.

— Рәхмәт, җегетләр! — ди әртист эчертүчеләргә. — Үләргә ятканда тереләттегез сез мине. Күпме еллар эшләп ни исемем, ни акчам...

Тагын да күбрәк аракы алып, аны үлгәнче сыйларга КГБның акчасы җитәрлек иде, ләкин Иван Сулейманович өч көн эчкәннән генә үләрдәй түгел иде. Ә вакыт кыса. Акыллы майорлар, полковниклар, генераллар бу кыен мәсьәләнең чишелешен тиз таптылар.

— Җәһәт кенә Верховный Совет указы чыгарттырырга кирәк, — диделәр. — Ленин образы тудырганы өчен Иван Сулеймановичн Кацманга Социалистик Хезмәт Каһарманы исеме бирергә! Яманлап үтерә алмаганны, мактап үтереп була!

Указ шул көнне үк басылып чыкты. Яман да шәп банкетны Крайком үз өстенә алды. Әлбәттә, акчасын КГБ түләде. Шул мәҗлестә, күкрәгенә Алтын Йолдыз кадаганда, сөенеченнән Иван Сулеймановичның йөрәге ярылып үлде. Аны олылап җирләделәр. Җирләгән төнне үк Иванның гәүдәсен кабердән алып, Мәскәүгә озаттылар...

Шушы эшне бик оператив, хәтәр дә яман шәп башкарганнары өчен майорлар полковникка әйләнде, полковниклар генерал булды, генераллар маршал дәрәҗәсенә күтәрелде. Хәтта бер маршалга генералиссимус бирергә кәгазь әзерләгәннәр, ди.

Бөтенесе дә майлаган кебек булды. Кап та йот. Ленин да үз урынында. Социализм тагын да артыграк үсеп китте. Кремльдә инде күптән комму-низом, кому верхом, дигәндәй, ал да гәл, калганын үзең бел. Ләкин шушы сәгадәт, ягъни шушы бәхетле совет тормышы тагын да бозыла язды.

Ленин чырайлы берәү:

— Мине Үзәк Комитетка кертегез! — дип Кремль капкасына килә. Әлбәттә, аны кертмиләр.

Ике солдат һәм бер майор килеп, аның кем икәнен сорыйлар.

— Мин — Ульянов-Ленин! — ди сукбай.

Майор үзенең ике солдаты белән Ленинны бөтереп алып, акыл хасталыгы белән авыручылар йортына илтеп тапшыра. Барганда да, врачлар алдында да бичара тоткын һаман бер сүзне кабатлый икән:

— Гражданнар! Мин — Ульянов-Ленин! Революция ясап, сезгә бәхет алып килгән Ленин мин!

Аның кыланышларын тыныч кына карап торучы баш врач әйтеп куя:

— Бездә өч Наполеон, ике Христос, биш Маркс, ун Сталин бар. Ленин гына җитми иде. Әйдә, узыгыз, пролетариат юлбашчысы Владимир Ильич Ленин!

— Сез көлмәгез, иптәш доктор, — ди тоткын. — Мин чыннан да Ленин!

— Кем әйтте сезне Ленин түгел дип?

— Мене бу майор сыныгы!

— Ул инде майор түгел, — ди врач. — Бүгеннән ул — полковник. Сезне тотып япкан өчен бәлки генерал да булыр, Владимир Ильич!

— Доктор, сез чыннан да минем Ильич икәнемә ышанасыз бит, иеме?

— Әлбәттә, ышанам, Сез — Ленин!

— Алайса, нигә миңа буй-буй күлмәк кигерттегез?

— Сезгә монда яхшырак булачак, Владимир Ильич. Әлбәттә, Маркс белән Сталин сезгә тынгы бирмәс, алдагы Ленинняарны да алар тиз ашады. Шулай да без сезне озаграк сакларга тырышырбыз. Аннан соң мавзолейдагы урыныгыз буш түгел бит. Бер мавзолейга ике Ленин башы сыймый!

— Кремльгә кайтарыгыз!

— Кремльдәге урыныгыз да буш түгел шул. Ул урынга тагын әллә ничә Ленин, әллә ничә Сталин үрмәләп маташа...

Баш врач кемгәдер ишарә итә:

— Һәр көн инсулин кадарга!

Ак халат кигән ике әзмәвер бичара тоткынны алып китәләр.

— Җибәрегез мине! Мин — Ленин, җибәрегез! Мин Дзержинскийга, Совнаркомга язачакмын! — дигән тавыш ерагая барып, коридор борылмасында сүнә.

... Бу хәл 1987 нче елның 7 ноябрь көнне булды.

Мавзолей күтәртмәсендәге Горбачевны алкышларга күмеп, бәхетле совет халкы Кызыл мәйдан буйлап агыла иде...

Шушы төшне мин хатыным Рузиягә сөйләдем. Ул озак кына дәшми утырды. Аның фикерен көтәм, аның мактавын телим: шәп хикәя булачак, дим. Бераз утыргач, хатыным мышкылдап куйды, аннан соң яшьле күзләре белән сөерсенеп миңа карап торды да ныклап җылый башлады.

— Син моны язарга уйлыйсыңмы? — диде.

— Бәрәк — дидем. — Әзер бит инде, кәгазьгә генә төшерәсе бар.

— Мондый төш күрергә ярамый, — диде Рузия. — Күрсәң дә язарга ярамый.

— Нигә? — дим.

— Башың икемени синең? Бала белән мин нишләрмен?..

Риза ИШМОРАТ

Татар әдәбияты һәм мәдәнияте зур югалту кичерә: шушы елның 29 октябрендә халкыбызның күренекле драматургы, сугыш һәм хезмәт ветераны Риза Ишморат 92 яшендә вафат булды.

Риза Фәхретдин улы Ишморатов 1903 елның 1 ноябрендә хәзерге Башкортстанның Яңавыл районы Бәдрәш авылында туган.

Булачак драматург 6 яшеннән мәктәпкә йөри, бераздан мәдрәсәдә, аннары урысча-татарча земство мәктәбендә белем ала. 1916-1918 елларда укуын Минзәләдә, Уфаның «Госмания» мәдрәсәсендә давам итте. 1920 елны Уфадагы педагогик курсларны тәмамлагач, Уфа эчке иминлек гаскәрләренең сәяси бүлегендә хәрби хезмәткәр. Актаныш төбәгендә башлангыч мәктәп укытучысы, Минзәлә шәһәрендә балалар тәрбиячесе булып эшли.

1923 елны Казанга килеп, театр техникумына керә. Аны тәмамлагач, 1926 елда Татар дәүләт академия театрында режиссер булып эшли, беренче чор иҗаты шунда башлана. «Йокы патшалыгында», «Өтек философ» (1926) пьесаларын сәхнәгә үзе куя.

Җитмеш елга якын сузылган иҗат гомерендә Риза Ишморат гаять зур һәм катлаулы тормыш юлы уза. Утызынчы елларда ул Ленинградтагы Сәнгать тарихы институтының югары курсларында укый, 1931-1940 елларда Татар дәүләт академия театрында режиссерлар коллегиясе җитәкчесе булып эшли, пьесалар куя, әдәби бүлек мөдире буларак, татар драматургиясенең үсешенә нык ярдәм итә. Язучы-драматург буларак та шул чорда танылa. Ун ел эчендә аның ун пьесасы тамашачыларга күрсәтелә, әдипнең исеме киң катлау хезмәт ияләренә танылып өлгерә. «Пожар», «Данлы чор», «Мәдинә», «Ил өчен», «Ватан» пьесалары аеруча зур уңыш белән бара, сугыш алдыннан язылган «Гөлзадә» драмасы тамашачылар күңелен бүген дә дулкынландыра.

Сугыш алдыннан Риза Ишморат Татарстан Халык Комиссарлары Советы каршындагы Сәнгать эшләре идарәсе башлыгы урынбасары вазифасын башкара.

1942 елның маенда Риза Ишморат фронтка китә. Беренче Украина фронтында «Ватан намусы өчен» газетенең башта хәрби хәбәрчесе, аннары баш мөхәррире булып, Воронеждан Берлингача авыр сугыш юлы уза, Берлиндагы урам сугышларында каты яралана. Сугышчан хезмәтләре өчен ул «Кызыл Йолдыз», Икенче дәрәҗә Ватан сугышы орденнары, медальләр белән бүләкләнә.

Риза Ишморат тормышны тирәнтен белүче, ватанпәрвәр язучы иде. Аның сугыш чорында язган «Кайту» пьесасы татар драматургиясенең алтын фондына керде.

Хезмәт кешесен олылау, тарихи шәхесләрнең зур һәм җитди образлары Р.Ишморат драматургиясенең төп сыйфаты иде. «Якты юл» (1947), «Бистә кызы Гөлсинә» (1952), «Шаулыйлар дулкыннар» (1964), «Үлмәс җыр» (1955), «Алар дүртәү иде» (1961), «Давылга табан» (1963), «И мөкатдәс моңлы сазым» (1982) шундыйлардан. Завод-фабрика эшчеләре, герой шагыйрь Муса Җәлил, океан давылларын җиңгән Әсгать Җиһаншин образларын тасвирлаган әсәрләре татар, урыс һәм башка милләт театрларында зур уңыш белән барды.

Риза Ишморат — гомерен туган халкының азатлыгы, бәйсезлеге өчен көрәшкә багышлаган зур эрудицияле әдип, зыялы, кырыкка якын сәхнә әсәренең авторы. Риза Ишморатның әдәби эшчәнлеге күпьяклы: драматург, язучы-публицист, тәрҗемәче, тәнкыйтьче, истәлекләр авторы. Ул киң күңелле, мөлаем, гаять ихтирамлы, кешеләрне ярата торган олы җанлы шәхес иде.

Әдәбият һәм сәнгать өлкәсендәге хезмәтләре өчен Риза Ишморат Хезмәт Кызыл Байрагы, «Почет билгесе» орденнары белән бүләкләнде. Татарстанның һәм Русиянең атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исемнәргә лаек булды.

Танылган драматургның, сугыш һәм хезмәт ветеранының якты образы каләмдәшләренең һәм халкыбызның күңелендә мәңгә сакланыр.

М.Ш.Шәймиев, В.Н.Лихачев, Ф.Х.Мөхәммәтшин, Х.М.Низамов, Р.М.Харисов, И.К.Хәйруллин, М.Х.Хәсәнов, М.М.Таишев, К.Ш.Исхаков, С.Ф.Мөхәррәмов, Р.С.Мөхәммәдиев, Г.Б.Бәширов, Ә.Н.Еники, Г.А.Ахунов, А.М.Гыйләҗев, Т.А.Миңнуллин, М.Х.Сәлимҗанов, Р.Г.Ишморатова, А.Г.Әхмәдуллин, А.Г.Хәбибуллин, Р.А.Таҗетдинов, Р.Ф.Кәлимуллин.

Габделхәй САБИТОВ

Ни аяныч, татар әдәбиятына югалту арты югалту килә.

Танылган язучы Габделхәй Сабитов шушы елның 29 октябрендә алтмыш дүрт яшендә арабыздан китте.

Габделхәй Вәли улы Сабитов 1931 елның 28 июнендә Татарстанның Минзәлә районы, Югары Тәкермән авылында колхозчы гаиләсендә туган. Күзкәй урта мәктәбен тәмамлаганнан соң, Иске Мәлкән, Түбән Тәкермән мәктәпләрендә укыта, уку-укыту эшләре буенча мөдир була.

1956 елда район газетенә эшкә күчә. Мәскәү әдәбият институтында драматургия бүлеген тәмамлый. 1960-1965 елларда Казан телевидениесе студиясендә әдәби-драматик тапшырулар буенча мөхәррир була, «Ялкын» һәм «Чаян» журналларында хезмәт итә.

Илленче еллар ахырында һәм алтмышынчы еллар башында Г.Сабитов «Туган җир туфрагы», «Агач аяклы кеше», «Өч күңел», «Корбан ашы», «Сөйлүн чәе», «Үлемсез Акылгали» кебек хикәяләрен, әкиятләрен матбугатта чыгарып, татар телен камил дәрәҗәдә белүче талантлы язучы булып танылды. «Кичерелмәс гөнаһ» исемле драмасы белән профессиональ сәхнәгә менде. Аның «Чулпан таңны уята» исемле драмасы 1973 елда Татарстан Мәдәният министрлыгы оештырган конкурс бүләгенә лаек булды. Шул ук чорда ул Габделхәй Сабитовка хас әдәби тәрҗемәләре, үзенчәлекле очерклары белән дә укучының ихтирамын казанды. Әдәби тел остасы булып укучы күңеленә керде. Бигрәк тә балалар-яшьләр аның әсәрләрен үрнәк итеп укыдылар, аны остазлары итеп санадылар.

Үзенең тыйнаклыгы, эчкерсезлеге, ихлас булуы белән аерылып торган әдип Габделхәй Сабитовның китаплары укучылар кулыннан төшмәс, аның исеме, нечкә зәвык белән тудырган иҗаты һәрвакыт безнең күңелләрдә сакланыр.

Татарстан Мәдәният министрлыгы, Татарстан Язучылар берлеге.

Иҗтиһат

Рәфис Кашапов:

Дан өчен җүләр генә акча өләшә

— Рәфис әфәнде, сезне бик юмарт кеше, диләр...

— Әйе, без, кардәшләрем белән унбишләп китап чыгардык, аларны халыкка бушлай тараттык. Болар — татар халкының узганы, фаҗигале язмышы турындагы әсәрләр. Аянычлы тәкъдиребез турында ике фильм төшердек, өченчесе әзерләнә...

— Бу гамәлләрегезнең нигезендә нәрсә ята — ихлас фидаилекме, әллә дан артыннан куумы?

— Дан өчен җүләр генә акча өләшә...

— Шулай да бу ярдәмчеллек сезгә кайдан килә?

— Мәктәптә укыганда безгә укытучылар, коммунизм була, дип сөйләделәр. Өйгә кайткач, әби-баба, алданмагыз, оланнар, боларның бөтенесе дә ялган, халыкны алдау гына, диделәр. Утыз елдан соң гына без әби-бабаның хаклы икәнен аңладык. Мәктәп безне ялганга өйрәтте... Армиягә киттек. Армия безне сүгенергә, аракы эчәргә, урларга, көчсезләрне җәберләргә өйрәтте... Халык эчә, яшьләр эчә. Эчә торган халыкка мәчет тә, чиркәү дә кирәкми. Эчкән халык бетүгә дучар. Сөрхуш кеше телен, динен, гореф-гадәтләрен оныта. Себердәге ничәмә-ничә халыклар юкка чыкты! Жириновский әйтә, татарларны чиркәүләргә куып кертеп, чукындырырга кирәк, ди. Миңа тавыш биргән кешене бушлай аракы белән сыйлыйм, ди. Әгәр дә шушылай барсак, без дә бетәчәкбез. Айнырга, котылырга, коткарырга, ярдәм итәргә кирәк. Гарипләргә, сугыштан кайткан инвалидларга без хәлебезчә ярдәм итәбез. Үсмерләр тәртип боза. Без шундый үсмерләрне җыеп, сәяхәткә чыгабыз, ата-бабаларыбыз туфрагына, Болгарга барабыз. Белесезме, тарихка орынудан алар яхшы якка үзгәрә. Эчүне, сүгенүне ташлыйлар. Безнең максатыбыз айныту, уяту, чисталыкка, миһербанга өндәү!

— Сезнең рәшәткә артына кергәнегез бармы?

— Бар. Чөнки без төрмәгә элеккән яшьләр белән дә эшлибез. Питрәч төбәгендәге төрмәгә барып йөри торгач, утыз-кырык тоткын эчү-сүгенүне ташлап, намаз укый башлады.

— Татарстанда сезнең кебек химаячеләр тагын бармы?

— Химаячелек эшенә бүтән малтабарлар да килеп кушылды, шөкер, алар арта бара. Алга таба бу эшебезне тагын да киңрәк җәелдерергә исәплибез.

Әңгәмәне **ТУРАЙ** әзерләде.

Чаян йолдызлыгы астында туганнар

КОТЛЫЙБЫЗ!

3 ноябрь

ГАФАРОВ Хәйдәр Зәйнулла улы — Татарстан Фәннәр академиясенең «Тергезү травматологиясе һәм ортопедиясе» Үзәге директоры, медицина фәннәре докторы, Татарстан Фәннәр академиясенең әгъза-мөхбире.

САЛИХОВ Кев Миңнулла улы — Е.К.Завойский исемендәге Физика-техника институты директоры, КДУның химия-физика кафедрасы мөдире, физика-математика фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең хакыйки әгъзасы һәм вице-президенты.

4 ноябрь

ЯКОВЛЕВА Галина Александровна — М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт академия опера һәм балет театры балет солисты.

5 ноябрь

ВАФИНА Гүзәл Вакыйф кызы — Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе артисты, Татарстанның атказанган артисты.

РЯБОВ Александр Андреевич — Ульян университетының юридик факультеты деканы, юридик фәннәре докторы, профессор, Татарстан Фәннәр академиясенең әгъза-мөхбире.

ФӘТТАХОВА Ания Гарифулла кызы — Минзәлә драма театры артисты, Татарстанның атказанган артисты.

6 ноябрь

БӘХТИЯРОВА Чулпан Нәкыйп кызы — музыка белгече, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.

ГӘРӘЕВА Салисә Гәрәй кызы — шагыйрә, Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре.

НИГЪМӘТУЛЛИН Энгель Галимҗан улы — әдәбият галиме.

7 ноябрь

БОРИСОВ Владимир Иванович — Татарстанның атказанган архитекторы.

МИФТАХОВА Рәхилә Хәйдәр кызы — Татарстанның һәм Русиянең атказанган артисты.

СӘЛИМҖАНОВ Марсель Хәким улы — Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры баш режиссеры, СССРның халык артисты, Русия һәм Татарстан Дәүләт бүләкләре иясе.

РОЙТФАРБ Григорий Зельманович — Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе артисты, Татарстанның халык артисты.

Яңа газетага язылу бара



— Курай уйнаганда да күңелең күтәрелми... Әллә, картым, «Мәдәни җомга»га язылып карыйкмы?

Чайнворд



Барлык сүзләр дә «А» хәрефенә башлана

1. XIX гасырда яшәгән татар-башкорт шагыйре. 2. А.Толстойның фантастик романы. 3. Татар халык әкияте. 4. Татарстандагы район. 5. Татар язучысы Алишның исеме. 6. Җырчы, Татарстанның халык артисткасы. 7. Сөйләм башында бер үк сүзнең кабатлануыннан гыйбарәт поэтик алым. 8. Зур яфраклы споралы үсемлек. 9. Вакыт берәмлеге. 10. Ю.Семенов романы. 11. Төркиядә яшәгән татар галиме, «Тоткынлык хатирәләре» повестеның авторы («Мирас», 1993, 3 нче сан). 12. Буй-буй таплары булган ерткыч балык. 13. Җимеш. 14. Е.Евтушенко повесте. 15. Башаклы культура. 16. Олырак яшьтәге кыз туган. 17. Ходай, тәңре. 18. «Ике буйдак» романын язган язучының исеме. 19. Предмет яки күренеш исеме, термин. 20. Бизәнү әйбере. 21. Иген уңышын күтәрә торган матдә. 22. Еврипид трагедиясе. 23. Әкиятләрдә сөйләнә торган берничә башлы елан. 24. Печтерелгән айгыр. 25. Капма-каршы образларны бирүдән гыйбарәт әдәби стилистик алым. 26. Чүп үләне. 27. М.Җәлилнең 1920 елда язган шигыре. 28. Ачыган камыр. 29. Йөк ташу өчен тәгәрмәчле хуҗалык әйбере. 30. Дагыстан халык шагыйрәсе. 31. Нинди дә булса мәсьәләгә бирелгән ачыклау. 32. Чувашстанның халык шагыйре. 33. Олы ир туган, абый.

Ренат **ГАЛЯВИН** төзеде.

Мәдәни җомга

Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат, Мәдәният министрлыклары химаясендә чыгарыла

Баш мөхәррир Зиннур МАНСУРОВ

Баш мөхәррир урынбасарлары Газинур МОРАТ, Миншәех ЗӘБИРОВ

Җаваплы сәркатип Альберт САБИРОВ

Телефоннар:
32-41-79 — кабул итү бүлмәсе;
32-45-78, 32-06-76 — баш мөхәррир урынбасарлары;
32-57-36 — җаваплы сәркатип;
32-57-76 — җаваплы сәркатип урынбасарлары;
32-62-79 — публицистика, очерк, сәясәт бүлеге;
32-58-91, 32-68-22 — әдәбият бүлеге;
32-60-11 — сәнгать бүлеге;
32-12-08 — тәнкыйть, фән, тарих бүлеге;
32-62-79 — мәдәният яңалыклары, мәгълүмат, тәрҗемә бүлеге
32-59-55 — халык тормышы, рухиятне яклау;
32-69-54 — хатлар бүлеге;
32-66-28, 32-59-22 — рәссамнар;
32-69-26 — фотохәбәрче;
32-57-94 — бухгалтерия.

Авторлар фикере редакция фикере белән муафыйк булмаска да мөмкин

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

Газетада басылган язмаларны, фотографияләрне файдаланганда, шулай ук өземтәләр китергәндә, «Мәдәни җомга»дан алынганлыгын күрсәтү мәҗбүри

Реклама урнаштыру өчен заказлар кабул ителә

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәлек ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты: 609403 МФО 265566 в Бауманском отд. ПСБ

Газета Татарстан Республикасы Мәгълүмат һәм матбугат министрлыгында 428 нче таныклык белән теркәлде

Индекс — 54129

Редакция адресы: 420503, Казан, Бауман урамы, 19.

Нәшрият адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2

Басмахана гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре уңаеннан 49-36-62 номерлы телефон буенча шалтыратырга

Газета редакциянең компьютер үзәгендә эшләнде

Газетаның сатудагы бәясе килешү буенча

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе

Тираж 8000
Заказ 4464